
PRESSA.RU

1926–1991 ЕЛЛАРДА АЗАТ ХАТЫН



2017 ОКТЯБРЬ № 10

СӨЕМБИКӘ

ISSN 0869-1398

ДӨНЬЯНЫ ИГЕЛЕК ТОТА
өлкәннәр ялгыз түгел

ИТАЛИЯ КАНИКУЛЛАРЫ
без ачкан дөнья

ЛИЛИЯ МУЛЛАГАЛИЕВА СЫЙЛЫЙ
бәрәңге тәкәсе

Рәйсә НИРАДЖ ВЕД-ЗАКИРОВА:

«ҺӘРКЕМ ҮЗ ЮЛЫННАН АТЛЫЙ»




PRESSA.RU



И-и ямьле туган ягым!



Марсель ГАЛИЕВ

Ә Чатыр тау (Азнакай) – башка... Идел-йортыбызның иң биек түбәсе саналса да, иңенә ятып еларлык яшел мендәр дә ул, рухыңа дәрт өстәрлек мәгърур биеклек тә ул, балачак иленә кайтара алган җил ияре дә ул. Чатыр тау сине, учына алып, күк гөмбәзенә чөя дә яңадан үз биеклегенә төшереп бастыра. Син шул мизгелдә бөтен уй-вөҗүдеңнән аерылып, Аллаһы катына якынаеп алганыңны, күзгә күренмәгән сәмави затның җил-канат белән башыңнан сыйпап алганын, һәм үзеңнең бер карышка олыгаеп киткәнеңне тоясың... Түбәсендә кылганнар йөгергән Чатыр тауга менеп, син Тарих хәтерен уятасың. Кара диңгез ярындагы Чатыр даг белән Урал бусагасындагы Чатыр тау – табигатьнең игезәкләре, иксез-чиксез киңлекләрне биләгән төрки-татар мәмләкәтенең тере маяклары...

Тау рухы

*Чатыр тау, дисәм, күңелдә
Чөелә бер горурлык.
Ул горурлык гел дә шулай
Тау рухына торырлык.*

*Саумы, диеп каршылый ул,
Кочаклап ала җиле.
Тау гынамы – туган җирнең
Кыйбласы, шәмаиле!*

*Җир йөзендә күпме таулар
Күктән йолдызлар аулый.
Тышаулана яшеннәре,
Бөркетләр томшык чарлый.*

*Миңа калса, бар таулар да
Бер тамырдан – кардәштер.
Мәңге горур кыялар да,
Энекәш, дип Чатыр тауга
Ерактан танып дәшер.*

*Бәллүр бозлы кыяларның
Бүтән ырым-уены.
Миңа газиз үз тавымның
Мәҗүси җил куены.*

*Менә ул – гомер Чатыры!
Күңелнең үз түбәсе;
Ятып ауна күкрәгенә –
Шулдыр бәхет түбәсе.*

Сөй гомерне, сөй халыкны, сөй халыкның дөньясын!



© «Сөембикә» 2017

1926 елдан башлап «Азат хатын» исеме белән чыкты. 1991 елда «Сөембикә» итеп үзгәртелде. Хатын-кызларның бөтентатар айлык әдәби-нәфис журналы 1913–1918 елларда чыккан «Сөембикә» журналының дәвамчысы.

Ежемесячное литературно-художественное и культурно-просветительское электронное периодическое издание на татарском, русском языках для женщин и семьи.

Территория распространения: Российская Федерация, зарубежные страны

Элемтә, мәгълүмати технологияләр һәм массакүләм коммуникацияләр өлкәсендәге күзәтчелек буенча Федераль хезмәтендә (Роскомнадзор) 2015 елның 18 маенда «Сююмбике» дип теркәлгән. Теркәү таныклыгы Эл № ФС 77-61814

Язмалар авторның тулы адресы күрсәтелеп, паспорт мәгълүматлары, пенсия иминияте таныклыгы, ИНН таныклыгының ксерокс күчермәләре белән бергә җибәрелгәндә генә кабул ителә.

Кулъязмаларга бәя бирелми, алар кире кайтарылмый.

10’2017



Җитәкче-баш мөхәррир
Ләйсән Рәфикъ кызы ЮНЫСОВА

Редколлегия:
Зилә Вәлиева, Нәбирә Гыйматдинова, Эльмира Зарипова, Кадрия Идрисова, Сәрия Сабурская, Айрат Сибагатуллин, Иркия Төхвәтуллина, Нурия Һашимова, Гөлназ Шәйхи, Эльвира Әхмәтова.

Редакциянең гомуми телефоны 222-09-77
Җитәкче урынбасары
Рәмзия Кашапова 222-09-78
Баш мөхәррир урынбасары
Гөлнур Хәсәншина 222-09-78
Җаваплы сәркатип
Лариса Маликова

Сайт мөхәррирләре:
Сөмбел Гаффарова
Камилә Димөхәммәтова

Автор фикере редакция фикере белән туры килмәскә мөмкин.

Реклама текстлары аны бирүчеләр җаваплылыгында.

Редакциянең язмача рөхсәтеннән башка материалларны «Сөембикә»дән күчереп басу тыела.

Дизайн-макет:
«ASAFIN GROUP»
Верстка:
Лариса Маликова

Тышлыкта:
Рәйсә Нирадж Вед-Закирова

Бүлек мөхәррирләре:
Мәдинә Авзалова
Лилия Гәрәева
Эльмира Закирова
Асия Юнысова
Фәнзилә Мостафина
Фотокорреспондент
Ксения Богданова
Корректор
Фирдәвес Исмәгыйлева
Гамәли хезмәткәрләр:
Нәфисә Әскәрова
Ленар Хәкимов

Формат: 225х290 мм.
Күләме 64 бит.

Басарга кул куелды:
7.10.2017 ел.
Заказ А-2530.
Тираж 5391.

Учредитель:
Акционерное общество «Татмедиа»



ТР «Татмедиа» Матбугат һәм массакүләм коммуникацияләр республика агентлыгы ярдәме белән чыгарыла.

Редакция адресы: 420066, Казан, Декабристлар урамы, 2 нче йорт.
www.syuyumbike.ru
E-mail: suumbike@tatmedia.com
ssuum@yandex.ru
тел./факс: (843) 222-09-77
Язылу индексы:
П2204 (ПАП рәсми каталогы буенча)
73002 («Роспечать» каталогы буенча)

Банк реквизитлары:
Филиал АО «ТАТМЕДИА»
«Редакция журнала «Сююмбикә»
Расч/счет 40702810600020010309
кор/сч 30101810000000000805
в ПАО «АК БАРС» БАНК г. Казань
ИНН 1655144950
БИК 049205805
КПП 165802002



PRESSA.RU

Газинур МОРАТ

* * *

Ут төрткәннәр җәйгә –
Урман яна,
Тротуарда яна чаганнар.
Яфраклар утлы кисәү гүя –
Кызуыннан пешә табаннар.

Куркуыннан дәррәү кошлар куба –
Эмигрант кошлар! –
Бәхилләшә,
Бәхилләшә җире-суы белән,
Туган җир һәм сагыш
Гел янәшә.

Урман яна Бөек Сагыш булып –
Табигатьнең мәркәз-каласы.
Бәгыремә утлы ук кадала –
Чаганнарның шәрә карашы.




Көз моңы. Рабис Сәлахов эше.

Харрас ӘЮП

Көз

Ал кулъяулык агач башларында...
Яшеренеп болыт асларына,
Елый бүген кояш берьялгызы...
Ничек төшсен кошлар башка монда!

Урманнарда – яфрак бураннары,
Һаваларда – каурый тузаннары,
Тимерчыбыкларга бәрелә-сугыла,
Урам буйлап очты йорт казлары.

Киталмыйча безнең аралардан,
Карап тора соңгы алмалардан
Сары чәчле моңсу кызы җирнең...
Җырым белән шуны озата барам...

PRESSA.RU



БЕЗНЕҢ ТЫШЛЫКТА





14
ҺИНД ӘКИЯТЕ
Г. Сафиуллина

ЗАМАН ҺӘМ БЕЗ



8
КӨЗЛӘРДӘ ДӘ ЯЗЛАР КАБАТЛАНА
М. Авзалова

ТАТАР ДӨНЬЯСЫ



20
АК КАЛФАКЛАР ТАБЫЛЫР ЧАК
Л. Әбүдәрова

18
ЯКЛЫЙ МИНЕ, САКЛЫЙ МИНЕ...
Л. Әбүдәрова





АЛТЫН ТУЙГА СӘЯХӘТ
С. Сәлимшина-Шаһимәрданова
26

ЭЧТӘЛЕК

МӘДӘНИ ТОРМЫШ 



34 СИН КЕМ КЫЗЫ?
Л. Әблиева

ЯШӘЕШ 



42 ЧИШМӘ ҖЫРЫ
Э. Закирова



52 ИТАЛИЯ КАНИКУЛЫ
Ф. Дәүләтшина

ШУЛАЙ УК: 

12 ШУЛАЙ КИРӘК БУЛГАН
М. Авзалова

44 СИН ЯШӘСӘҢ, БЕЗ ЯШӘРБЕЗ
Л. Гәрәева

ХАТЫН-КЫЗ ГАЛӘМЕ 



58 ЭНҖЕЛЕ ХӘСИТӘ

КИЛӘСЕ САННАРЫБЫЗДА:

ИРЕМ... ДЕКРЕТКА КИТӘ.
ЗАМАН ҺӘМ БЕЗ.

БАЛА – БӘГЫРЬ ҖИМЕШЕ.
КҮҢЕЛЕҢӘ ҖЫЙМА.

БЕЗ БЕЛГӘН КОЯШ АПА.
ХӘТЕР-ХАТИРӘ.

МӘРЬЯМНЕҢ ҖИМЕШЛЕ КАБАК
БӘЛЕШЕ. МАСТЕР-КЛАСС.



PRESSA.RU

Кадерле «Сөембикә» редакциясе!



И минем газиз, гүзәл татар телем! Дөньяны танып белгән, җаныма рухи азык биргән телем! Биш гасыр буе исән калыр өчен җан тырмашкан телем. Хәлең авыр синең.

Моннан утыз еллар элек кенә бәхетле булганбыз икән. Туган телебездә белем алып та югары уку йортларына керә алдык. 90 нчы еллар – институтларда татар төркемнәре ачылган чорлар иде.

Укыган дәреслекләребез, рәсемнәре, төсләре белән тыйнаграк булсалар да, укып аңлар, дәрескә әзерләнер өчен күпкә уңайлы булганнар икән. Күнегүләрне үтәү, сорауларга җавап табу өчен интернетта да казынасы юк иде. Хәер, ул вакытта интернетның нәрсә икәнен дә белмәдек. Әти-әниләр дә янибызга утырып, дәрес әзерләшмәде. «Теге күнегүне эшли алдыгызмы?» – дип, «Ватсап»та язышмады.

Хәлең авыр, туган телем. Киләчәгең кыл өстендә. Рус балаларының әти-әниләре, иң аянычы – татарларның да «Татар теле кирәкми!», «Ирекле укытылсын!» ише плакатлар күтәреп, урамнарга чыгулары телемнең, аның белән бергә халкымның да дәрәҗәсен төшерә. Югыйсә шушы телне белеп кенә дә дөньяны әйләнеп чыгарга мөмкин диган 14 тел арасында татар теле дә бар. Шушы тел кирәксез буламы?

Яшерен-батырын түгел, нинди генә дәреслекләр әзерләп, курслар ачсак та, татар телендә рәхәтләнеп сөйләшергә өйрәнүчеләр бармак белән генә санарлык. Егерме елдан артык тырышып та ник татарча аралашырга өйрәтә алмыйбыз соң? Ник балалар бу дәресләрне көтеп алып, теләп йөрмиләр? Гаепне татар булмаган ата-аналарга гына аударып калдыру дөрес түгел. Татар теле дәреслекләре бик катлаулы. Әле татарча ун-унбиш сүз аңламаган балаларга грамматика өйрәтәбез. Татар телен Ана теле буларак укыту да шома гына бармый. Мәктәптән үк университетның филология факультеты программасы бирелә башлый. Башлангычтан ук сүз төркемнәре, җөмлә кисәкләре үтелә. Аңламый әле аны балалар, кабул итә алмый. Син аларның сүз байлыгын арттыр башта, матур җырлары, әкиятләре, хикәяләре белән таныштыр.

Узган уку елыннан башлап Татарстан мәктәпләрендә 9 нчы сыйныфларга татар теленнән имтихан керттеләр. Шуннан куркып кына да күпләр балаларын татар телен чит тел буларак укытучы төркемнәргә күчерде. Катлаулы имтиханнар белән өркетеп, татар теленең тамырын үзебез үк корытмыйбыз микән? Бәлки безгә татар теле дәресләрен кызыклырак, мавыктыргычрак итүне уйларгадыр?

Беркөн хезмәттәшем 8 нче сыйныфта укучы кызының татар теле дәреслеген алып килгән. Әни кешене дәреслектәге 11 нче күнегү (Хәйдәрова Р. З., Малафеева Р. Л. Изд-во «Татармультфильм», 2015) гаҗәпкә калдырган. Бирем үзе авыр да түгел кебек. Җөмләне генә дәвам итәсе. Әмма... ниндидер уйланылмаган, мантыйксыз кебек ул җөмләләр. «Без укытучыларга бурычлы, шуңа күрә... Мин мәктәпкә бурычлы, чөнки...» Ярар, көчен, егәрен балага багышлаган укытучыга баланың бурычы булсын да, ди. Мәктәпкә нинди бурычы бар инде аның? Баланың белем алырга хокукы турында Россия Конституциясенең 43 нче маддәсендә язылган түгелме соң? Хокукы бит ул аның! Менә тагын бер очрак. Анысын да хезмәттәшем сөйли. «Ишегалдындагы киоскта су сатучы татар хатыны 4 нче класстагы оныгына татар теленнән дәрес әзерләшүемне үтенде. Берничек тә булыша алмыйбыз, безнең баш җитми ди. Мин – югары белемле филолог, шактый утырдым ул биремнәр белән. Өй эшен күп бирәләр икән. Калын һәм нечкә кушымчалар белән 15 ләп яңа сүз ясарга, аларның нинди сүз төркеменә ялганып ясалганын, яңа сүзнең нинди сүз төркеменә караганын ачыкларга. Шулар белән җөмләләр төзергә; 10-15 парлы сүз ясарга; рәсемгә карап кечкенә хикәя язарга. Түбәсе күккә тию, еракка китеп кара кебек сүзтезмәләрнең мәгънәви ягын аңлатырга. Дәреслек авторлары кемне күздә тотып төзеделәр икән?» – дип гаҗәпләнә ул.

Программаның катлаулы булуын укытучылар үзләре дә таный. Бервакыт Татарстан мәгариф министры урынбасары Илдар Мөхәммәтов, программаны үзгәртми булмый, кебегрәк сүзләр әйткән иде.

Татар телен яратмыйлар, дип, кемнедер гаепләгәнче, кызыклы һәм мавыктыргыч укыту методикасы булдырыргадыр, бәлки, безгә.

Лилия ЗӘЙНУЛЛИНА.
Казан.

Хатын-кызның бәхете ир-ат кулында, диләр, дөрес сүз. Моның чынлап та шулай икәнлегенә Гөлзаданың язмышы белән танышкач инандым.

Гөлзадә авылда, тугыз балалы гаиләдә туа. Кечкенәдән эшләп үсә, хезмәт тәрбиясе ала. 15 яшендә Яшел Үзәнгә китеп, училищега укырга керә. 1975 ел була бу. Студент кызны тулай торакка урнаштыралар, кием бирәләр, хәтта бушлай ашаталар да. Җәннәткә килеп эләккәндәй тоя үзен Гөлзадә. Авылдагы кебек, исерек әтиләре дә тынычлыкны бозмый, тамагы да туяр-туймас йөрми.

Училищеда укыганда ук фанера заводына эшкә урнаша. Балалыгы да чыгып бетмәгән 16 яшьлек кыз өчәр смена эшли, исеме Мактау тактасыннан төшми. Биредә өч ел эшләгәч, «Серго» заводына күчә. Монда да өчәр смена хезмәт куя – торак алырга өметләнә. Алны-ялны белми ун ел буена эшли шулай. Аннары контролер итеп күчерәләр, эше дә, ниһаять, бер генә сменага кала. Бергә эшләгән Равия исемле хатын аны апасының улы белән таныштыра.

Рәшит – әти-әнисенең бердәнбер улы, чиста-пөхтә егет. Җиде ай очрашып йөргәннән соң, яшьләр өйләнешә. Гөлзадәне тулай тораҡтан яхшы машиналарда алып китәләр. Ике көн шәһәрдә туй иткәннән соң, тагын ике көн авылда гөрли әле бәйрәм.

Алар Рәшитнең әти-әнисе белән яши башлый. Соңрак Гөлзадә тулай тораҡтан бер бүлмә ала. Дүрт ай тыныч кына уза. Аннары ир үзгәрә – кунарга кайтмый, кайтса да, таң алдыннан гына исереп кайтып егыла. Берсендә тоташтан биш көн кайтмый. Гөлзадә инде әллә нәрсәләр уйлап бетерә. Бәхеткә, үзе кайтып керә тагын.

Тора-бара фатирдан әйберләр югала башлый, хәтта капчык-капчык бәрәңгегә кадәр «аяклана». Әллә барысын да ташлап авылга гына кайтып китимме, дигән уй да килә Гөлзадәнең башына. Тик авылдашларыннан ояла. Әнисе дә: «Берегезне дә көчләп бирмәдек, баргансыз икән, түзегез. Мин түздем бит», – дип кенә тора. Бәлки, бала тугач, үзгәрер, дип тә уйлагандыр инде.

Бервакыт авылдан кайтып килгәндә Рәшит киндер кырында машинаны туктата да, ике капчык киндер җыя. Кайткач, Гөлзада бу хакта кайнанасына сөйли. Әни кеше, каушап, коелып төшә һәм теге үләнне чүплеккә чыгарып ыргыта. Кич аны Рәшит чүплектән кире алып кереп, бәдрәф бүлмәсенә кереп бикләнә. Озак чыкмый торгач, нишли бу, дип, ишекне барып ачса, ире киндер төя. Имеш, дусты Гришаның теше сызлый икән, бу шуңа дару ясый. Беркатлы хатын ышана...

Икенче балалары тугач, Гөлзадәдә кан агулану – сепсис башлана. Сигез ай урын өстендә ята. Шул вакытта балаларын караган өчен әле дә кайнанасына рәхмәтле ул. Ә Рәшит исә вакытны бушка уздырмый, тулай тораҡтагы кызлар белән «типтерә».

Гомер бара. Балалар акрынлап үсә, Гөлзадә белән Рәшит «Серго»да эшлиләр. Ниһаять, аларга кухнясы өч гаиләгә уртак фатир бирәләр. Гөлзадәнең әтисенең сеңлесе Нурсөя апалары да шушы ук фатирда яши. Күршедәге гаилә икенче фатир алып чыгып киткәч, ул бүлмә дә Гөлзадәләргә кала. Шулай итеп, Нурсөя апасы белән бер гаилә булып яши башлый алар. Әмма туганының хәле көннән-көн авырлаша, хәтта кашык тотып ашый алмас була. Рәшит баштарак аңа карата мәрхәмәтле булып кыланса да, соңрак җәберзолымны кызганмый башлый. Гөлзадә апасын унҗиде ел буена карый, берүзе күтәрә, берүзе юындыра. Берсендә ире исереп кайтып, бик холыксызлана башлагач, балаларын алып, өйдән чыгып кача, ә Нурсөя апасы берүзе ятып кала. Бичара хатын бу төнне мең кат үлеп, мең кат терелә. Үтерәм мин сине, дип, Рәшит аны мендәр белән дә томалый, пычак белән дә яный. Ике баласын ияртеп, Гөлзадә иртәнге дүрттә генә кайта. Фатир ишеген ачучы булмагач, кече улын форточкадан кертә. Бичара Нурсөя апасы төнлә булган хәлләрне тотлыга-тотлыга сөйли. Гөлзадә аны башкача ялгызын гына беркайчан да калдырмый.

Иренең эчүенә дә, холыксызлануына да күнә ул. Кешеләр исерек ир белән дә яшиләр бит. Тик наркотик иснәвен дә белгәч, бөтенләй югалып кала. Өстәвенә, ата кеше 17 яшьлек улын да үз артыннан ияртә, тора-бара алар наркотикны иснәп кенә калмыйлар, кадала ук башлыйлар. Ирен генә түгел, баласын да бу баткактан йолып кала алмаган хатын яшәү мәгънәсен бөтенләй югалта.

Ә бөркөнне... ирен ванна бүлмәсендә асылынган килеш таба ул. Бер ай элек кенә Нурсөя апасын җирләгән хатын, инде ирен җирли. Алга таба тынычлап яшәрбез, бәхетсезлекләр артта калды, дисә дә, насыйп булмый. Өйләнеп, матур гына яши башлаган, оның сөю бәхетен биргән Рөстәмнәренең үле гәүдәсен алып кайтып салалар. Наркотиклар башына җитә аның. Кече улы Рамил дә гомерсез булып чыга – абыйсының вафатына биш ел булганда, аның да йөрәге тибүдән туктый. Ул да этил спирты һәм ниндидер таблеткалар белән агуланган булып чыга.

«Бер-бер артлы барысын да югалтырмын дип уйламаган идем. Ике балам һич кенә дә күз алдымнан китми. И Аллам, акылыма гына зәгыйфьлек китермә. Урын өсләренә калдырганчы, җанымны күкләргә, улларым янына ал», – ди Гөлзадә. Ачы язмышы өчен ирен каргамый ул, яшьлегем, юләрлегем аркасында наркоманнан бәхетсез балалар таптым, дип үзен битәрли. Кияүгә чыкканда кызлар балаларына яхшы әти булырдай егетләрне сайласыннар иде ди.

Сөмбел МОГЫЙНОВА.

Хөрмәтле укучыларыбыз!
Сездән хатлар көтеп калабыз.
Безнең адрес: Казан, Декабристлар урамы, 2.
e-mail: ssuum@yandex.ru

PRESSA.RU



КӨЗЛӘРДӘ ДӘ ЯЗЛАР КАБАТЛАНА...



Мәдинә
АВЗАЛОВА

КАРТАЙМЫШ КӨНЕҢДӘ ЯЛГЫЗ КАЛУДАН ДА АВЫР НӘРСӘ БАР МИКӘН УЛ? СҮЗЕБЕЗ ТӘРБИЯГӘ БӘБИ ТҮГЕЛ, ӘБИ АЛГАН, УЛ ӘБИНЕ БӘБИ КЕБЕК КАРАГАН ГАИЛӘЛӘРНЕҢ БЕРСЕ ТУРЫНДА.

Сентябрь урталары... Әле кайчан гына агачлар яшеллеккә күмелеп, дөнья шау чәчәктә утыра иде. Җылы җәйләр дә бер дә китмәс, сагындырып-юксындырып кына кыздырып алган кояш та мәңге сүрелмәс сыман иде. Соңгы җылы нурларын азга гына күрсәтеп алып, кул да изәмичә китеп барган быелгы кыска җәй артыннан тагын кара-салкын көзләр килде. Агачлардан җиргә шыбыр-шыбыр сары яфраклар коела. Өлкәннәр көненең көзгә – октябрь аена туры килүе очраклы түгелдер. Гомер көзләре дә агач ботагында көч-хәл белән ябышып торган сары яфрак шикелле бит. Җил катырак исә башласа, ул аны ботагыннан тартып ала да һавага очырта, агачыннан еракка-еракка алып китеп, йә сукмакка, йә олы юлга ук чыгарып ташлый.

Әңгәмәдәшем – Чаллы шәһәрендә яшәүче Мәрьям Шәех кызы Габдрәфикованың сөйләгәннәре шулай тәэсир иттеме, әллә тәрәзә артында гына посып торган үз көземнең салкыны тиеп киттеме, ниндидер бер ят тойгы кичереп, сискәнеп куйдым.

Әнием, күз нурымның үзәкне өздереп әйтә торган бер сүзе һич истән чыкмый: «Инде, кызым, картайган көндә урын өсләренә генә калырга язмасын. Сезне тилмертергә генә язмасын, – дия иде дә, – кеше кулларына гына калырга язмасын», – дип, үзәгемне өзеп өстәп куя торган иде. «Ничек инде кеше кулларына... Ә без кайда, без нигә?!» Бәлкем, ул шулай дигәндә, үзен күз алдында тотып та әйтмәгәндер. Кешене картайган көнендә ни көтәсен күзаллап кына әйткәндер. Ул беркемне дә «тилмертмичә» тиз арада арабыздан китеп барды. Теләгәне тормышка ашты. Киткәнен сизми дә калдык...

«Әнием кайткан кебек булды»

Аның әнисе – алты бала анасы Гайшә апа да: «Кулдан-кулга йөрмәсәм генә ярый инде», – дип, гел бер сүзне кабатлый торган булган. Кулдан-кулга йөрмәгән, аны гаиләдә бишенче бала булып туган, арада шәфкатьлесе – шул Мәрьям тәрбияләгән дә инде. Унике ел караган ул авыру әнисен. 82 яшендә пычак астына кереп яткан әбинең хәле операциядән соң да әллә ни булмаган. Начар авыру үзенекен иткән. Шуңа да карамастан, ул 89 яшенә җитеп, дөнья куйган.

«Ике атнага гына, дигән иде. Бөтенләйгә калдырдык».

– Әни безне эшләтеп, бәлагә төшкән кешегә ярдәм итәргә кирәклеген аңлатып үстерде, – дип сөйли Мәрьям ханым. – Без бөтен күрше-күләннең өен җыештырып, кирәкле йомышларга йөреп үстек. Шулай үстерделәр безне. «Синеке, минеке», дип тормадык. Әни үлгәч, еладым да еладым. Бик юксындым. Өемдә бер өлкән кеше булмаса, дөньялар ятим калган сыман була бит ул. Үз-үземне кая куярга белмичә йөргән көннәрнең берсендә ирем (ул отставкадагы полковник) кулыма газета алып кайтып тоттырды. «Укып кара әле», – ди бу миңа. Күземне генә салдым, шундук аңлап алдым: сүз Өлкәннәр йортындагы карт-карчыкларны тәрбиягә алу турында бара иде. Миңа бит миңа нәрсә кирәк! Шундук «Доверие» социаль хезмәт күрсәтү үзәгенә шалтыраттым. Анда эшләүче хезмәткәр турысын әйтте дә салды: «Юк, – ди, – Чаллы йортыннан берәүнең дә китәсе килми». Берничә көннән үзәк җитәкчесе Эльвира Мифтахова чакырып алды да безнең белән сәгать ярым сөйләште. Аннары гына: «Алабугада теләүчеләр бар», – дип, шунда барырга тәкъдим итте. Җыендык та киттек ирем белән. Тугыз яшьлек улыбыз Диниярны да ал-

Фото: Рочев Кирилл

БӘБИЛӘР ҺӘМ ӘБИЛӘР

Хөкүмәтебезнең «Өлкән кешеләрне тәрбиягә алу» проектын гамәлгә ашыру турында»гы карары бүгенге көннең иң актуаль юнәлеше дип кабул ителә. Чөнки ел саен республикада өлкән яштәге гражданнарның саны 2,5 процентка арта тора. Шуның белән бергә ялгыз яшәүче карт-карчыкларның саны да арта.

Проектның максаты – үзләрен карый алмаган өлкән кешеләрне гаилә шартларында яшәтү.

Былтыр әлеге проект унҗиде регионда кулланылды. Быелдан – бездә.

Ул социаль хезмәт күрсәтү учреждениеләрендә яшәүче 55 яшьтән өлкән хатын-кызларга, 60 тан өлкән ир-атларга, Татарстанда ялгыз яшәүче өлкән кешеләргә дә, инвалидларга да кагыла.

Гаиләсенә тәрбиягә өлкән кешене алган гаиләгә айлык түләүләр:

- инвалид булмаган һәм 3 нче группа инвалид кешене караган өчен – аена 4 мең сум;
- өлкән яштәге 2 нче группа инвалидны караган өчен – аена 6 мең сум;
- 1 нче группа инвалидны тәрбиягә алган өчен – 8 мең сум акча.

Моннан тыш, карт-карчыклар, Килешүдә каралганча, гаилә бюджетына пенсиясенең 75 процентын биреп барырга тиеш була.

Өлкәннәрне тәрбиягә алучы гаиләләргә дә җитди таләпләр куелган: Әйтик, ул кешенең үз йорты, үз мөлкәте булырга тиеш. Барлык гаилә әгъзаларыннан рөхсәт алынырга тиеш. Начар, йогышлы авырулы, кайчандыр хөкемгә тартылган булмаска, ярты еллык эш хакы яшәү минимумыннан ким булмаска тиеш.

2016 елда гына да өлкән яштәге 17890 кешегә социаль ярдәм күрсәтелгән.

14294 се – хезмәткәрләрнең даими игътибар үзәгендә.

PRESSA.RU

дык. Мин аны бик соңлап – 42 яшемдә генә таптым. Кызларымның берсе – Айназы – Казанда. Ул – полиция майоры. Кияүдә, бер кызы бар. Айсылуым – Чаллыда, анысы ике малай үстерә. Шулай итеп, дүрт бүлмәле фатирда без өчәү утырып калдык.

Хәзер генә ул «җыендык та киттек» дию җиңел. Ә ул чагында... 4 ноябрь көне, бөтен дөньяны кар баскан, котырыпмы-котырып буран улый. Җитмәсә, иртәнге як та түгел. Эштән соң кузгалдылар. Ярый әле Алабуга белән Чаллы арасы – кул сузымында. Көткәннәр икән аларны. Ишек төбенә үк чыгып каршы алдылар. Һәм... бер бүлмәгә алып менеп киттеләр.

– Килеп кердек, – дип сөйли хәзер Мәрьям ханым, – ике караватбелән бәләкәй суыткыч кына сыярлык кечкенә бүлмә. Ә караватта бәләкәй генә бер әби утыра. Күрүгә, йөрәгем жу-у итеп китте. Килдем дә кочаклап алдым. «Сине алырга килгәннәр. Барасыңмы?» – дип сорый җитәкчеләре. Ә ул: «Бараммы соң? Юк, юк... Миннән файда юк, бала карый алмыйм, ашарга пешерә алмыйм. Мин – гарип», – ди. Каршы инде, каршы... Барасы килми. Тагын иңеннән кочып алдым: «Барып кара әле, дим. Кунакка бар. Ошатсаң, калырсың. Ошатмасаң, кире илтеп куярбыз...» Шулай дигәч, килеште әбиебез. Ул намазлы карчык. Китапларын гына алды да безгә иярде. Кечкә сәгать уннар тирәсе иде микән, кайтып җиттек. Ул, ишектән килеп керүгә үк, стенада эленеп торган «Аятел көрси»не күреп алды. Шуңа башта бик куанды. «Догалы йорт», – ди. Аннары без аңа өйне күрсәтеп чыктык, соңыннан гына ул яшисе зур бүлмәгә алып кердек. Хәйран калып басып торды. Бераздан елый ук башлады. «Аллаһы Тәгаләнең рәхмәте яусын сезгә», – ди.

Өлкән яшьтәгеләрнең саны ел саен 2,5 процентка арта тора.

Ике генә атнага дип килгән әби, Габдрәфиковлар гаиләсендә кала. Лена Бакирова бу өйнең лаеклы әгъзасына әйләнгәнче биш ай вакыт үтеп китә. Документлар тутыру мәшәкатьләре, рәсми тикшерүләр, әбигә 1 нче группа инвалидлык документы алып бирү мәшәкатьләре... хәзер инде барысы да артта калды. Шул кыска гына арада да әбекәй гаиләнең иң кадерле, иң яраткан кешесенә әверелде. Мәрьям ханым эштән кайтуга иң беренче әбинең ишеген ачып карый. Башта ул курка-курка гына кайта иде. Сагынмыймы икән, китәм дип әйтмәсме икән? Хәзер инде аның күңеле тыныч. Карчыкка монда җан рәхәте. Нәрсә ашыйсы килсә – шул бар. Хуҗабикә – аш-су остасы да әле. Тиз генә бәлешен дә пешерә, әби яраткан башка тәм-томнарны да күз ачып йомганчы әзерләп куя. Аның «тәмле булган» дип, мактый-мактый ашаулары Мәрьямгә әнисен хәтерләтә. Хәер, бу әбигә дә ул «әни» дип дәшә. «Әни, әйдә, бәлеш ашыйбыз. Әни, әйдә, чәй эчәбез...» Йөрәгенә якын кабул иткән кешегә бәхет бит ул! Киң күңелле кешегә яшәүләре мең рәхәттер ул.



Шул кыска гына арада да әбекәй гаиләнең иң кадерле, иң яраткан кешесенә әверелде.

Әбинең чыгышы, кай яклардан булуы белән кызыксынам. Мәрьям Шәеховна бу хакта ачылып китеп сөйләргә яратмый. Лена әби үзе Оренбург якларыннан. Озак еллар Үзбәкстанда яшәгән. Аннары, дөньялар тынгысызлана башлагач, Санкт-Петербургка кайтып урнашканнар. Аның бер кызы, бер малае бар. Ләкин әби аларның берсенә дә сыймаган. Моңа кадәр 13 ел ул әле бер картлар йортында, әле икенчесендә кагылып-сугылып йөргән.

«Балаларына бер дә сүз әйттерми, – ди олы йөрәкле ханым. – Килә алмыйлар. Аларның акчалары юктан башканы әйтми. 15 майда әбиебезгә 82 яшь тула». Бәлкем, шунда кайтып китәрләр... «Ой, белмим, – ди ханым, икеләнә калып, – Кайтырлар микән?»

Дөрес, кызы белән телефоннан хәбәр алышып торалар икән алар. Кызы дигәнебез Мәрьям яшьләрендә булыр. «Сөйләшкән саен рәхмәт әйтә», – ди әңгәмәдәшем. Хәзер ирле-хатынлы Габдрәфиковлар әбинең сәламәтлеген ныгыту белән мәшгульләр. «Мин аны атнасына ике юындырам, киемнәре күп аның хәзер, бөтен кирәк-яракны сатып алдык», – ди Мәрьям Шәеховна.

Яше сиксәнне узган кешене карау җиңел түгел. Ләкин ул һич тә зарланмый. «Әбине китереп утырткач, әни кайткан кебек булды», – дип сөенә.

Ялгызлык куркыта

Бу сүзләрне еш ишетәм. Соңгы көннәрен интернат-йортларда кичергән карт-карчыклар янына баргач та, үзара сөйләшкәндә дә... Ялгызлык шундый нәрсә шул инде ул. Куркыта... Гомерең офыкларга авышкан бер мәлдә, бу дөньяда бөтен борчу-мәшәкатьләрең белән япа-ялгыз торып каласың икән, сине бары бер нәрсә борчый: соңгы сулышымда янымда кем булыр? Кайчандыр алдынгы эшче булган, аласы бөтен хөкүмәт бүләкләрен алып бетергән, ә бүген исә әкренләп җыелган чирләре белән япа-ялгыз калган (карчык дип тә әйтәсе килми) ханымны шул борчый. «Янымда авызыма су салып торучы да булмаячак бит минем», – ди ул. Аны мәсьәләнең матди ягы кызыксындырмый. Кайчак күрше-күлән кертеп чыккан азык-төлек тә, әйбәт кенә алган пенсиясе дә кызыксындырмый. «Хәлемне белешергә дип, бер кереп чыксалар да...» – ди ул, шуңа да канәгать булачагын сиздереп.

Стюардесса булып эшләүче Диләрә Газинур кызы Каюмованың: «Иң мөһиме – аралашу», – дигәнен бик тә аңлыйм. «Мондый аралашу күбрәк минем үземә кирәк», – дигәнен дә аңлыйм. Кем белән аралашасың бит... Ни хакта гәп куертасың бит... Очраклы гына булган танышуның менә шулай елларга сузылачагын, танышы, хәер, хәзер инде якын кешесенә әверелгән хезмәт ветераны өчен генә түгел, иң элек үзе өчен мөһим булачагын күз алдына да китереп карамагандыр ул.

– Идел буе районының Дубравная урамында урнашкан Ветераннар йорты турында ишетеп беләсездер, – ди Диләрә Каюмова. – Ветераннарның һәркайсы үз фатирында яши. Аларны ашатып-эчертеп, фатирларын җыештырып торучы комендантлар, азга гына да биредә яшәүче сугыш һәм тыл ветераннарын күз уңыннан калдырмыйлар. Бер мәртәбә дус кызлар белән Җиңү көне уңаеннан шунда концерт куярга барган идек. Аннары бу гадәткә кереп китте. Шулай аралаша башладык. Еш кына беркая чыга алмаган, үз бүлмәләрендә бикләнеп яшәргә мәҗбүр булган әби-бабайларга ни җитмәвен аңлыйсыз инде. Әлбәттә, аралашу җитми. Мин дә шуларның берсе белән таныштым. Нина Андреевна Сивцовага әле күптән түгел генә 94 яшь тулды. Мин аны, сөйләшү рәвешенә карагандa, гел Фаина Раневскаяга охшатам. Аны тыңлаган саен тыңлыйсы килә. Мин аның яныннан күпме энергия, көч-куәт алып китәм. Ул мине бик күп нәрсәгә өйрәтә, акыллы киңәшләрен бирә. Күпне күргән бит ул. Гомумән, беренче мәртәбә сөйләшкәндә үк мин аны күптәнге танышым сыман кабул иттем. Әйтерсең, бер-беребезне йөз ел беләбез. Сөйләшеп сүзебез бетмәде. Безнең дуслык менә инде өч ел дәвам итә.

Диләрә инде якын кешесенә әверелгән сугыш ветераны турында яратып, хөрмәт белән искә алып сөйли. Нина Андреевна фронтка 18 е тулыр-тулмас 1942 елны киткән. Сугыштан соң биш ел Германиядә, аннары 25 ел Балтыйк буе илләрендә яшәгән. Шуннан соң гына ул Татарстанга кайткан.



– Ул гаҗәеп кеше, – ди Диләрә. – Күз алдына китерегез: кеше 80 яшенә чаклы производство җитәкчесе булып эшләсен әле?! Озак еллар авыл совет депутаты булып та торган. Ә күпме кешегә булышкан ул?! Хәзер дә булыша, – ди ул һәм бераздан өстәп куя, – миңа булыша. Киңәшләре, кайчак җылы сүзләре белән... Ул бит үзе бер шәхес, үзе бер дәвер...

Сугыш ветераннары өчен төзелгән әлеге муниципаль йорт 2008 елны куллануга тапшырылган. Ул 91 бүлмәле фатирдан торган биш катлы бина. Башка йортлардан кай ягы белән аерылып тора дисезме? Аның үз ял итү бүлмәсе, дәвалау-физкультура кабинеты, терапевты, стоматологик поликлиникасы булган медицина офисы бар. Әллә кая да китәсе юк, ярдәм үзләрендә генә.

...Адәм баласына картаймыш көндә әллә ни күп тә кирәкми: яратсыннар, үз итсеннәр аны. Кирәклеген, аның артык кашык булмавын һәрчак кабатлап торсыннар гына. Ялгыз калган карт-карчыклар моңа бигрәк тә мохтаҗ. Дөньяны игелек тота, дибез. Әйе, игелекле кешеләр тота. Җирдәге фәрештәләр тота.

PRESSA.RU



ШУЛАЙ КИРӘК БУЛГАН

«УЛ ЗАМАНДА ЭШЛӘГӘН ТЕРЛЕКЧЕНЕҢ ҺӘРКАЙСЫНА ОРДЕН БИРЕРЛЕК», – ДИ ӨЧ ОРДЕН КАВАЛЕРЫ.

«Аллага тапшырып, киләсе елның җәенә 78 тула», – дип торган Мәрьямниса апага бер дә ул яшьне бирәсе килми әле. Карап торуга кызлар кебек. Шулай дигәч, ул рәхәтләнеп бер көлеп куя. Аякларының сызлавына да әллә ни исе китми. Заман чире, хәзер аягы авыртмаган кеше юк ул, янәсе. Үзен шулай дип тынычландырамы, безгә зарланып торуны кирәк санамыймы... Хәер, сугыш чоры балалары тормышны да, алар җилкәсенә төшкән авырлыкны да шулай кирәк булган дип кабул итә. Бөтен җире җитеш, бар уңайлыклары булган җыйнак кына өенең кухнясына әледән-әле кагылып, плитә тирәсендә кайнашкан ханымга нидер әйткәләп, безнең игътибарны үзенең яшь чагында төшкән фоторәсемнәргә юнәтеп, әкрен генә, үз җаена сөйли дә сөйли ул. Фоторәсемнән безгә толым-толым чәчләре биленә кадәр төшкән 15-16 яшьләрдәге кыз бала карап тора.

– Мин, – ди ул, сокланып торуыбызны күреп.

– Яшь әле сез монда, бала гына...

– Фермада эшли башлаган чагым, – ди Мәрьямниса апа. – Фермага эшкә килгәндә миңа 15 яшь иде. Дөресен әйткәндә, мал янына килергә дә курка идем. Ярый әле башта тавык карарга куйдылар. Сыерлар янына өч елдан соң гына тәвәккәлләдем. Бу – 1958 ел иде. 40 ел гомерем шулар янында узган да киткән менә.

Кызык бит язмыш дигәнең... Аның әтисе Мәүли абзый, хатынын һәм өч баласын алып, вербовка белән Карелиягә чыгып киткәндә, Саба районының менә шушы гөрләп торган Мамалай авылына кире әйләнеп кайтасын күз алдына да китерә алмагандыр. Ил гизеп, дөнья күреп, сәфәр дигән гамәлнең кызыгын да, михнәтен дә туйганчы татып, туган нигезгә кайтып җиткәнче, аларны әле күрмеш җилләре элгәре Ташкент дигән серле калага китереп ташлый. Өч еллап ул каланың татлы җимешләрен татыганнан соң гына Мәүлиевләр гаиләсе юлга кузгала. Күңел тарта, җан тарта... Ә нәрсә кайтмаска? Әтиләре – кулында ут уйнатырдай балта остасы. Кайтуга ук авыл уртасында менә дигән йорт калкып чыга. Ул вакытлар өчен ни зиннәтле капкалар да, бүгенгедәй икешәр катлы зур-зур өйләр дә кирәк булмаган. Иң мөһиме: җил капкалы булса да, шыңгырдап торган бүрәнәдән салынган яңа өй!

Дүрт бала арасында иң зурысы булган Мәрьямниса мәктәптә озак кинәнми. 15 яше тулуга кыз, әтигә авыр дип, үзе теләп, фермага эшкә килә. Әнисендә йөрәк чире, әтисенең дә юк-юк та сугышта алган яралары кузгалып тора. Өйдә берсеннән-берсе бәләкәй өч бала... Кыз үзен алар язмышы өчен дә җаваплы тоя, күрәсең. Шулай башлана аның хезмәт юлы. Бу һөнәр ошыймыюкмы дип сайланып тору да юк. Кирәк икән, эшлисе! Бәлкем, шуңадыр да ул хәзер үзенең уңышларын: «Эшләгән дә эшләгән инде...» – дип, бер җөмлә белән чикли. Кайчак аның тыйнаклыгына хәйраннар калып торасың. Ничек кенә эшләгән әле?! Районның профсоюз лидеры Дания Мулланур кызы Галимуллина әйтмешли, өч орденлы олпат сыер савучы бит ул! Дөрес, бер караганда: «Эшләгән дә эшләгән!» Көнне

төнгә ялгап эшләгән шул арада бер-бер артлы ике Хезмәт Кызыл Байрагы ордены, аннары Ленин ордены алырга да өлгергән. Социалистик Хезмәт Герое исемен алырга гына өлгерми калган. Советлар Союзы таркалган. Тик ул бүләкләренә бик канәгать. «Рәхмәт, хезмәтемне күрделәр, олыладылар» сүзеннән башканы әйтми. Анысы шулай. Эшләгән, тырышкан кешенең хезмәтен күрә белү – үзе бер сөенеч бит ул.

– Вакыт та бара, заман да үзгәрә. Бүгенге фермаларны элеккеге, сез эшләгән вакытлардагы фермалар белән чагыштырып булмый. Аермасы – җир белән күк арасы.

– Әйтсәсе дә юк, – ди Мәрьямниса апа. – Чагыштырырлыкмы соң? Азыкны да малларга трактор тарата, сыерларны да аппарат белән савалар дип сөйлиләр.

– Үзегезнең бер дә барып күргәнегез юкмы?

– Юк шул, – ди ул уңайсызланып. – Эшләгән кеше арасында буталып йөрүдән уңайсызланам. Инде хәзер күпкә җиңел дисәләр дә, бик җаваплы аларның эшләре.

Ул үзе белән булган хәлләрне сөйләп ала. Әле көлдерә, әле уйланырга мәҗбүр итә... Җәелеп китеп, озаклап сөйләми, үткән көннәренең бер генә мизгелен кузгатып куя. Ә безгә шунысы да җитә: әнә, яшь кенә бер кыз бала, озын чәч толымнарын уйнатып, сыерлары янында арлы-бирле йөренә. Әнә аның 43 нче размерлы резин итеге аягыннан төшеп кала. Аягы пычрана. Кыз, кире килеп, пычрактан итеген тартып чыгарып, кабат киеп куя. Пычрак шул ферма эче, чистартып бетерерлек түгел. Бер кул бит, барына да өлгереп булмый. Әнә ул, кулына сәнәк алып, малларына салам сала башлый. Бер очтан икенчесенә чыгып җитеп, су салырга керешкәнче, сыерлар саламны ялт иттереп куя. Кыз борчылып куя: азык җитми малларга, әнә ничек тиз ялтыраталар. Әнә кыз аларга чөгендер таратып чыга да, шундук беренче торган сыер янына килеп, чүгәләп, сава башлый. Тора-бара Мәрьямниса иң алдынгы сыер савучыларның берсе булыр әле. Башкалар елына бер сыердан 1000, иң күбе 2000 литр сөт савып алганда, аныкы 3000 литр булыр. Әйе, әйе, заманы өчен аның бу кадәресе дә бик күп булган. Хәзер генә ул бу күрсәткеч 9000 чикләрен үтте. Һаман да шул кул хезмәтенең чүпкә чыгуы, тарихта кала баруы сәбәпче моңа.

– Ул заманда эшләгән терлекченең барысына да орден бирерлек, – ди ул. Һәм үзегенә үткән тагын бер мизгелне яңартып ала: – Берара маллар арасында тилчә таралды. Начар чир ул. Сыерларның җилемнәре бозыла башлады. Бертуктаусыз селәгәйләре ага. Без ул вакытларда җәйләүдә көн-төн кунып яттык. Учак яга идек тә, ашарга пешереп ашый идек. Әмма терлекләрне азга гына да ялгыз калдырмадык. Сөтне савабыз да түгәбез, савабыз да түгәбез. Шулай бер айга кадәр дәвам итте. Аннары, әкренләп, терлекләр хәлләнә башлады. Зур сынау булды ул безнең өчен.

– Бөтен эшне кулдан эшләүнең бер әйбәт ягы булгандыр инде ул. Әйтик, маллар сезне кулыгыз белән килеп кагылуга ук сизгәндер.

– Арада керебеткәннәре дә очрый иде, – дип елмая Мәрьямниса Мәүлиева. – Бер сыерым сөтен «урлап»



кала башлады. Нәкъ шундый вакытларның берсендә районнан җитәкче килеп төште. Фермалар буенча йөри торгач, шул бур сыерым каршына килеп басты. Ә мин, ахыргача саудырмагач, яныннан китеп, икенче сыерның җилемен юарга керешкән генә идем, бу аның янына килеп утырды да чыжылдатып саварга да тотынды. Артыма чак кына авып китмәдем. Кара син аны, җүнсезне дим, миңа сөтен бирмәде, ә бер белмәгән кешегә, зинһар, ал гына, янәмәсе. Шулай да була. Савым сыер бит ул, вакытында саумасаң, әллә каян үкереп, ярсып кайта. Саумадылар диюе.


Мамалай фермасы элек тә алдынгылар исәбендә йөргән. Хәзер дә данлыклы хуҗалыклардан санала.

Гомерен гел хезмәткә багышлаган кеше ул. Мәрьямниса апа ире вафатыннан соң кайнанасын 92 яшенә кадәр тәрбияләп, соңгы юлга озата. Пенсиягә чыккан елны ул төп нигезенә – үзе әйтмешли, бер урамнан икенче урамга күченеп кайта. «Үз әнием дә 91 яшендә минем кулда вафат булды», – ди ул.

Бүген л ялгыз түгел. Янында – якын туганнары. Кухняда аңа аш-су әзерләп йөргән ханым – сеңлесе Зөләйха булып чыкты. «Мин хәзер бернәрсә эшләмим. Суыткычыма ризыкны алып килеп тутырып куялар. Әзерләп ашаталар. Өйләремне җыештыралар, йомышыма йөриләр. Бу өйгә чыкканга да өченче ел китте инде». Рәхмәт аларга, дип, өй салырга булышкан олы җитәкчеләрне мактап та ала. Шулай инде, өлкәннәргә, гомерен хезмәткә багышлаган кешеләргә күрсәткән хөрмәт, игътибар алтыннан да кыйммәт бу заманда.

Мәдинә АВЗАЛОВА

PRESSA.RU



ҺИНД ӘКИЯТЕ

Голнур
САФИУЛЛИНА

«Матурлык бәйгесендә катнашырга телим», – дигәч, ирем шунда ук: «Юк!» – диде... Нәкъ өч көннән соң исә ризалашты. Шул вакыт мин бер нәрсәне аңлап калдым: аның «юк» дигәне «әйе»гә дә үзгәрергә мөмкин икән... Тамчы да ташны тишә... Гүзәллек бәйгесендә катнашып карау балачак хыялым иде. Тик бит минем буем 155 сантиметр гына... Ә «Миссис Иркутск» бәйгесендә буемның озынлыгына борәү дә игътибар итмәде, анда иң төп таләп – хатын-кызның әни булуы иде. 2013 ел бу. Мин ул чакта ике бала әнисе...

Иркутск сәхнәсеннән аны: «Якташыбыз, бүгенге көндә Һиндстанда яшәүче Рәйсә Нирадж Вед-Закирова», – дип игълан итәләр. Тамашачы алдына 16 яшьлек улы Вигян һәм 3 яшьлек кызы Нивен белән чыккан Рәйсәне күпләр хәтерләп кала ул чакта. Саридан булганга гына түгел, әлбәттә. Сөйкемлелеге, үткенлеге, үз-үзен тотышы белән аерылып тора ул. Тагын әле язмышы белән дә.

Рәйсә – Иркутск кызы. Аның Маһинур әбисе белән Зәйтүн бабасы өлкәнең Черемховск районы Зерновое авылында бердәнбер татар гаиләсе була.

– Әти белән әни аерылышкач, мин мәктәпкә кергәнче Зерновоеда яшәдек, – дип сөйли Рәйсә. – Әбием белән бабамның төп чыгышлары Татарстанның Актаныш һәм Мамадыш районнарыннан. Башта алар Бурятиягә күченеп киткәннәр, аннан, илленче еллар уртасында Зәйтүн бабам, «килүгә үк фатир бирәбез» дигәч, яшәр өчен шушы авылны сайлаган. Аларның килеп төшүе Зерновое өчен вакыйга булган. Кулларында чемодан, тегү машинасы, яхшы киенгәннәр, чибәрләр... Бабам тырыш кеше иде, гомер буе ике-өч эштә эшләде. Авылда абруйлы гаилә булдылар. «Әтәйнең әнисе олыгайган көндә безнең белән яшәде, – дип искә төшерә әнием. – Динле, укымышлы карчык. Бабам Насыйр Дусай авылында мулла булган, әби дә балаларга гарәп теле укыткан. Зерновоега килгәч тә әби башыннан ак яулыгын салмады. Тирә-юньдәге халык аңа куркулык койдырырга, өшкертергә йөрде».

Авылда ерак әбием Фатиханы бик хөрмәт иткәннәр, женазасына Зерновоеның бөтен урысы җыелып килгән.

Маһинур әбисе белән Зәйтүн бабасы туган якларына, еш булмаса да, кайтып йөргәннәр. Боларны Рәйсә әнисе Наилә сөйләгәннәр буенча гына белә. Әбисенең анда Галия апасы яшәгәнен, аның посылка белән юкә балы, мамык шәлләр салганын, бабасының Кукмарага – апасына кунакка баруын, күчтәнәчкә ап-ак йоннан бәйләгән оекбашлар җибәрүләрен...

Галия, Вәкил, Рәшит, Гөлүсә, Люция, Әюп... Кайсы яктан, ничек туган бу кешеләр? Исәннәрме, юкмы? Бу сорауларның берсенә дә җавап юк инде: туганлык җепләре өзелгән, аралар ерагайган. Хәтердә – исемнәр генә саклана...

– Әйткәнемчә, мин 1 нче класска укырга кергән елны киттек без авылдан. Әби белән бабайны ничек сагынганымны белсәгез! Атна саен кайтып йөри идек: авылда эшнең беркайчан беткәне юк – булышырга кирәк. Берсендә электричкага соңга калдык – кайтып булмады, шул көнне үкси-үкси елаганым әле дә истә... Мин 10 нчы класста укыганда әби авырып китте дә, аны сырхауханәгә салдылар. Бабай янына мин кайтып тордым. Икәү көтү дә кудык, сыер да саудык...

Татарча аңлавым, догалар белүем өчен мин әби белән бабайга рәхмәтле. Икесе дә мәрхүмнәр инде. Күршедәге татар авылы Касьяновкада җирләнделәр. Әле яңа гына бабай вафатының 20 еллыгына аш үткәрделәр. Коръәнне әнием укыган...

Инде әңгәмәнең иң кызык өлешенә килеп җитәбез. Һиндстан... Безнең өчен Гита һәм Зита, Митхун Чакраборти, Радж Капур ватаны, әкияти матур, серле ил... Язмыштыр инде – татар кызы Рәйсәнең бөтен тормышы нигәдер менә шушы ил белән бәйләнгән булып чыга. Ә язмыштан, бик теләсәң дә, кача алмыйсың...

Әнисе паспортистка булып эшләгән чит ил студентлары тулай торагына эшкә кеше кирәген ишетеп калган Рәйсә шунда урнаша. Юк, тормышлары авыр булганга түгел, әнисе аны да, сеңлесе Тәнзиләне дә беркайчан мохтаҗлыкта яшәтми. Әмма һәрвакыт мөстәкыйль булырга омтылган кызга акчаны үзе эшләп табу мөһим бит. (Сүз уңаеннан, беренче хезмәт хакы йөз сум була аның. Шуның сиксән сумына әнисе белән хушбуй сатып алалар.) Иркутск техник институтына укырга кергәч тә эшен ташламый ул. Беренче мәхәббәтен дә тулай торак коридорында очрата Рәйсә. Егет – Һиндстаннан, кыздан сигез яшькә өлкәнрәк. Әлбәттә, чибәр – һинд киноларындагы мәхәббәт геройларыннан әллә ни аерылмый. Яратуы да аларныкыннан ким түгел – яшьләр кавыша.

Һәр кичне йоклар алдыннан әбием өйрәткән догаларны укыйм.

Ире укуын тәмамлагач, Рәйсә, бер икеләнүсез аңа ияреп, Һиндстанга юл ала: энә кайда, җеп шунда булырга тиеш.

Тик улларының өйләнүе, инде бала көтүләре хакында аның туган йортында берни белмиләр икән. Рәйсә анда барып төшкәч кенә аңлый моны. Ире туганнарына әйтмәгән, бу яңалыкны сөйләргә йөрәге җитмәгән. Бергә кайтып төшкәч, аңларлар, кичерерләр дип уйлаган, күрәсең. Юкка... Чит-ят җирдән килгән киленне кайнанасы кабул итми. Һинд гаиләләрендәге тәртипләрнең кырыслыгын Рәйсә шул чакта яхшы аңлый...

Бу хакта сөйләгәндә күзләрендә хәзер дә яшь булуын күргәч, ул вакыттаниләр кичерүен күз алдына китерү авыр түгел.

Ире кала. Рәйсә кире Иркутскига кайтып китә. Борчылулар эзсез узмыйни – самолетта аның тулгагы башлана... Оныгы Вигянны кайнанасының бер тапкыр да күргәне юк. Үпкәләр күптән онытылган, үзен кабул итмәүләре өчен Рәйсә беренче иренең гаиләсенә бүген хәтта рәхмәтле – язмышын башка сукмакка кертеп җибәргән өчен рәхмәтле. Ә ул чакта... Никадәр кыен булса да, яшәргә кирәк... Институтны тәмамлый, Мәскәүдә укып, психолог һөнәре ала. Ә күңелдә бер теләк яши. Теге вакытта, ире туган йортның бусагасыннан уза алмаганда, ул нигәдер үз-үзенә: «Мин бу илгә барыбер тагын бер киләм әле!» – дип сүз биргән була. Сүзне үтәргә кирәк! Чираттагы ялы вакытында Һиндстанга юллама сатып ала.

...Самолетта аларның урыннары янәшә туры килә. 15 декабрь – Рәйсәнең туган көне була ул.

– Очкычта йокламын дип уйлаган идем, ә ул бертуктамый сөйли: кем ул, кайдан, ни белән шөгыльләнә, ниләр турында хыяллана... Аның бу кадәр ачылуына аптырап тыңлап барам. Өнәмәвемне сизә бит югыйсә, тик сизмәмешкә салыша. Миңа сораулар яудыра. Кешегә ошарга тырышканда гына матуррак күренергә, үзебезне әйбәтрәк күрсәтергә тырышабыз бит без. Ә бу очракта минем уемда андый нәрсә бөтенләй юк иде.



PRESSA.RU





Тагын чит ил кешесе белән якынаюмы? Кирәкми... Сүз арасында: «Нинди модель икән, карыйм әле», – дип, ул минем телефонымны кулына алды. Кай арада шуннан үзенең номерын җыярга өлгергән! Кич белән телефоныма: «Мин сине яратам!» – дигән смс-хәбәр килеп төште. «Кемдер ялгыш җибәрде бугай», – дип уйладым. Ә ул самолеттагы күршем Нирадж булып чыкты. Мине эзләп тапты, кичке ашка чакырды.

Сарины бик сирәк киям – бәйгеләрдә катнашканда гына.

Ә иң кызыгы Иркутскига кайткач башланды. Нирадж миңа бертуктамый шалтыратырга кереште. Көнгә йөзәр тапкыр! Бер айдан үзе килеп төште. Минем: «Юк!» – диюләрем аңа берничек киртә була алмады: ышандырды, күндерде, ризалатты – Һиндстанга, Мумбай шәһәренә килен булып төштем. Икенче тапкыр...



Үзем дә сизмичә, әңгәмәдәшемнең сүзен бүлдерәм:

– Ә кайнанагыз? Ул кабул иттеме?

– Без өйләнешкәндә иремнең әти-әнисе вафат иде инде. Әмма монда да тәртипләр үзгәрә хәзер. Россиядән килгән киленнәрне кабул иткән гаиләләр аз түгел. Тик проблемалар барыбер җитәрлек. Бер генә мисал. Һиндстан – вегетарианнар иле бит. Безнең кызларга да күп очракта ирләре ит ашарга рөхсәт итми. Өйләнешкәч, Нирадж да миңа: «Бәлки ит ашамассың?» – диде. «Ярый, ашамам, – дип җавап бирдем. – Тик син дә ул очракта минем теләгемне үтисең – иртәгәдән ит ашый башлыйсың, яме». «Мин бит инде аны 42 ел ашамыйм», – диде ирем аптырап. «Ә мин инде 32 ел ашыйм!» – дидем. Ирем барысын да аңлады – бу хакта башка сүз кузгатмады. Гаилә коргансың икән, бербереңне хөрмәт итү кирәк, ирексезләргә ярамый дип саныйм мин.

Тагын тормышның күңелсезрәк якларына кереп киттек.

Рәйсәнең бүгенге тормышы һич тә зарланырлык түгел. Иренең төзелеш белән бәйле зур бизнесы бар. Күп катлы яхшы йортта, иркен фатирда яшиләр. Хезмәтчеләр тоталар. Ире Рәйсәне алиһә урынына күрә.

– Әйткәнемчә, монда ирләр кинода гына романтик. Ә чынлыкта... Тик мәхәббәт кешене үзгәртә икән. «Нигә сиңа ул чәчәкләр?» – дип аптырый иде башта Нирадж. Хәзер ул миңа аларны кочагы белән алып кайта ала. Кыз бала тууын фаҗигагә әйләндерүчеләр дә байтак. Иремнең бер генә теләге булды: «Ул чәршәмбе көнне дөньяга килергә тиеш!» – диде. Алар йолдызнамәгә бик ышана: чәршәмбе туган бала аңа уңыш китерергә тиеш иде. Невин әтисе көткән көнне туды!

Бәйгеләрдә катнашырга рөхсәт итүе дә – яраткангa. (Балалы хатынга өйләнүе өчен тирә-юньдәгеләрдән иренә шактый сүз ишетергә туры килүен Рәйсә соңыннан, очраклы рәвештә генә белә. Хатынының матурлык конкурсларында катнашуын, җиңүләр яулавын да Нирадж башта берәүгә дә әйтми. Ә белгертәсе килеп йөргән бугай! Рәйсә турында зур язма чыккан журналны беркөнне үзе йөргән спортзалның киенү-чишенү бүлмәсендә «онытып» калдыра. Сер шулай чишелә.)

Иркутскидагы матурлык бәйгесеннән соң Рәйсә Мәскәүгә «Леди России» конкурсына элгә: «Lady Universe» номинациясендә төп титулны яулый. Сәхнәгә ул һәрвакыт үзе белән кызы Невинны да җитәкләп чыга.

– Мин чемодан җыймый башлагач, кызым: «Ә чираттагы бәйге кайчан була, кайчан китәбез?» – дип сорый башлады. Хыялым чынга ашты бит инде: тагын бәйгеләрдә катнашырга теләгем юк иде... Ә аннан, Гоага ялга

очканда, кулыма журнал эләкте, «Мисс Һиндстан» бәйгесенә кастинг игълан итәбез», – дигән юлларны күреп алдым. Балалар өчен оештырылган матурлык конкурсларында Невин үзе катнаша ала бит, дигән уй башыма да кереп карамаган иде. Тәвәккәлләдек! Кызыбызның бүген дөньяның төрле почмакларында, төрле бәйгеләрдә катнашып алган 52 титулы бар, әмма безнең өчен иң кадерлесе, әлбәттә, «Мисс Һиндстан» таҗы! Иртәгә бәйге була дигән көнне хәтта әтиебез дә йокламады...

Греция, Төркия, Вьетнам, Россия, Грузия, Болгария, Франция... Бер елга тугызар бәйге! Тугызар таҗ! (Язма журналга әзерләнгән көннәрдә, Невин Италиядә узган матурлык бәйгесендә катнашып, тагын җиңү яулады: аның титуллары 52 түгел, ә 53 хәзер!)

«MISSIS WORLD RUSSIAN BEAUTY» бәйгесен Америкада туксанынчы еллар башыннан үткәрәләр. Чит илләрдә яшәүче Россия ватандашлары арасындагы иң дәрәҗәле конкурс бу. Нью-Йоркта 2014 елда узган әлеге бәйгедә Рәйсә Гран-прига ия була. Бер үк вакытта балалар өчен «MINI MISS WORLD RUSSIAN BEAUTY TY» конкурсы да бара. Невин да шул елны анда беренче урынны ала! Ә залда әтиләре утыра. Шатланып! Горурланып! Матурлык бәйгеләренең кызын никадәр үзгәртүен ул инде күптән аңлаган: Невинга әле 8 яшь тулмаган, ә аның инде телевидениедә махсус программасы бар – атаклы һинд актерларыннан интервьюлар ала.

Әтиләре соңгы вакытта, гомумән, бик бәхетле әле аларның. Рәйсә алты ай элек ирена игезәк балалар бүләк иткән. Малайлар! «Ирем барысын да уңышка юрый», – дип елмая ул. Икеләтә уңышка!

Үзенең булдыклы хатын, менә дигән әни булуын Рәйсә иренә дә, тирә-юньдәгеләргә дә инде раслаган. Нираджның дуслары, хезмәттәшләре, тирә-күршеләр өчен ул күптән үрнәк. Невин рус балеты һәм һинд классик биюе белән шөгыльләнә, нәфис гимнастикага йөри, фортепианода уйный, рәсем ясый, чигә, бәйгеләрдән кайтып керми – әнисе тырышлыгы бит. Ул кызының директоры, арт-директоры да, менеджеры, стилисты, чәчтарашы да. (Ерак юлларга соңгы вакытта өч бала белән чыгып китүе үзе батырлык!) Картиналар чигә – Мумбайда эшләүче Россия фән һәм мәдәният үзәгендә шәхси күргәзмәсе булып узган. Аның ачылышында Россиянең Һиндстандагы консулы да катнашкан. (Хатынын «рәссам» дип атаулары ире өчен зур яңалык булган! «Элек ул, төрле сәбәпләр табып, минем белән бергә үзәккә бармаска тырыша иде, – ди Рәйсә. – Ә хәзер бик теләп йөри. Анда безнең ирләр бөтенләй үзгәреп китәләр. Гаилә кануннарын җимереп, рус кызларына өйләнгәнгә күрә, алар барыбер җәмгыятьтә үзләрен ятрак хис итә, күрәсең. Ә үзәккә – үзләре кебекләр җыела, һәммәсендә бер язмыш. Сүз уңаеннан, Мумбайда мин дә бердәнбер татар хатыны түгел».)
Рәйсә – Көнбатыш Һиндстандагы Россия ватандашлары ассоциациясе әгъзасы да: авыр хәлдә калган илдәшләренә ярдәм итүдә катнаша.

Үзәктә еш кына аш-су әзерләү буенча бәйгеләр оештырыла. Рәйсәгә җитүчеләр сирәк!

...Рәйсә белән соңгы яңалыклар турында сөйләшәбез: аларда кура җиләге өлгергән. Мумбайда көне буе көчле яңгыр ява, димәк, өченче сыйныфта укучы Невинның иртәгә дәресләре булмаячак. Олы улы белән телефоннан сөйләшкәннәр... Консуллык каршындагы мәктәпне тәмамлагач, «Әби янында яшәргә телим», – дип, Вигян Иркутскига кайтып киткән. Әнисенең кыз фамилиясенә күчкән, исемен алыштырган. Ул хәзер – Ринат Закиров. «Һәркем үзе дөрес дип тапкан юлны сайлый», – ди Рәйсә. Әйе, шулай!

БЕРНИЧӘ ҖӨМЛӘ БЕЛӘН

■ Һиндстанда гаиләләр хәзер зур димәс идем. Урта хәллеләрдә – 1-2 бала. Ярлы гаиләләр исә малай туганчы таба да таба баланы...

■ Кайнана киленне башта ук яратып бетермәсә дә, ир бала туса, аралар әле азрак җылынырга мөмкин. Кыз тапсаң – кайнанаңнан рәхим-шәфкать көтмә!

■ Абортлар тыелмаган, әмма гинеколог булачак әти белән әнигә баланың кызмы, малаймы икәнен әйтергә тиеш түгел. Әгәр моны әшли икән – хөкем каршына басарга да мөмкин.

■ Һиндстанда уртача хезмәт хакы 100 доллар тирәсе. Гаилә аның 80 долларына көн итсә, ай саен 20 долларын банкка – баласының бирнәсе өчен салып бара. Менә ни өчен алар барысы да малай тууын көтә. Кыз бала өчен гомер буе бирнә җыярга һәркемнең дә мөмкинлеге юк. Бирнәң саллы булса, кызыңны табибка, адвокатка яки полицейскийга кияүгә бирә аласың. Бирнәң аз икән – рикша белән канәгатьләнәсең.

■ Болливуд киноларының гына барысы да мәхәббәт турында. Чынлыкта, Һиндстанда яратышып кавышкан парлар бик сирәк. Кызына кияүне әти кеше үзе эзли: нинди кастадан, диннән булуы исәпкә алына. Астрология дә эшкә җигелә. Невинга дә булачак тормыш иптәшен әтисе сайласа, мин каршы төшмәячәкмен.

■ Аерылган яки тол калган хатын кабат кияүгә чыгу турында инде хыяллана алмый. Аның каруы, хатын-кыз теләмәсә, рөхсәт бирмәсә, ирне аңардан аермыйлар.

■ Моңарчы ир белән хатын икәнеңне раслау өчен документ кирәк булган урыннарда, туйда төшкән фотосурәтне күрсәтергә сорыйлар иде. Соңгы вакытта «языльшу турындагы» таныклыкны күрсәтсәң – шул җитә. Әмма Америкага бару өчен виза алганда, безгә тагын гаилә альбомы белән килергә куштылар.

■ Балага «туу турындагы» таныклыкны бирер алдыннан, син яшәгән йортка килеп: «Чынлап та балалары тудымы?» – дип, башта тирә-күршеләрдән сорашалар, аннан, ир бала алып кайттыгызмы, кызмы, дип карар өчен, өйгә керәләр.

PRESSA.RU



МӘКАЛӘГӘ КЕРЕШКӘНЧЕ, ӘҮВӘЛ ШУНЫ АЧЫКЛЫЙК ӘЛЕ: СЕЗ ДӨНЬЯВИ КАРАШЛЫ КЕШЕМЕ, ӘЛЛӘ ДИНИМЕ? Ә БӘЛКИ МӘҖҮСИДЕР? «БУ НИНДИ СОРАУ ИНДЕ?! УРАМДА XXI ГАСЫР!» – ДИЯРСЕЗ. АШЫКМАГЫЗ.

Ландыш ӘБҮДӘРОВА

ЯКЛЫЙ МИНЕ, САКЛЫЙ МИНЕ...

Йә, кара мәче күргә тизрәк төймәгезгә үрелгәнегез юкмыни? Тоз чәчелсә, якын кешегез белән ызгыш-талаш көтеп йөргәнегез? Идәнгә чәнечке төшеп китсә, кунакка хатын-кыз көткәнегез бармы? Чәйнек җырлап кайнаганны кунак килүгә, тәрәзә төбенә кош кунганны яхшы хәбәргә юраганыгыз бардыр бит? Ә «13» ле санына нинди мөнәсәбәттә сез?

Әни булган хатын-кызлар мине аңлар: алар балалар турындагы ырымнарның тулы бер энциклопедиясен туплаган кешеләр. Хатын-кыз үзенең әни булачагын белүгә, кагыйдә буларак, үзенең башка төр социаль статусларын салып ташлый да табигать баласына әйләнә. Менә шунда бүгенге көндә «искелек калдыклары» дип бәяләнә торган ырымнар аңа ярдәмгә килә дә инде. Бу җәһәттән Таня Майер исемле бер америкалы әнинең Россиядә әни булу турындагы китабында бер очракны тасвирлавы кызыклы: «Россиядә, – ди ул, – хатын-кызлар ырым-шырымнарга ышана. Мәскәү дәүләт университетында фәлсәфә фәне укытучы бер иптәш кызым үзенең авырга калуын белүгә, маңгай чәчен кистерми башлады. Күз алдына китерәсезме: фәлсәфә фәннәре докторы!»

Әйе, Танечка, бездә Әниләр шундый инде ул, аларны һәм, гомумән, «Россияне акыл белән генә аңлап бетереп булмый». Хикмәт шунда: ананың балага карата булган ярату хисен башка төр ярату белән бутап булмый. Баланы яратуның исеме сөю дә, мәхәббәт тә, гыйшык та түгел, ә курку дип атала. Йөрәк астында җан яралуын белүгә, хатын-кыз шушы хис белән яши

башлый. Йокыдан ул: «Мин баланы яратам», – дип түгел, ә «Ничек ул анда?» дигән уй белән уяна. Төрле афәтләр, һәлакәтләр, экологик проблемалар һәм билгесезлек белән тулы дөнья аның нарасые өчен чит, ят. Булачак ананың куркуларын фәнни ачышлар яки коры статистика белән генә куып таратып булмый. Менә шул вакытта ырымнар юану китерә дә инде.

Әлеге дә баягы, йөклелек вакытында чәч кисәргә ярамый дигән ышанудан башлыйк. Янәсе, киссәң, бала үле туарга яки төшәргә мөмкин, диләр. Бу ышану борынгы заманда әби-бабаларыбызның чәчкә аерым игътибар бирүеннән килә. Имештер, кешенең яшәү көче нәкъ менә чәчләрендә, дип ышанган алар. Фән моның алай түгеллеген исбатлады, ә менә ышану яши бирә.

Бала туганчы бирнә әзерләмәскә, диләр. Мантыйк буенча, киресенчә, әзерләп куярга кирәк югыйсә. Бала тугач, башка мәшәкатьләр дә җитәрлек була. Ә ышануның тамыры исә элгәре туачак баланың җенесен белмәүгә бәйле, күрәсең. Хәзер исә моны УЗИ кебек ачышлар белән җиңел хәл итеп була.

Йөклелек вакытында тегәргә, бәйләргә, чигәргә ярамый – бу ырымның ике тамыры бар. Беренчедән, тегү-бәйләү эшләре борынгылар баланың бу дөньяга килү юлын тегеп куя, дип уйлаганнар. Икенчедән, баланың теле озак ачылмас, дип курыкканнар. Чынлыкта исә боларның нигезе юк. Дөньядагы тегүче хатын-кызлар сау-сәламәт бала таба.

Йөкле вакытта озаклап көзгегә карарга ярамый. Борынгылар көзгене теге дөньяга ишек буларак кабул иткәннәр. Шуңа да көзге тирәсендә кара көчләр күп йөри, дип ышанганнар. Йөкле хатын көзгегә озак карап торса, явыз көчләрне үзенә тартып китерер, дип шикләнгәннәр. Бүгенге көндә мондый ырымнарга ышанасы килми, әмма йөкле вакытта хатын-кызның кыяфәте кәефе кебек үк үзгәрүчән була. Йөкле вакытта хатын-кызның кәефсез көйгә көзгегә карамавы хәерле...

Күрсәтергәме, күрсәтмәскәме?

Бәби тугач, хатын-кызларның моңа кадәр ырым-шырымнарга ышанмаганнары да аларга колак сала башлый. Мәсәлән, 40 көнгә кадәр баланы берәүгә дә күрсәтергә ярамый дигәненә. Чыннан да, баланы күрсәтергә ярыймы, әллә ярамыймы? Ышану бер төрле сөйли, табиб – икенче төрле, аек акыл белән өченчесен уйлыйсың.

«40 көн буена ана белән баланың бер аягы җирдә, бер аягы гүрдә булыр» дигән мәкаль дә бар безнең халыкта. Димәк, халык ышануына таянсак, күрсәтмәвең хәерле.

Табиблар да бала тугач, әни кешенең күкрәк сөте белән имезүе 40 көн дәвамында формалашып бетә дип саный. Ягъни әни кеше баласын сәгатьләр буе күкрәге янәшәсендә тотарга тиеш. Мондый шартларда кунак чакыру әни белән балага уңайлы булырмы? Һәр гаилә үзенчә хәл итә. Шулай ук яңа туган бала янына бакчага йөри торган балаларны бигүк якын китерергә ярамый. Билгеле булганча, бакчага йөри торган балалар инфекцияләрне тиз иярткүчән. Әлегә бер прививкасы да булмаган балага монысы да кирәк түгел. Димәк, бу җәһәттән борынгы миф белән медицина бер сүздә.

Бик күп халыкларның мифологиясендә дә, динендә дә, көндәлек тормышында да бу ышану яшәп килә, ул магик фикерләүнең иң киң таралган төре. Психология фәне аны мәдәни шартлылык синдромы дип атый. Ул кешенең энергия-мәгълүмат кырында баланс бозылу, аурага тискәре йогынтылы программаларның үтеп керүе дип аңлатыла. Нәтиҗәдә, кешенең сәламәтлегенә зыян килә, иммунитеты төшә, кәефе начарая. Ниндидер эмоциональ киеренкелек вакытында, кешеләр бер-берсенә тавыш күтәреп сөйләшкәндә, уй-кичерешләр йөрәктән чыкканда күз тию ихтималы зур икән.

Әле биокыры ныгып җитмәгән яңа туган баланы нәкъ шушы сәбәпләргә бәйләп, кеше күзеннән саклыйлар да инде. Бу вакытта әни дә, бала да тискәре энергиягә бик сизгер булалар: әни булу бәхете, баласын исән-сау килеш кулына алу шатлыгы белән әни кеше чит кешенең ихтыярсыздан кабынган кызыгу, көнләшү кебек хисләрен сизми дә кала.

> *Яшь баланы кеше күзеннән саклауның тагын бер сәбәбе – күз тию дигән нәрсә дә бар бит әле.*

Әлбәттә, күз тиюгә, ягъни магия телендә әйтсәк, кара көчләр ияртүгә берәүләр шунда ук ышана, икенчеләр катгый рәвештә кире кага. Элегрәк мин дә мондый нәрсәләрне «сафсата» дип кенә бәяли идем. Ә балалар тугач, һәртөрле инфекция чыганакларын, вирусларны «үтәли күрергә өйрәнгән» кеше буларак, күз тию кебек «искелек калдыклары» да көн тәртибенә басты. Югыйсә тамагы тук, асты коры, җылыда гына ята торган бала нәрсәгә еларга, көйсезләнергә мөмкин? Табигать алдындагы көчсезлегем мине дә мондый нәрсәләргә ышанырга мәҗбүр итә. Аннан соң ышанмаганга карап кына андый нәрсәләр юк дигән сүз түгел бит әле. Урамда техника һәм тәрәккыят заманы булуга карамастан, күз тиюләргә каршы олы бер индустрия эшләп килә икән. Мулла бабайлар өшкерә, әбиләрең төчкерә дигәндәй.

Безне кечкенәдән әбиләребез дога белән өшкереп үстерде. Күз тисә дә, тимәсен дип тә өшкерде. Бик күпләребез кечкенәдән үк ул догаларны яттан белә. Өстәвенә, ислам дине күз тиюне кире какмый. Аннан иман ныклыгы белән сакланырга куша.

Хәзер инде мин ырым-шырымнарны бөтенләе белән кире кагучы тәкәббер кеше түгел, шулай да чама хисен югалтмаска кирәк дип саныйм. Үземне балаларыма карата һәрвакыт догада булачак әни дип күзаллыйм. «Саклый мине, яклый мине әнкәмнең догалары», дип җырлаганча, үзебезне дә әниләр догасы нинди генә упкыннардан тартып алып калмагандыр – болары бер Ходайга гына мәгълүм. Инде буй җиткәч, адым саен киртә-каршылыклар сагалап торган олы тормыш юлына аяк баскач, юкка гына бусагадан борылып, әниләргә «Догаңнан ташлама!» дип әйтмибез бит.

PRESS4.RU



АК КАЛФАКЛАР ТАБЫЛЫР ЧАК

МИЛЛӘТ КЫЗЛАРЫ ТУРЫНДА БЕЗ КАЙЧАН УЙЛАНАБЫЗ СОҢ? ТАТАР КЫЗЫ ДИГӘНДӘ, КҮЗ АЛДЫНА НИНДИ СУРӘТ КИЛЕП БАСА?

Ландыш ӘБҮДӘРОВА

Милләт кызларына һәр чорның үз йөкләмәсе булган, заманның катлаулыгына карап, хатын-кызларыбыз гаилә учагын, дин-иманны саклаучыдан ил йөгәнен үз кулына алган милләт анасына кадәр юл үткән. Андыйларның исемнәре тарих битләренә языла барган: Сөембикә, Нурсолтан, Сүзге… Исемнәре татар халкының фаҗигале язмышы турындагы җырларга кереп калган: «Энҗе лә мәрҗән кызларның кул бавы, Гөлҗамал…»

Узган гасыр башында милләтебезнең алдынгы карашлы зыялылары да уйланган бу турыда. Гаяз Исхакыйның «Мөгаллимә»се, Фатих Әмирханның «Татар кызы», Галимҗан Ибраһимовның «Татар хатыны ниләр күрми?» әсәрләре барлыкка килгән.

XIX йөз татар кызларын мәгърифәтле булырга өндәсә, XX йөз башы аларга ирләр белән тигезлек алып бирде. XX гасыр урталарында татар хатын-кызлары ир-егетләр белән бер үк хезмәт сафына басты. Гасыр ахырына милләт өчен көрәшкә дә бергә чыкты.

Инде XXI гасырның да икенче дистәсен тутырып киләбез. Дөнья масштабларында татар кызларының да исемнәре торган саен ешрак яңгырый хәзер. Без янә татар кызларының йөзе турында уйланабыз. Кем син, бүгенге заманның хатын-кызы? Нинди син? Синең урының кайда? Эшлекле костюмнар, макияж, феминизм һәм тәрәккыйяткә өндәүләр – болар кемгә кирәк? Арыган, ләкин әле үзен карарга көч тапкан, бер кулына азык-төлек төягән авыр сумка, икенчесенә планшет тотып эшеннән өенә чабучы хатын-кызлар – бу илгә шушындыйлар кирәгрәк кебек югыйсә.

Бу турыда язучылар сирәк уйлана хәзер. Аның каруы, хатын-кызлар монысына да үзләре алынганнар. Тоталь кризис (икътисадый кризис кына түгел, рухи кыйммәтләрдә дә) дәверендә, тормыш нигезләре какшаган мәлдә без үзебез өчен Өлге эзлибез. Хатын-кызлар сизгеррәк җаннар бит, аларның бу эшкә алданрак тотынуы да гаҗәп түгел. Безгә киләчәктә үзебезнең мөмкинлекләребезнең чикләрен сызу өчен аутентик нигез кирәк. «Татар кызы» бәйгесе – менә шул эзләнүләрнең нәтиҗәсе ул. Бәйге әле бер төбәктә, әле икенчесендә аерым-аерым үткәрелә килде дә, хәзер инде Бөтендөнья татар конгрессы, аларны берләштереп, халыкара статус бирде. Бу табигый да: бәйгенең географиясе елдан-ел киңәя. Чиләбе белән Уфа татарлары башлаган эш төрле төбәкләрдә хуплау тапкан әнә.

Быел бәйгедә Россиянең егермедән артык төбәгеннән (Татарстан, Башкортстан, Удмуртия, Чуашстан, Кырым Республикалары, Алтай крае, Әстерхан, Чиләбе, Пермь, Төмән, Свердлау өлкәләре һәм башкалар), Казакъстан белән Кыргызстаннан катнашучылар булды.

21–23 сентябрьдә Казанда «Татар кызы-2017» бәйгесенең ярымфиналы узды. Кызлар пешерү буенча осталыкларын күрсәтте, Татарстанның халык рәссамы Нәҗип Нәккаш аларны шәмаил ясарга өйрәтте, аннан соң калфак чигеп карадылар. Финалга иң уңган, иң оста 12 кыз сайлап алынды.

Гаилә учагын саклаучы буларак, алар милли ризыкларны пешерә белә; милләт кызы буларак, шәмаилне белгән – динен, тарихын өйрәнгән; калфак чиккән – үзенең милли тамырларын этик-эстетик күзаллавы белән үргән...

XXI гасырның татар кызы нинди булырга тиеш, дигән сорауга җавап иде бу ярышлар.

Кызлар калфак чигә. «Бу гүзәл гамь!» – дияр иде шагыйрь һәм сокланып күзәтер иде. Күңеле, бәлки, әрнер дә иде. Буй җиткән кызларга калфакның ни икәнен аңлатып, кулларыннан тотып диярлек чигәргә өйрәт инде. Минем күңелдә «Гөлҗамал» җыры яңгырый: «Энҗе лә мәрҗән кызларның кул бавы...» Илдар абый Юзеевның «Ак калфагым төшердем кулдан» дигән сүзләре искә төшә. Их, менә телебезне дә камил белсәләр! Шунда «Ак калфак» татар хатын-кызлары оешмасы җитәкчесе Кадрия Идрисова эчке диалогымны ишетеп торгандай сүзгә кушыла: «Онытылган һөнәрләрне менә шулай яңадан кулларыннан тотып өйрәтергә кирәк», – ди ул, «яңадан» сүзенә басым ясап. Аның сүзләре миндә, ни гаҗәп, оптимизм уята. Үзем дә татар кызы бит мин. Татарлык һава сулау кебек табигый булган Актаныш төбәгеннән. Татар рухы өчен киләчәккә ышаныч беләнрәк караган ике меңенче елларны Казан университетының татар факультетында укып үткәргән көннәрдән. Шуңа да милли рух тегермәненә су коярдай һәрбер сүз, һәрбер гамәл энҗе бөртегедәй кадерле безнең буынга. Бәлки... татар теле өстендә әледән-әле күсәк уйнап торганда, кызларыбыз милләт сакчылары сафына басып, гаиләләрендә телне, тел белән бергә милли рухны да яклап алып калырлар?!





■ Адэль Сәет-Аблаева (Кырым, Симферополь): Кырым мәдәният, сәнгать һәм туризм университетының Хореография факультетында укыйм. Мин игезәкләр сыңары, узган ел "Татар кызы" бәйгесендә туганым Эдаль катнашкан иде. Бу безгә Казан татарлары белән аралашу тәҗрибәсе бирә. Аралашу һәрвакыт кешене баета, шуңа да бу мөмкинлек безнең өчен мәктәп ул.



PRESSA.RU



Әйе, риторик эндәшләр белән, пафослы сүзләр яздым мин хәзер. Ләкин ул вакытта – кызлар калфак чиккән минутларда моңа ышанасы килә иде...

Бу бәйге – яшьләр белән эшләү, яшьләрне милли хәрәкәткә җәлеп итүнең бик тә уңышлы формасы.

Лена Колесникова, Чиләбе өлкәсе татар конгрессы рәисе:

– Бу бәйге – минем иң яраткан балам. Ул Чиләбедә туды, һәм нәкъ менә бездә үткәрелә торган «Татар кызы»ның Россия төбәкләре өчен өлге булуы минем өчен зур шатлык. Быел катнашучылар саны тагын да артты, географиясе киңәйде. Сайлап алу турлары да югарырак дәрәҗәдә уза башлады. Төбәкләрдә аның чибәрләр бәйгесе генә түгеллеген аңлыйлар. Чыннан да, бәйге гүзәллекнең подиум-варианты түгел. Бу бәйгедә талантлы, киң кырлы белемле, милли рухлы кызлар катнаша. Һәркайсы үз төбәген күрсәтергә лаек.

Узган ел бәйгене Россия күләмендә беренче тапкыр уздырдык. Былтыр катнашучылар арасында төрлесе бар иде. Быел исә барысы да талантлы, быел финалга сайлап алу тагын да кыенрак. Һәркайсы – йолдыз.

Быел кызларның күбесе туган телендә сөйләшә. Монысы аеруча куанычлы. Бәйгедә катнашу өчен ана телен белү – мәҗбүри дип куябыз, әмма бөтен төбәккә дә без, оештыручылар, бердәй таләпләр куя алмыйбыз. Андый таләп тамырдан дөрес булмас иде. Без бәйгедә катнашырга теләүче татар кызлары алдында «тел белмисең», дип, ишекне ябып куя алмыйбыз. Бәйге үзенә танып-белү, өйрәнү бурычын да куя. Без ябык түгел, әгәр үз эчебезгә бикләнәбез икән, бәйге үсештән тукталачак. Без, киресенчә, чит халыклар белән хезмәттәшлек итәргә, аларга үзебезнең мәдәни хәзинәбезне күрсәтергә әзер.

Әгәр дә катнашучы кызыбыз милли үзаңын уятуга беренче адымын гына ясаса да, берничә елдан соң бу орлыклар аның гаиләсендә үзенең җимешләрен бирәчәк. Узган бәйгеләрдә катнашучылар үз төбәкләрендә милли хәрәкәттә актив катнашучылар булып китте, кемдер яшьләрне милли оешмага берләштерде.

Алар монда бер-берсе белән таныша, татар дөньясының абруйлы шәхесләре белән аралаша. Кыскасы, бәйгедә катнашу чорында алар милли мәдәният, тарихны танып белү буенча тулы бер мәктәп үтә.

Бәйгедә 17–25 яшь арасындагы кызлар катнаша ала. Аларның гаилә хәле әлегә таләп итеп куелмый. Алга таба, бәлки, бәйгене туташлар һәм ханымнар өчен бүләргә туры килер. Чиләбедә без нәни кызлар өчен «Нәни энҗеләр» дигәнен оештыра башладык. Кечкенә кызчыкларга да мәдәниятебезне, тарихыбызны өйрәтәбез шулай.

Кадрия Идрисова, «Ак калфак» Бөтентатар хатын-кызлары иҗтимагый оешмасы җитәкчесе:

Бәйгенең беренчеләре белән хәзергесен чагыштырсак, хәзер кызларның телгә карашы үзгәреп бара. Аларның бәйгегә мөнәсәбәте җитдиләнә, аларның нәкъ менә татар кызы булырга омтылышлары көчәя.

Без кызларыбызны үткәннәр белән генә тәрбияләмәскә тиеш. Әйе, үткәннәр – безгә үрнәк, без шуннан





■ Татарстаннан катнашучы Гөлназ Гатина – булачак финанслар белгече. Ул шәмаилне дә пөхтәлек, төгәллек белән башкарып чыкты.



■ Диана Аверина (Мәскәү): Хәзерге заман сәнгатенең Актерлык факультетында укып чыктым, ике ел актриса булып эшләдем. Хәзер кинематографиядә грим буенча рәссам булып эшлим. Мәскәүдә татар диаспорасы белән тыгыз элемтәдә эшлибез. Мин бит Уфа кызы, анда да үзебезнекеләрне эзләп таптым. «Ильдан» ансамблендә биим.

этәрелеп, аларны заманча итеп үстерергә тиеш. Татар кызлары рәсем ясамаган, алай киенмәгән, болай киенмәгән, дип, аларны заманчалыктан тыю – милләттән читкә тибәрү генә булыр иде. Алар өйдә яхшы хуҗабикә дә булырга, бии дә, җырлый да белергә, зәвыклы, укымышлы булырга да тиеш. Алар рәсем дә ясый белә, шәмаил дә...

Татар кызларына бит хәзер һәрнәрсәне яңадан исләренә төшерергә кирәк. Бу юлы без аларга калфак чигү буенча ярыш оештырдык. Ярымфиналда катнашкан 25 кызның берсе дә «Мин моны эшли белмим», дип тормады – һәркайсы булдыра алган кадәр тырышты һәм оста итеп башкарып чыкты. Чөнки геннарында сакланган ул. Алар күңелләре белән тоя: калфак кигән баш горур була. Калфаклы кызлар гәүдәләрен төз тотып йөри. Беренче бәйгеләрдә без аларның чәчләрен үрергә куша идек, чөнки татар кызы чәчен туздырып йөрми. Хәзер инде кызларда моны аңлау бар.

Татар кызлары сөйкемлелек, мөлаемлык белән аерылып тора, аларның елмаюлары серле.

Без кызларыбызның тәрбиясен табигать белән бәйләргә тиеш. Беләсезме, кызларның төс-төсмерләр аеру сәләте саегып бара. Табигатьтән аерылу асылыңны югалтуга китерә. Милли бизәкләребез дә табигатьтән алынган бит безнең.

Бәйгенең әһәмияте – кызларны үзара ярыштыруда түгел, ул тәҗрибә алмашу, милли үзаңны уяту, ныгыту мәйданы. Яшьләр иярергә тырышалар, аларның беләсе килә. Аларга менә шушы асыл кыйммәтләрне нигезләп бирә белергә генә кирәк.

Нәфисә АКЧУРИНА, «Берлек» мәдәни-агарту оешмасы рәисе (Уфа):

– «Татар кызы» бәйгесе – минем өчен намус эше. Башкортстанда Казан ягыннан чукындырудан качып килгән татарлар яши. «Татар кызы»ндагы эшем – халкыбызның шушы фаҗигаләргә дучар ителүгә карата җавабым ул.

Уфада татар кызларының гүзәллек бәйгесе 1992 елдан бирле үткәрелеп килә. Алик Локмановлар башлап җибәргән эшне Зәлия Ахуновалар еллар буена югалтымыйча саклап килгәннәр. «Нәүруз гүзәле» дигән исем белән ул 12 тапкыр үткәрелде, «Татар кызы» буларак Уфада дүртенче тапкыр оештырыла.

«Татар кызы» бәйгесенең концепциясе – татар хатын-кызларының җыелма образын тудырудан гыйбарәт. Моны халкыбызның бөек шәхесләрен күрсәтү аша башкарып була. Һәм без шулай эшлибез дә.

Туфан Миңнуллинның вафаты алдыннан биргән әңгәмәсе хәтергә кереп калган. «Шундый заман җитте: татар кызларын чишендереп, мал урынына сәхнәдә йөртәләр», – дип борчылган иде ул. Юк, без аларны чишендермибез. Тышкы матурлык үтә дә китә ул, кеше эчке матурлыгы белән күңелдә кала.

Әгәр бәйге туган телебезне күтәрергә, хәтеребезне яңартырга, халык күңеленә ышаныч оеткысы салырга ярдәм итсә, бурыч үтәлгән дигән сүз.

Бәйгегә кызлар үтә дә тыйнак булып, хәтта берникадәр курку белән киләләр. Киткәндә инде аларда үз-үзләренә ышаныч арта. Алар белән искиткеч педагоглар эшли. Афәрим Акчурин аларны татар моңын тоярга өйрәтә, Рәмизә Мөхәммәтшина бию хәрәкәтләрен бөтен нечкәлеге белән төшендерә, Мәхмүт Фатыйхов татар сүзләрен аларның авызына бал итеп сала, Гүзәл Акбердина аларның менталь холкын уята. Кайбер кызлар «тәүфыйк», «сабырлык», «затлылык» кебек сүзләрне беренче тапкыр ишетәләр. Моңа аларны гаепләп булмый, киресенчә, бу безне сагайтырга тиешле бер фал. Бу тамырлар өзелү куркынычы яный, дигән чаң. Аларның бәйгедә катнашырга теләвен милли тамырларын барларга омтылулары итеп кабул итәргә кирәк. Бу хуплауга лаек.

Уфада бәйге финалында заллар һәрвакыт тулы була. Тамаша вакытында халык тын да алмый, чөнки татар сүзенә, татар йөзләренә сусаган. Бу җәһәттән, бәйге, бәйгене барлыкка китергән татар кызлары – милләтне берләштерүче, җыючы бер нигез.



Рузалина Туктарова (Чиләбе): Мин тумышым белән Садко шәһәреннән. Әтиәнием – Башкортстанның Салават районыннан. Үзем дә Уфада, Кооператив институтында укыйм. Мондый дәрәҗәдәге бәйгеләрдә катнашырга күптән хыяллана идем. Тәвәккәлләдем һәм финалга уздым.



Башкортстан кызы Регина Равиловага шулай ук Уфадан Зәлия Ахунова теләктәшлек белдереп торды.

PRESS53.RU



«СӨЛГЕ ТУЕ»

«АК КАЛФАК» ТАТАР ХАТЫН-КЫЗЛАРЫ ИҖТИМАГЫЙ ОЕШМАСЫ САРМАН РАЙОНЫНДА «СӨЛГЕ ТУЕ» УЗДЫРДЫ.

Люция ФАРШАТОВА

Сарман башта безне үзенең халкы белән шаккаттырды: һәркем туган телдә генә сөйләшә, монда бар да ачык йөзле, тырыш-булдыклы... Аннан инде, әлбәттә, күз нурларын, җан җылыларын кушып чиккән аллы-гөлле сөлгеләре белән сокландырды!

Сарманлылар бу чарага берничә ай әзерләнгәннәр. Иң беренче эш итеп, «Сөлге туе»на дип атап, һәр авылда кич утырып, 1000 нән артык (!) сөлге чиккәннәр. Моның өчен әбиләрнең сандыкларында әле дә кадерләп сакланган сөлгеләрен барлаганнар: кызыл башлысын, чүпләмләп, алтын яки көмеш белән чигелгәнен... Атаклы «Казан сөлгесе» үрнәкләрен искә төшергәннәр, яңадан-яңа бизәкләрне үзләре дә уйлап тапканнар: халкыбызның онытылып барган олы мәгънәле, бай эчтәлекле гореф-гадәтләренең берсе – сөлге чигү шулай кабат яңартылган. Иң мөһиме: бу эшкә әби-апалар, кызлар-киленнәр генә түгел, мәктәп балалары да кушылган. Алай гынамы, районлагы кайбер балалар оешмаларында кыз балаларны сөлге чигәргә махсус өйрәтә башлаганнар. Мәсәлән, без булган «Лилия» балалар бакчасына йөрүче сабыйлар да чигү осталыгына кечкенәдән үк өйрәнәләр икән. 4-5 яшьләрдә алар чигү үрнәкләрен кәгазьгә ябыштырып, осталык күнекмәләрен алса, 6 яшьтә инде кулларына энә-җеп алып сөлге, тастымал чигәләр.

«Сөлге туе»на республиканың 27 районыннан, Россиянең 7 төбәгеннән килгән кунаклар – урыннардагы «Ак калфак» оешмаларын җитәкләүче йөздән артык гүзәл ханым район үзәгендәге «Шәфкать» тернәкләндерү үзәгендә, Сарманның Җәмигъ мәчетендә, Иске Кәшер авыл җирлеге территориясендә урнашкан «Кырык чишмә» дип йөртелүче чишмә буе аланында да булырга өлгерделәр; Татар Илеге елгасы буендагы ял паркында оештырылган күргәзмәдә районда яшәүче









Фото: Александр Эшкинин. Татаринформ.

төрле милләт вәкилләренең (алар биредә 7 процент кына, калган халкы – татарлар) һөнәрчелеге, милли ашлары, сәнгате белән таныштылар, сөлге чигү буенча мастер-класслар алдылар.

Район хакимияте башлыгы Фәрит Мөнәвир улы Хөснуллинның, кырык эшен кырык җиргә куеп, көн буе диярлек алар белән булуы да гаҗәпләндерде кунакларны. Бу бит хатын-кызга хөрмәтнең иң зурысы дигән сүз. Аның пленар утырыштагы чыгышы да эчтәлекле булуы белән сөендерде. «Элегрәк татарларның бер генә бәйрәме дә чиккән сөлгедән башка узмаган, – диде ул. – Яңа туган баланы да ап-ак чәчәкле сөлгегә төргәннәр, никах туйларында пар атларны чиккән сөлгеләр белән бизәгәннәр, Сабантуй батырына да, ат чабышларында җиңүчегә дә чиккән сөлге бүләк иткәннәр. «Ак калфак»лыларның онытылып баручы шушы йоланы көнкүрешебезгә кайтарырга омтылуы үзе үк милләтебезнең үзаңын уятуда бер саллы өлеш ул. Без бу йоланы бүгеннән башлап куллана башлаячакбыз».

Яшәгән төбәкләрендәге чиккән сөлге белән бәйле йолаларны чыгыш ясаучыларның һәрберсе искә төшерде. Әйтик, республиканың көньяк-көнчыгыш төбәгендә, Самара, Ульяновск якларында элегрәк кыз сорарга баргач, әгәр ул як риза булса, яучыга чиккән сөлге бүләк итеп җибәрә торган булганнар. Әлеге сөлгене егет ягы капкага чыгарып элгән, бар халык килен төшәсе йортны белеп торган – бәйрәм көткән. Нинди күркәм йола!

Гомер-гомергә чиккән сөлге халкыбызның йөз аклыгы булган. Киләчәктә дә шулай булып калсын.

Сарман районы Сарман авылы «Ак калфак» оешмасы җитәкчесе Дания Зиннәтуллина аккалфаклылар соңгы берничә елда тормышыбызга кайтарган кайбер йолаларны инде куллана да башлауларын билгеләп үтте. Мәсәлән, районда күп кенә хатын-кызлар бәйрәмнәргә, бар халыкны сокландырып, калфактан, татар милли киеменнән килә икән. Күп гаиләләр шәҗәрәләрен барлый башлаган. Мәктәп, бакча балаларын, яшьләрне төрле түгәрәкләрдә милли ашларыбызны пешерергә, калфак, кулъяулык, сөлге чигәргә өйрәтәләр. Сарман аграр көллиятендә, сәнгать мәктәбендә укучы кызларның сөлге-тастымаллар, мәрҗәннән картиналар чигеп, аларны инвалид балаларга, ярдәмгә мохтаҗ гаиләләргә бүләк итүе традициягә әйләнеп бара. «Яшьләр безне тыңларга әзер, күп вакытта без үзебез аңлата белмибез, шул рәвешле асылыбызны, үзебезне югалтабыз. Милли гореф-гадәтләребезне көнкүрешебезгә кертү юнәлешендәге аңлашылмаучылык та шуннан килеп чыга», – диде ул.

PRESSA.RU

БАРЛЫК ЯКЫННАРЫБЫЗ БЕЛӘН «ТУГАН АВЫЛЫМ»ДА МОННАН 50 ЕЛ ЭЛЕК УЗГАН ТУЕБЫЗНЫ ИСКӘ ТӨШЕРЕП УТЫРДЫК. ИКЕБЕЗ ДӘ ИСӘН-САУ, КАДЕРЛЕ КЕШЕЛӘРЕБЕЗ – ЯНӘШӘДӘ... 50 ЕЛ КҮЗ АЧЫП ЙОМГАНЧЫ ҮТКӘН ДӘ КИТКӘН!



АЛТЫН ТУЙГА СӘЯХӘТ



Сиринә СӘЛИМШИНА-ШАҺИМӘРДАНОВА

Безнең дә алтын туебыз гөрләде! Флера Сөләйманова җырлый торган «Алтын туй» җыры нәкъ безнең турыда кебек, ул безнең яшьлектән иде. Сүзләре ничек туры килеп тора тагын: «Алтын туегыз бик мөбарәк икән», «Барысы да уртак булды», «Бер шатлыкны ике иттегез», «Бөтен туганнар бергә җыелган»... Ә бит Равил белән очрашуыбыз яңа гына иде кебек...

1966 елның апреле. Мәскәү технология институтының III курсында укып йөргән көннәрем. СССР башкаласына Татарстаннан КПССның XXIII съездына ун делегат килде. Минем өчен дә бәйрәм булды якташларым белән аралашу: үзем бит Ютазының Кәрәкәшлесеннән! Татарстан кунаклары белән Ломоносов исемен йөрткән Мәскәү университетына, Габдулла Тукайның 80 еллыгына багышланган тантанага баруым бүгенгедәй күз алдымда. Арада кемнәр генә юк! ТАССР өлкә комитетының беренче секретаре Фикрәт Табиев, җырчы Илһам Шакиров, университет профессорлары, студентлар... Чыгышлар күп булды. Илһам Шакиров, рояль янына утырып, «Кара урман»ны җырлады. Аннары кичәбез Тимирязев исемендәге академия клубында дәвам итте.

Менә шунда инде мин Казан егете Равил Шаһимәрданов белән таныштым. Ул бу академиянең аспиранты булып чыкты. Әле дә хәтеремдә: Равил Тукайның ике шигырен русча сөйләде, ә мин татарча җырладым. Аннары инде очрашкалап йөри башладык. Аңа свитер бәйләп бүләк иткәнем булды. Аш-суга осталыгымны да күрде Равил. Хәзер дә елмаеп искә төшерәм: бу кызның кулыннан эш килә, дигәндер инде егет. 1967 елның язында ул мине Казанга, әнисенә күрсәтергә алып кайтты. Өйдән хәер-фатиха алып, Аллаһының рәхмәте белән Мәскәүдә Тимирязев районы ЗАГСында язылыштык. Аннары Казанга кайтып, никах укытып (Башкортстаннан килеп, никахны әти үзе укыды), туй ясадык.

Элек әби-бабайлар, әти-әниләр, балалар – барчасы да бер нигездә яшәгән бит. Үзебезнең гаиләдә дә шулай үстек – Сәлимшаһ бабай өе безнең нигез иде. Җәмәгатем Равилнең әнисе – Хәдичә әни белән бик күп еллар бергә гомер иттек. Хәдичә әнинең әтисе Мөхәммәдфатыйх бабай да вафат булганчы берничә ел безнең белән яшәде. Кечкенә генә өйдә – кайнана, Равилнең энесенең гаиләсе, безнең гаилә, яңа туган яшь балалар... Су да, газ да юк, керосинкада ашарга әзерлибез, балаларны коендырырга су җылытабыз. Аллага шөкер, ирләребез су ташып, утын ягып, безне авыр эшләрдән сакладылар. Кайнанабыз Хәдичә бик акыллы, бик гадел кеше иде. Балаларны тәрбияләүдә, барыбызга тыныч яшәүдә бик ярдәм итте ул, урыны җәннәттә булсын. Казан белән Мәскәү арасын такырайтып, мин дә, ниһаять, диплом алдым.

Ә Равил бик сабыр булды, кечкенә баланы да алып калды, сызымнарны әзерләгәндә дә булышты. Ничә генә барырга туры килмәде Мәскәүгә! Диплом алып кайткач, башта юллама белән химик чистарту фабрикасында эшләдем, аннары мине Кремльгә – Халыкка көнкүреш хезмәте күрсәтү министрлыгына чакырдылар, тәэмин итү бүлеген җитәкләдем. Соңрак – Австрия белән уртак «Ильдан» предприятиесендә генераль директор урынбасары, Италия белән уртак «Имаж» предприятиесендә генераль директор вазыйфаларын башкардым. Татарстан Республикасының Милли банкында тәэмин итү хезмәтендә эшләдем. «Татарстанның атказанган халыкка көнкүреш хезмәте күрсәтү хезмәткәре» дигән мактаулы исемем бар.

Янәшәмдә Равил булмаса, андый югарылыкларга ирешә алыр идемме икән әле?! Һәрвакыт кешеләргә игелек кылучы чын ир солтаны ул минем! Башкарган эшләре дә бик җаваплы. Равил Габделнур улының хезмәте күп еллар буена Татарстанның су ресурслары белән бәйле булды. Кече елгаларның энергетик байлыгы һәм мелиорация фонды юнәлешендә эшләде ул. Ленинградтагы Гидрология һәм су ресурслары Төньяк фәнни-тикшеренү институтының Казан бүлеге институтының директоры итеп билгеләнде. Белем дәрьясына чумып, техник фәннәр кандидаты, авыл хуҗалыгы аграр фәннәр академиясенең шәрәфле профессоры булды. Аның тырышлыгы белән Казанда экология институты оештырылды. Ул – Россиянең атказанган экологы.

Ә хатын-кыз кайда гына эшләсә дә, кем генә булса да, барыбер әни кеше булып кала икән. Улларыбыз Рөстәм белән Айдарны шыплап тулган троллейбуста мәктәпкә озатулар (кесә телефоннары юк, ничек барып җиткәннәрен белмим), ата-аналар комитетында эшләп йөрүләр, җәйге каникулларда балаларны өчәр айга пионер лагерьларына җибәрүләр (чөнки калдырыр урын юк!)... Аллага шөкер, улларыбыз үсеп җитеп, югары белем алдылар, мәртәбәле эшләргә урнаштылар, башлы-күзле булдылар. Рөстәмебез КАИ тәмамлады, армия сафларында хезмәт итәргә дә өлгерде. Мәскәүдә зур транспорт предприятиесендә коммерция директоры булып эшли. Хатыны белән дүрт малай үстерәләр. Айдарыбыз башта җиңел промышленность техникумын, аннары КДУның юрфагын тәмамлады, финанс-икътисад институты каршындагы курсларда белемен күтәрде, ЮНЕСКО каршындагы Дөнья институтында укыды. Хәзер ул Россия мөселман эшмәкәрләре ассоциациясе президенты. Бик матур дини гаилә корып, җәмәгате белән өч бала тәрбиялиләр. Хәзер җәмәгатем Равил белән Айдар улымның гаиләсе – хатыны Эльвира, балалары Әмир, Әсәл, Мәрьям, бергәләп, бер нигездә яшибез. Балалар тормышта югалып калмады – нык адымнар белән атлыйлар, йөзебезгә кызыллык китермиләр.

Әтиебезнең яшәү үрнәге, гаиләсенә булган җылы мөнәсәбәте – һәркемгә үз тормышында файдаланырлык бер хәзинәдер.

Менә хәзер уйланып утырам да бер нәрсәне ачык аңлыйм: гаиләбез уңышларының сере бит бик тирәндә ята! Ислам динен, рухи-әхлакый кыйммәтләрне саклауга зур өлеш керткән әтиебез, авылдашлар күңеленә «ак бабай», «мулла бабай», «Нарыш аксакалы» (ул чыгышы белән Башкортстанның Туймазы районыннан) булып кереп калган Исмәгыйль Сәлимшаһ улы Сәлимшин тәрбиясе, аның үрнәге, мирасы, кулъязмалары, аның безгә язып калдырган васыятьнамәсе никадәр көчкә ия булган! Кулъязмаларның берсендә, буш калган урында, әтиебез: «Бу урында оныкларым дәвам итәр», – дип язган. Мин улларымны, оныкларымны, туганнарымның балаларын сөенеп искә төшердем. Сүзләрең рас килде, әти! Әтинең юлы бик катлаулы булса да, хәзерге һәм киләчәк буын өчен бик гыйбрәтле, зур игътибарга һәм ихтирамга лаек. Аның васыятьнамәсен ничә тапкырлар гына укымаганбыздыр. Ул безнең гаиләнең тормыш, яшәү канунына әйләнде.

«Балаларым һәм барлык туганнарым! Мин хәзер картайдым инде. Әҗәл вакыты билгеле түгел, билгеле булмаса да, мин Алладан сездән алда дөньядан ки-

PRESSA.RU

түемне сорыйм. Шуның өчен дә сезгә беркадәр сүзләр язып куям, әүвәл Аллаһыны бер диеп. Моны бервакытта да исегездән чыгармагыз. Икенчесе, гамәл кылган Пәйгамбәрне хак дип белегез. Шулай булсагыз гына теләгегезгә ирешерсез.

Дөньяда беркем дә мәңге яшәми, Аллаһы Тәгалә беркемнең дә гамәленә мохтаҗ түгел. Яхшы булсак та – үзебез өчен, начарлыкның да җәзасы үзебезгәдер.

Барчагызга шуны әйтәм: үзегездән кечеләрнең эшләренә нык күзәтчелек итегез. Шулай, балалар, Аллаһы риза булмаган эшләрдән бөтен көчегез белән сакланыгыз. Коръән кушканча яшәгез…

Их, балалар! Гомерләр бик тиз үтә икән… Үтте шул яшьлек заманым, кайтмас инде ул мәңгегә… Атнакичләрдә, җомга көннәрендә безне искә алып Коръән укытырга тырышыгыз. Шул рәвешле, балаларыгызга да Аллаһының барлыгын, берлеген белгертегез.

Кыямәт көнендә дәгъвалы булмасыннар, өстегездән бурычны төшерегез, бала балигъ булганчы аңлатсагыз, өстән бурыч төшәр…

Дөньядан югалганың соңында яхшылык белән исемең, йә яхшы балаң, йә адәм файдаланырлык эшең калсын дигән Пәйгамбәребез. Тагын бик зур үтенечем: җеназа намазыннан башка куя күрмәгез, мөмкин булса, гүр сәдакасы бирерсез.

Дөньядагы кебек, килешмәгән эшләрне кире кайтарып төзәтеп булмый. Бу – мөмкин түгел! Шуңа күрә аларны фани дөньяда төзәтергә тырышыйк.

Ике улыбыз һәм җиде оныгыбыз – бик зур байлыгыбыз! Әлхәмдүлилләһи, Аллаһыга чиксез рәхмәт!



Дөнья – ахирәтнең игенедер. Дөньялыкта азык әзерләмәсәң, ахирәттә ачыгырсың. Шулай ук һәр эшегезне Аллаһыга тапшырып башкарыгыз. Үзегезне зур күреп йөрмәгез, бертөрле җан иясен дә гаепләмәгез. Авырлыклар килсә, кешедән күрмәгез, һәр авырлык һәм тарлык үзебезнең начарлык сәбәбеннән киләдер. Аллаһы Тәгалә һичкемне гаепсезгә җәзаламый…

Их, балалар! Мин бит үзем өчен дә, шулай ук сезнең өчен дә бик куркам. Ник дигәндә, балаларга дини тәрбия бирү ата-аналар өстендә зур бурыч булып тора.

Минем Коръәнем, башка төрле китапларым, дәфтәрләрем бар. Сез аларны кадерсез итмәгез, үзегез укый алмасагыз, укый торган кешегә булса да бирегез. И Аллам, балаларымны һәм туганнарымны, үземне дә дөнья, ахирәт хурлыкларына төшермә!

Балаларым, мине озатырга килүчеләр булса, аларга йомшак кына итеп әйтерсез: мөмкин булган кадәр «Ләә-иләһә иллаллаһ»ны күп укысыннар. Мөмкин булса, каберемә билге куярсыз. Мин дөньяга мәңгегә килмәгән, бер аерылыр көн килер. Шул вакытта мине искә алып, дога кылырсыз.

Минем бу дәфтәремне теләсә кая ташламагыз, картайганчы үзегездә саклагыз. Сезгә тагын бер үтенеч: ислам динендә өстегезгә йөкләтелгән бурычларны, ягъни намаз, ураза кебек гамәлләрне үтәргә тырышыгыз. Ислам дине кушкан гамәлләр авыр түгел, ләкин теләк кирәк. Теләгең булса, үтәргә мөмкин. Хушыгыз.»

Нәселебезнең дин өчен тырышуы – барысы да әтиебезнең ихлас дога һәм гамәлләре нәтиҗәсе. Үзем дә дини гыйлемнәр алдым, өч тапкыр хаҗ сәфәренә бару бәхетенә ирештем. Тәвәккәлләп, зур эшкә дә тотындым: әтинең нәсел шәҗәрәсен, югалган мирасыбызны эзләп табарга, шул хәзинәне балаларыбызга, оныкларыбызга тапшырырга ниятләдем. Әтинең тарихи эзләре буйлап Ютазы районының Кәрәкәшле, Бәйрәкә авылларын урап килдем. Аның туган авылы Нарышка бардым, Татарстан белән Башкортстан чигендә урнашкан Чүтегә сугылып чыктым. Күрше Җәүмәт, Зәйпе, Ак Чишмә авыллары да әтинең гомер тарихына кереп калган. Кәрәкәшледә әти тегермәне янындагы елга аша салынган басмаларда басып тордым, Исмәгыйль чишмәсе суларын эчтем… Һәм шулар тәэсирендә күптән түгел «Дөнья – ахирәтнең игене яки Нарыш җәүһәрләре» дигән китапны чыгаруга ирештем. Китапта шулай ук әтиебезнең вәгазьләре, нәсыйхәтләре, фронт көндәлеге, шигырь-поэмалары, фәлсәфи уйланулары тупланды, истәлекләр, хатирәләр урын алды.

…Алтын туйдан башланган хикәям менә шулай гаилә тарихына барып тоташты. Һәрчак янәшәмдә мине хуплап, миңа булышып торган җәмәгатем Равил, улларыбыз Рөстәм белән Айдар һәм аларның гаиләләре, оныкларыбыз, кадерле туганнарым – беренче ярдәмчеләрем булды.

Шөкер, без 50 ел эчендә үзебезнең дә, балаларыбызның да узган гомерләреннән бик канәгать, алдагы көннәребездә дә шулай яшәргә насыйп булсын.

МӘДӘНИЯТ

Хельсинкиның Мәхәллә йортында Рәшит Ваһапов исемендәге халыкара татар җыры фестиваленең (продюсеры Рифат Фәттахов) бер концерты узды. Концертны Финляндиядәге татар диаспорасы рәисе Атик Али белән имам-хатыйп Рамил Беляев ачып җибәрде. Анда фестивальнең яшь лауреатлары Рәнис Габбазов, Гөлсирин Абдуллина, Азат Абитов, виртуоз музыкант Ринат Вәлиев чыгыш ясады. Татарстан Дәүләт Советының фән, мәгариф, мәдәният һәм милли мәсьәләләр комитеты рәисе, халык шагыйре, күренекле җәмәгать эшлеклесе Разил Вәлиев бәйрәмнең мәртәбәле кунагы иде.



Камал театры труппасы – 12 яшь артист һәм оркестрның 13 музыканты – Казан аэропортында яшь артист Ришат Әхмәдуллинны Салих Сәйдәшев көен уйнап каршы алды. Казан аэропортындагы бу тамаша – театрның «йөзек кашы» булган «Зәңгәр шәл» спектаклендә Булатны каршы алу күренеше – театрның чираттагы флешмобы иде. Камал театрында шушы спектакль белән яңа – 112 нче сезон ачылды.

КОТЛЫЙБЫЗ

Татарстанның атказанган артисты Лилия Муллагалиева Мәскәүдә Останкинода узган XII «Золотой голос России» халыкара вокал бәйгесендә татар халык җыры «Гөлҗамал»ны җырлап – III дәрәҗәдәге лауреат, автор җыры өчен дипломант исемнәрен яулады.



МӘГАРИФ

Дөнья әдәбиятына зур өлеш керткән бөек рус язучысы Л. Н. Толстойның тууына 190 ел тулу уңаеннан һәм Толстойлар гаиләсе өчен Казан тормышының мөһимлеген истә тотып, Татарстан Президенты указы нигезендә, 2018 ел Татарстанда, рәсми рәвештә, Лев Толстой елы дип игълан ителде.

«Державин укулары» XIII Халыкара фәнни-гамәли конференциясе үз эшен Казан федераль университетының юридик факультеты ассистенты Алсу Хөрмәтуллинага Державин премиясен тапшырудан башланып китте. Премияне яшь галимгә ТР Президенты Рөстәм Миңнеханов тапшырды. Алсу киләчәктә югары уку йортында укыту турында хыяллана. Монографиясендә ул теория һәм практиканы бәйләп алып баруын ассызыклады.

Казанның 3 нче гимназиясендә «Беренче экологик сыйныф» проекты эшли башлады: экологик сыйныф ачылды. Ул Татарстан экология һәм табигый байлыклар министрлыгының республикада экология елы кысаларында гамәлгә ашырыла. Беренче сыйныф балалары Табигать тарихы музеенда Җирнең геологик тарихын өйрәнде, уникаль минераллар коллекциясе белән танышты, динозаврлар турында мультфильм карады.

ҖӘМГЫЯТЬ

Татарстан Президенты Рөстәм Миңнеханов Ташкентта эш визиты кысаларында Үзбәкстан Президенты Шәүкәт Мирзияев белән очрашты. Анда алга таба сәүдә-икътисадый хезмәттәшлекне киңәйтү мәсьәләләре каралды. Нефть-газ химиясе, автомобильләр төзү, сәнәгать җиһазларын җитештерү, медицина һәм фармацевтика, авыл хуҗалыгы сәнәгате өлкәләре өстенлекле булырга тиеш дип билгеләнде; мәгариф, сәламәтлек саклау, мәдәният, туризм буенча багланышларны арттыру кирәклеге ассызыкланды.
Ул шулай ук андагы татар диаспорасы белән очрашты. Ташкентта 100 меңнән артык татар яши, ә Үзбәкстанда, гомумән, 280 меңләп милләттәшебез гомер итә. «Үзбәкстандагы татар диаспорасы дөньяда иң күп санлыларның берсе», – дип билгеләп үтте Рөстәм Миңнеханов.

«Сөембикә» журналы, Россия Авыл хуҗалыгы министрлыгы уздырган Бөтенроссия бәйгесендә катнашып, «Авыл гаиләсенең заманча йөзе» номинациясендә 3 нче урын яулады. Шунысын да әйтергә кирәк: авыл тормышы гомер-гомергә «Сөембикә» журналының төп темасы булды. Бәйгегә 81 төбәктән 5329 журналистның эше кабул ителгән.

Казан Россиянең иң кунакчыл шәһәре дип табылган. Бу хакта «Лента.ру» редакциясе Booking.com компаниясе тикшеренүләренә таянып яза. Татарстан башкаласы сәяхәтчеләрне уникаль архитектурасы, транспорт уңайлыгы, үзенчәлекле ашлары һәм халыкның кунакчыллыгы белән таң калдырган. Икенче урында – Мәскәү, өченче урында – Санкт-Петербург.

СПОРТ

Чаллы спортчысы Екатерина Чернышева Сочида триатлон буенча узган халыкара ярышларда призлы урын яулады. Чаллы кызы үз яшендәгеләр категориясендә дистанцияне 12 сәгать 16 минут 14 секундта узды. Ярышлар спортның йөзү, велоузыш, йөгерү кебек төрләрен эченә алган иде. Ярышка 15 илдән, шул исәптән, Германия, Франция, Бельгия, АКШ, Кипр, Австралия, Сингапурдан 1200 атлет килгән иде.



PRESSA.RU



ҺӘРКАЙСЫБЫЗ – АЛЫШТЫРГЫСЫЗ

«ГАИЛӘ – ҮЗЕ БЕР ДӨНЬЯ УЛ. АНДА БАРЫСЫ ДА ГАДӘТИ, АҢЛАЕШЛЫ, КАДЕРЛЕ.

Зилә һәм Булат Мортазиннарны белмәгән кеше юктыр да Арчада! Хәер, Арчада гынамы соң?! Телевизордан да күрсәттеләр, газеталарда да язып чыктылар. Быел Ульяновскида узган «Идел буеның уңышлы гаиләсе» фестиваль-конкурсында «Гаилә эше» номинациясендә җиңү яулап кайттылар әнә.

Әле дә күз алдында: Арча балалар сәнгать мәктәбенең хореография бүлеге укытучысы Зилә, баянчы ире Булат (музыка факультетын тәмамлагач, ул читтән торып төзелеш институтында укый; Казандагы бер компаниядә сату бүлеге җитәкчесе), уллары Камил белән Рүзәл, туган-тумача, әби-бабайлар, бергә эшләгән хезмәттәшләр, дуслар – барысы 15 кеше «ГАЗель»гә төялеп, Татарстан данын якларга чыгып китә. Рус, мари,

мордва, удмурт, чуаш, башкорт гаиләләре үзен күрсәткән 14 гаилә арасында Мортазиннарга җиткәннәре булмый да! Жюри рәисе Владислав Третьяк та ошата үзләрен. «Биредә Татарстан командасында ике яшь хоккейчы катнаша», – дип, һич көтмәгәндә сәхнәгә үз култамгасы куелган кәшәкәләр алып чыга. Камил белән Рүзәлнең түбәсе күккә тия! Боз сараенда хоккей уйнау иң яраткан шөгыльләре булсын да!

Узган ел бу гаилә үзен «Нечкәбил»дә дә күрсәткән иде инде. 45 конкурсантның 12 се арасында финалга чыгып, «Пирамида»да чыгыш ясады Мортазиннар. Гаиләдәге гореф-гадәтне саклау, берберенә хөрмәтне Зилә сәхнәдән шулкадәр матур итеп күрсәтә алды, аны «Иҗади нечкәбил» дип бәяләделәр. Ә август ахырында Татарстан Республикасы Президенты Рөстәм Миңнеханов һәм аның тормыш иптәше Гөлсинә ханым оештырган мәҗлестә Булат белән Зилә барысының күз уңында булдылар. Хөрмәткә лаек гаиләләр арасында иң яшь парлар Мортазиннар иде!

Әйе, алар – матур гаилә! Аларга сокланалар, аларны кайда да үрнәк итеп куялар. «Бездә һәр кеше алыштыргысыз, һәрнәрсә үз урынында, – ди әнә Зилә. – Салисә әбинең әкиятләре, Сиринә әбинең тәмле бәлешләре, Азат бабайның үләннәрдән пешергән чәйләре, Фаил бабайның Арчадагы кәҗәләре, минем чәчәк түтәлләрем, йорт куяннарыбыз, умарталарыбыз... беребезгә дә чит була алмый. Без аларны тиешенчә бәяли, саклый белергә тиеш».

Гаиләнең чишмә башы Казан дәүләт мәдәният һәм сәнгать университетына барып тоташа. Берсе – музыкант, икенчесе – биюче. Арча егете Яшел Үзән кызын бер күрүдә якын итә. Уйнап-шаярып сөйләшкәндә, Булат Зиләдән сорап куя: «Син яшисе өйнең түбәсе нинди булырга тиеш?» «Зәңгәр!» – дип җавап бирә кыз. Гаҗәп, Булатлар Арчада салып бетереп яткан йортның да түбәләре зәңгәр икән бит! Нәкъ Зилә хыялындагыча! Булат белән уртак яклары да күп икән: икесе дә авыл баласы, икесе дә үҗәт һәм тырыш, икесе дә сәнгатькә мөкиббән, икесе дә лидерлар... Тагын бер уртак таяну ноктасы бар бит әле: Зилә дә, Булат та – «Сәләт»некеләр, әйдаманнар. Үз дәрәҗәңне белергә, максатчан булырга, башкалар күңелен күрергә, югалып калмаска... һәм һәрчак җиңәргә өйрәнгән һәм башкаларны да шуңа өйрәтә алган кешеләр. Үз гаиләләренең «Сәләт» ветераннары исемлегендә булулары белән горурланалар. Билардә узган «Сәләт» форумын бер елны да калдырмаска тырышалар. Ә өйләренә – һәрвакыт сагынып кайталар!

Аларның үзенә тартып торучы нурлы нигезләре кадерле кунакларны – ике яктан да әти-әни, туганнарның гаиләләрен еш кабул итә. Елларда, бәйрәмнәрдә зур йорт шау-гөр килеп тора: ике кодагый чөкердәшеп бәлеш сала, Зилә «фирменный» тортын пешерә, Булат мунча ягып җибәрә. Аннары инде табынга җыелалар. Мәтрүшкәле, карлыган яфраклы, гөлҗимешле чәй янына урмандагы умарталыкларыннан кайткан бал менеп утыра (аларның 30 баш умартасы бар!), Фаил абый белән Булат кулларына тальян, баяннарын ала... И күңелле чаклар! Мондый көннәрдә Зилә еш кына үзенең балачагын искә төшерә. Дәү әнисе каникулларда оныкларын гына түгел, туганнан туган, хәтта өченче буын туганнарын да үз янына җыя иде. Моның тирән мәгънәсен яши-яши аңлый Зилә: балалар, туганнар бер-берсен белеп үссеннәр, туганлык җепләре өзелмәсен дигән икән бит ул! Дәү әнисе юк инде, тик алар династиясе Сабан туена ел саен Яңа Чишмә районының Зирекле авылына төп нигезгә җыела. Туганнар Татарстаннан гына түгел, Мәскәүдән, Пермь якларыннан ук кайта. Гаилә традицияләрен саклап яшәүче Мортазиннарга быел Франциядән кунак килеп төшкән. Удмуртиядән китеп, шул илдә яшәүче журналист Светлана Русских-Энгехард алар йортындагы җылылыкка, хөрмәткә сокланып, тагын кайтасы килү теләге белән киткән.

Бөтен Татарстанда беләләр инде үзләрен.

...Мортазиннар тагын сәфәргә җыена. Бу юлы – Мәскәүгә! Бөтенроссия «Ел гаиләсе-2017» онлайн-бәйгедә «Гаилә гореф-гадәтләре» номинациясендә җиңү яулаганнар! Булдыралар Мортазиннар! Хәерле юл телик аларга!



PRESSA.RU


Эльвира САФИНА

Хит җырлар, матур шигырьләр авторы ул. Оскар Усманов, Фирзәр Мортазин, Альфред Якшимбетовлар белән уртак иҗатта туган җырлары Илсаф, Гүзәл Уразова, Илгәрәй, Айгөл Бариевалар репертуарында. Ә менә монысын аеруча яраталар бугай: «Сыерын да савабыз, печәнен дә чабабыз... / Бер эштән дә курыкмыйбыз, / Без бит авыл кызлары!» Лилия Муллагалиева белән икәүләп иҗат иткәннәр! Әйе инде, Эльвира Сафина турында сүзебез! Шушы көннәрдә филармониядә узган иҗат кичәсендә ул инде йолдыз булып балкыды!
Чүпрәле районы Яңа Кәкерле авылында туып-үскән кыз максатчан-үҗәт тә, хисле-хыялый да: тормышында фән белән иҗат бер-берсен тулыландыра. Ул – филология фәннәре кандидаты, Татарстан Фәннәр академиясенең Г. Ибраһимов исемендәге Тел, әдәбият һәм сәнгать институтында лексикография бүлегендә өлкән фәнни хезмәткәр.

УЛЬТРАМАРИН БУЯУ АЛЫП...

Сүз

Төн җәелеп яткан җиһаныма,
йомарланган кара мәчедәй.
Бар да йоклый,
тәмле төшләр күрә,
тик мин янам
бәйрәм шәмедәй.
Сүзләр сайлыйм, имеш...
Бер-бер артлы тезәр өчен
сәйләннәрдәй...
Арып киткән бугай күңелем
әйлән-бәйләннәрдән.
Түз!
Сүз!!!
Сүз дәвалар,
тирәнәеп өлгермәсә
яраларың,
актан азрак булса
караларың...
Түз!

* * *

Әйе, талантлы шул дустым,
Шуңа үзен өстен күрә дә.
Аның фикеренчә, беркем түгел
Хәтта дәрәҗәле түрә дә.
Кимчелекләр таба һәммәбездән,
Без, янәсе, «авыл», гадиләр,
Заман белән бергә атламыйбыз,
Аннан калышабыз – кадимнәр.
Өстән генә шулай карап тора,
Кешеләрне сайлап сөйләшә,
Үзе кебек «каймак»ларның гына
Хәлен белә, көен көйләшә.
...Ниндидер кыл зыңлап
өзелдеме?! –
Утырасы килми янәшә...

* * *

Һәрберебез юлчы бу тормышта,
Үзе белән йөртә каләмен.
Төрле төсләр,
төрле сүзләр белән
Мәңгелеккә яза сәламен.
Кемнәр язар икән безнең хакта,
Кемнәр язар икән без юкта?!
...Ә кәгазьдә әле –
Күп нокта...

* * *

Ультрамарин төсле буяу алып
Мин ясадым сине, үземне...
Юл чатында сине күреп алып,
Сиңа баккан ике күземне.
Сөю биргән, сөйгәнемне алган
Моңсу фасыл – зәңгәр көземне.
Әйтергә дип авызымны ачып,
Әйтми калган теге сүземне...
Ультрамарин бетте...
Таный алмыйм – бу соң үземме?

* * *

Яшел кара белән язам сиңа
Көнделдәге иң зур серемне:
«Шуннан бирле сине уйлап яшим,
Син беләдең йөрәк түремне».
Яздым да бит, җибәрмәмен, ахры,
Бу хатым да калыр үземдә.
Әллә сагыш, әллә өмет булып
Яшь бөртеге балкый күземдә...

* * *

Шулай буламыни, еллар үтеп бара,
Күргәнем юк сине бер гомер.
Тик һаман да син дип яна әле
Йөрәгемдә утлы бер күмер.

* * *

Күңелемә төшкән күләгәне
Күрми генә узып кит әле.
Узып кит,
тик борылып карама,
Сиздермичә генә көт әле...
Син барыбер мине көт, яме?!

* * *

Серле гөл икән ул мәхәббәт:
Чәчәк аткан чагы бик рәхәт.
Кавыштырса насыйп яр белән,
Язмышыңа укы мең рәхмәт.
Моңлы гөл икән ул мәхәббәт:
Көлдерә, елата, юата.
Көннәрең гел кояшлы булыр –
Мәхәббәтне генә югалтма.
Назлы гөл икән ул мәхәббәт:
Назга күмә бөтен җиһанны.
Һәр кешене нурлы итүче
Мәхәббәттән олы хис бармы?



Ренат Галиәскәр исеме яшьләргә яхшы таныш. Балтач районы Борнак Иле авылында туган. Казанда югары уку йортын тәмамлаган. Җыр текстлары, шигырьләр яза, концертлар алып бара, бәйрәмнәр оештыра. Мәктәп елларында ук иҗат дөньясына алып кереп киткән татар теле һәм әдәбияты укытучы Энҗе Закированы (шагыйрә Эльмира Шәрифуллинаның бертуган сеңлесе) рәхмәт сүзләре белән искә төшерә. Язган шигырьләрен интернеттагы шәхси битенә элеп бара. «Сөембикә» укучыларына Ренатның үзенчәлекле шигырьләрен тәкъдим итәбез.

Ренат ГАЛИӘСКӘР

ЕЛМАЙ... СӨРТ ЯШЬЛӘРЕҢ...

Яратамын күзне

Яратамын көзне, көйсез чөнки...
Синең төсле бик еш үзгәрә:
Чалт аяз көн торган мизгелдә дә
Салкын икәнлеген сиздерә.

Көннәр буе төтәп торган яңгыр
Ташлаттыра барлык эшләрне.
Тәрәзәдән карап утырасың
Сүтмәк булып узган хисләрне.

Салкын җиле җылы җәйләрдән соң
Чынбарлыкка ата күкләрдән.
Соңгы чиккә җиткән чаклар була,
Тәмам туеп синсез кичләрдән.

Яратамын көзне, көйсез чөнки...
Синең төсле бик еш үзгәрә...
Җил-яңгырлар булып узганнан соң,
Чалт аязып, көлеп җибәрә.

* * *

Бар кешегә бирелсә дә куәт,
Биек таулар атлап үтәрлек,
Йөрәкләргә салынмаган икән
Шул куәтне җиңәр үҗәтлек.

Ялгышалар бөркетләргә тиңләп,
Үз иткәнне кыя-тауларны...
Таулардан да биек күтәрелгән
Күгәрченнәр җирдә бик азмы?!

Максатлардан сыгылса да канат,
Таулар баса төшеп иңнәргә,
Бөркетләр дә мәҗбүр була кайчак
Үзәннәрнең җилен сөзәргә.

Ак күгәрчен булып югарыдан
Колачларсың яшьле күңелне...
Итәгеннән горур таш-тауларның
Бер көн күзәтермен мин сине...

Соңардың

Елмай... Сөрт яшьләрең... Үрелсәм дә,
Битләреңә минем кул җитмәс.
Ике яктан бергә кычкырсак та,
Уртак бәхет безне ишетмәс.

Мин бит сине, җаным, бу гомердә
Бер минут та уйлап туймадым.
Ә син күпкә түгел... азга түгел,
Мәңгелеккә бары соңардың...

Бер гомергә генә соңладың...

Көтәбез

Яшь вакыт, дингә карамый,
Һаман көтәбез.
Күпләребез көтеп туеп,
Таләп итәбез.

Кышын зарыгып көтәбез
Чәчәкле җәйне.
Дүшәмбедән сагындыра
Шимбә, якшәмбе.

Җылы караш, сәлам хаты,
Уңайлы очрак;
Кемдер чирдән дәва көтә,
Ходайдан сорап...

Көтеп алып, бик еш кына
Күрми үтәбез.
Терминнар күп, тик асылда
Бәхет көтәбез.

Әгәр инде...

Синнән миңа шалтырату килеп,
Телефоным беркөн алмасам;
Язган хатларыңа бер сәбәпсез
Җавап әгәр инде тапмасаң;

Әгәр инде кинәт бер инглиз кебек
Эзсез генә китеп югалсам;
Юлларыңда кабат очрамасам,
Кичен килеп, куна калмасам;

Әгәр инде кире торалмасам
Талган килеш татлы йокыга,
Гомерләр бит матур бер җыр гына,
Уятырга, зинһар, ашыкма...

Нигә шулай булды әле, диеп,
Авыр уйлар уйлап, юрама.
Мәхәббәт тә матур бер уйдырма.
Бары мин юк. Килеш. Шул гына...

PRESSA.RU



Люция ӘБЛИЕВА

СИН КЕМ КЫЗЫ?

(Хикәя)

– Камил, син мине яратасыңмы?

Егерме елдан артык торган хатыны авызыннан бүген беренче тапкыр бу сорауны ишеткән Камил, телевизор пультына баскалап, бер каналдан икенчесенә күчә башлады.

– Әнисе, яратмасам, әллә кайчан ташлап киткән булыр идем инде.

– Ышан сиңа!

Фәнәзия кәнәфидән Камил янына диванга күчеп утырды.

– Камил, шулай да әйт әле, яратасыңмы мине?

Камил, хатынының өзми-куймый торган гадәтен белгәнгә, җиңелчә генә иңеннән кочаклап алып: «Яратам, яратам, әнисе», – диде дә телевизор каравын дәвам итте.

Хәер, карый дип инде... Пульт төймәләренә баса торгач, телевизор гомергә бер тапкыр да карамаган каналда туктап калу сәбәпле, Камил нәрсә караганын үзе дә аңламый тора иде.

Ярый әле Фәнәзиянең телефоны шалтырап, икенче бүлмәгә чыгып китте. Юкса: «Яратам, яратам, әнисе», – диган Камилнең комач кебек кызарып утыруын сизмичә калмас иде.

Көне туры килүен әйт син аның! Нәкъ менә бүген ул җитәкләгән оешмага яшь чагында яратышып, мәңге аерылмаска сүз биргән мәхәббәте Җәүһәриянең кызы эшкә килгән көнне! Юк, Фәнәзия Җәүһәрия турында белми. Шуңа күрә хатынының соравы очраклы туры килү генә икәненә Камил һич шикләнми. Тик шулай да сак булырга кирәк. Җәүһәрия белән бер елга якын яратышып йөргәннәрен Фәнәзия белмәсә дә, Камил үзе белә бит!

Өйләнешүләре дә кызык булды шул Камил белән Фәнәзиянең. Гадәттә, колхоз җитәкчеләре кыш көне ял итәләр. Камилнең әтисе дә Яңа еллар үткәч, Кырымга санаторийга китте. Кайтышлый Камил янына сугылды. Ирләрчә, сүзне уратып тормыйча, турыдан әйтте:

– Улым, мин «килен» таптым әле, ягъни сиңа кәләш! Диплом алу белән башлы-күзле итәргә булдык әле без сине, әниең дә каршы түгел.

– Кызык икән! Ә мин ризамы соң?

– Риза булмый кая барасың, улым?

Камил әтисенә Җәүһәрия турында әйтмәкче булып авызын ачкан иде, әтисе өлгеррәк булып чыкты:

– Ярый, ялга кайткач, сөйләшеп бетерербез. «Килен» бер кашык су белән йотарлык, соңыннан үзең дә рәхмәт әйтерсең әле, – дип сөйләшүгә нокта куйды. Аннан машина янында аягы өшүдән сикергәли башлаган шоферы Әфкатькә, тәрәзәсен ачып:

– Киттек! – диде.

Ул кичне Җәүһәрия Камилнең кәефе үзгәргәнен әллә каян сизеп каршы алды.

– Әллә бер-бер хәл булдымы, төсең качкан, Камил?

– Юк, бар да тәртиптә, кошчыгым. Әзрәк арыткандыр диплом эше белән утырып. Әйдә, киен, шундый саф һава тышта, йөреп керик әле.

Педагогика институты тулай торагының вахтерлары барысы да Камилне таныйлар, документ та сорап тормыйлар. Җәүһәрияне алып чыгып киткәндә: «Кире кайтарырга онытма!» – дип озатып калалар. Бүген дә кизү утыручы Соня түти нәкъ шулай диде.

Тик Камил, Соня түтине аптырашта калдырып, бүген башкачарак җавап бирде:

– Кайтармыйм, бүген урлыйм Җәүһәрияне!

Камилнең бу сүзләре фәрештәләрнең «Амин!» дигән чагына туры килде дә, килмәде дә...

Әтисенә ялга кайтырга ышандырып калган Камил сүзеннән чыкмады. Район үзәгендәге автовокзалдан каршы алырга әтисе үзе килгән иде. Әтисе юл буена уен сүзләр сөйләп кайтса да, ярты сәгатьлек юлны бу юлы озаграк узгандай тоелды Камилгә.

Теге көнне башлаган «килен» темасына кагылмагач, Камил сөенеп куйды. Тик сөенүе иртәрәк булган икән. Тамак ялгап алгач, сеңелләре белән сөйләшеп утырганда, әтисе белән әнисе аны кече якка чакырып алдылар.

– Улым, – дип сүз башлады әтисе. Камил әнисенә күз төшереп алды. Әнисенең әтисе сөйләгәнен куәтләп торуы йөзенә чыккан иде. – Тау белән тау очрашмаса да, кеше белән кеше очраша икән. Санаторийда институтта бергә укыган иптәшемне очраттым. Күрше өлкәдә райком секретаре булып эшли. Бик акыллы, тырыш, максатчан иде студент елларында ук. Сөйләшеп киткәч, синең белән бер яшьтәге кызлары барлыгы ачыкланды. Быел үзләрендә институт бетерә. Фотосын да күрсәтте, бик чибәр. Исеме Фәнәзия. Ике атна буе гел бергә йөрдек кордаш белән. Кыскасы, без сезне таныштырып, кавыштырырга булдык.

– Камил, әтиең кеше таный ул, – дип сүзгә кушылды әнисе, – үзеңнең дә өйләнердәй кызың күренми бугай.

Камил ничек итеп әтисе белән әнисенең күңелен кайтармый гына Җәүһәрия турында әйтергә кирәклеген уйлап бетермәгән иде әле.

– Иртә кичтән хәерлерәк, диләрме әле? Иртәгә сөйләшеп бетерсәк, ничек булыр икән?

Әтисе ризалыгын белдереп ияген какты.

Ярты төнгә кадәр йоклый алмый ятты Камил. Кичә Җәүһәриягә әтисенең ял йортыннан «килен» табып кайтканын көлеп сөйләсә дә, монда эшләр еларлык булып бара икән ләбаса. Әнисе белән әтисе чынлап торып туйга әзерләнеп маташалар.

Камил Җәүһәрияне бер күрмәгән-белмәгән Фәнәзиягә алыштырырга җыенмый иде. Тик... Әтисенең холкын белә Камил. Аныңча булмаса, яхшылык көтмә. Әнисе дә гел: «Әтиегез ни әйтер, әтиегез риза булмас, әтиегез белсә ачуланыр», – дип үстерде аларны. Өч ел флотта хезмәт итеп, институтның соңгы курсында укып йөргән егет булса да, Камил өчен әти һаман да әти булып кала... Үзен дә тиргәп алды Камил. Нигә элегрәк сөйләнмәде соң әле ул Җәүһәрия турында әниләренә? Сорау биреп торган була бит әле! Әтисенең хупламавын белеп яшерде ул. Камил институтта укый башлагач, әтисенең тел төбендәге «үзеңә тиң... безгә тиң... нәсел-нәсәбе... кода булырдай» сүзләрениндирәк кызларны сайларга кирәклегенә ым биреп тора иде. Ә Җәүһәрия нибары гади колхозчы кызы. Үзе дә авыл малае булгангамы, Камил, шәһәр егетләре күбрәк сайлаган техник институтта укыса да, авыл кызларын якын итә шул. Факультетның партия оешмасын җитәкләгән «авыл малаена» шәһәр кызлары да бәйләнеп карады, тик җиңә алмадылар. Җәүһәрия белән очраша башлагач, әкренләп югалып беттеләр тагын.

Җәүһәрия белән алар студентлар арасында барган чаңгычылар ярышында таныштылар. Зәңгәр күзле, алтын сары чәчле Җәүһәриянең кино актрисаларыннан бер ким җире дә юк иде. Бәлки, артыграк та булгандыр әле. Ярышлар вакытында Җәүһәрия янында берничә егетнең бөтерелеп йөргәнен дә искә алып куйды шул вакытта Камил. Җәүһәрия Камилгә үзе килеп эндәшмәсә, алар ул көнне танышып та китмәгән булырлар иде. Ни әйтсәң дә, үткерлеге бар шул Җәүһәриянең. Сизгер дә, уңган да. Тик бер килмәгән ягы бар икән – түрә баласы түгел. Камил үзенең юморыннан үзе көлеп куйды.

– Улым, әллә бүген төшкә кадәр йокламакчы буласың инде?

Камил әнисенең тавышына уянып китеп, сәгатькә күз салды. Тугыз тулып килә. Әйе, авыл өчен бу чынлап та «төшлек». Әтисе хуҗалыкны әйләнеп кайтыр вакыт җиткән.

– Әни, ун минуттан торып утырган булам.

Камил сикереп торып, мускулларын яза башлады.

Әтисе озак көттермәде. Җыелышып чәйләп алгач, урта ишекне ябып куйдылар. Мәктәп яшендәге сеңелкәшләре колагына иртәрәк иде әле бу сөйләшү.

– Менә сиңа иске авыздан яңа сүз. Моңа кадәр берниндидә Җәүһәрияләр юк иде бит әле, – дип, Камилнең сүзен бүлде әтисе.

Җәүһәриянең кайсы яктан, әти-әниләренең кем булуын ачыклагач, йөзенә ризасызлык билгеләре чыккан әтисе, турыдан:

– Арагыз тирәнгә кермәгәндер бит? – дип сорады.

– Тирәнгә кермәде.

– Соң... Тирәнгә кермәгәч.

– Тирәнгә кермәсә дә, аңа өйләнергә сүз бирдем.

– Шул гынамы? – әтисе өйне яңгыратып көлде.

– Сүзгә син хуҗа, ничек биргәнсең, шулай аласың. Калага баргач, озакка сузмый, араларыгызны өзү җаен күр. Җәйгә Фәнәзия белән туегыз, менә шул.

PRESSA.RU

Аннан Камил белән сүзне төгәлләгәнен аңлатып, хатынына дәште:

Рәшидә, Кырым күчтәнәчләрен әзерлә әле, Камилне озаткач, Диларисларга сугылырбыз.

...Хатыны Фәнәзия бүген эшкә иртәрәк кирәк дигәч, Камил шоферына шалтыратып, үзен килеп алмаска кушты. Шәхси машинасында башта хатынын илтеп куйды, аннан эшенә китте.

Эш башланырга бер сәгатьләп вакыт бар, хезмәткәрләр әле берсе дә күренми. Камил кичә Җәүһәриянең кызы Камилә алып килгән хатны тагын бер тапкыр укып алырга булды.

«Камил Касыймович! Исәнмесез! Әгәр мөмкин булса, сезгә шушы хатны тапшырган кызны – Камилә Ризвановны эшкә урнаштырырга ярдәм итә алмассыз микән. Хәзер югары уку йортын тәмамлаганнарны, эш тәҗрибәсе булмау сәбәпле, эшкә алырга тырышмыйлар. Камилә йөзгә кызыллык китерә торган бала түгел. Сезгә ышанып, әнисе Җәүһәрия.»

Бер белмәгән чит кешегә язган кебек «сезләп» сырлаган хатын Җәүһәрия. Хәер, чит кешеләргә әйләндерде шул язмыш аларны.

Камилә тач әнисенә охшаган. Кичә кабинетына килеп кергәч, чак кына «Җәүһәрия!» дип ычкындырмый калды бит Камил.

Ул хатка карап уйга калды. Ничә еллар узгач, Җәүһәрия кабат аның язмышына ни өчен килеп кермәкче була соң әле? Җитмәсә, кызы аша? Җәүһәрияне бик яхшы белә Камил: тиктән генә мөгез чыгара торган кеше түгел ул. Камилнең әтиләре аңа өйләнергә рөхсәт бирмәгәч тә, шашынып, тилереп дәгъвалашып тормады. Диплом алу белән, күрше республикадагы районнарның берсенә химия-биология укытучысы булып китте дә барды. Камил аның бу адымын очраклы рәвештә булса да күрешеп яшәмәс өчен икәнен белә иде. Әйе, алар башкача очрашмады. Хатыны Фәнәзиянең Камил өчен җан атып яшәве дә, бәлки, сәбәп булгандыр. Бәлки...

– Камил Касыймович, Камилә сезнең янга керергә рөхсәт сорый.

– Керсен.

Секретарь чыгып киткәч, Камил тиз генә хатны өстәл тартмасына шудырды. Камилә кабинет ишеген ачканда, Камил җитди кыяфәт чыгарып, җитәкче роленә кереп өлгергән иде инде.

Камилә төс-кыяфәт белән әнисенә охшаса да, үткерлеге аныкы түгел, күренеп тора. Камил беренче генә көн эшләмәгән җитәкче буларак, аңа үзе ярдәмгә килде.

– Йомышыгыз бар идеме?

Камилә оялып кына сүз башлады.

– Әнинең сезнең белән күрешеп сөйләшәсе сүзе бар. Әгәр риза булсагыз...

Камилнең бөтен тәне эсселе-суыклы булып китте. Ләкин «...күлмәге дә сәрпинкә, алтын чәчле, зәңгәр күзле – коеп куйган кәртинкә» Камилә каршында коелып төшмәде.

– Әниегез кайчан килергә уйлый?

– Ул унбиш көнлек ял алган иде, шуңа иртәгә үк килеп җитә ала... Сез каршы килмәсәгез.

– Әниегезне мин кайчан килсә дә кабул итәм, шулай дип әйтегез.

Камилә йомышының шулай тиз үтәлүенә үзе дә ышанмыйча, рәхмәт әйтеп кабинеттан чыгып китте.

Кызык, сентябрь башында укытучылар эш башлый гына әле, ә Җәүһәрия ялга чыккан. Хәер, укытучы булып эшләмәскә дә мөмкин бит. Камил Җәүһәрияне исеннән чыгармаса да, аның белән очрашу эзләп, тормышы белән кызыксынып яшәмәде. Җәүһәрия үзе шулай теләде.

Көндәгедән иртәрәк кайткан Камилгә Фәнәзия аптырап китте.

– Әтисе, иртәләгәнсең, минем әле кичке ашым да әзер түгел.

– Зыян юк, көтәм, әнисе. Эчемдә ач бүреләр уламый. – Аннан, уллары Газинур бүлмәсенә ымлап, – Өйдәме? – дип сорады.

– Гөлгенәсе ниндидер концертта катнаша, лекцияләрдән соң – китапханәгә, аннан – филармониягә, – дип шалтыратты.

Аннан, Камилдән шикләнеберәк:

– Бер-бер хәл булдымы әллә? – дип куйды.

– Юк, әнисе, барысы да тәртиптә. Газинур быел соңгы курсын башлады бит. Планнарын сорашмакчы идем, эшкә кермәкчеме, укуын аспирантурада дәвам итмәкчеме... Гөлгенәсе белән ни уйлый икән?

Фәнәзия алъяпкычын аш-су бүлмәсенә илтеп куйды да Камил янына килеп утырды.

– Син ничек уйлыйсың соң үзең?

– Фән белән кызыксынуы көчле бит, аспирантурада калам дисә, мин каршы түгел.

– Ә өйләнәм дисә?

– Ә син каршымыни? Оныклар да булса, ишәябез, шәп кенә була бит, әнисе!

– Иртәрәк булмасмы димен, егерме ике яшь кенә тулды бит әле Газинурга. Аннан Гөлгенәсен дә ныклап белеп бетермибез әле, ниндирәк гаиләдән икән?

– Бер-берсен яратсалар, анысы мөһим түгел, минемчә.

– Алай димә, әтисе, балаларда гаиләнең холкы чагыла.

Кичке аш арасында да сүз күбрәк Газинур турында барды. Бу минутларда Фәнәзия белән Камил тормыш әзерләгән «сюрприз»лар турында белмиләр иде әле.

Фәнәзия инде ярты сәгать элек рәхәт изрәп йоклап китте. Камил, хатынын уятмаска тырышып, зал ягына чыгып утырды. Тавышсыз гына телевизорны кабызып куйды. Ачык калган форточкадан якындагы шәһәр шау-шуы ишетелеп тора. Өй эченә тулган көз исе күңеленә рәхәтлек бирсә дә, Камилне моңсу уйларыннан арындыра алмады.

Җәүһәрия... Җәүһәрия... Ничә еллар җигелеп тарткан тормыш арбасының бер тәгәрмәче кыеш булган түгелме соң? Өйләнешкәннән бирле хатынына бер тапкыр да «яратам!» дип әйтә алмавы, Җәүһәриягә биргән



Рәсем: Наталья Васильева

антының тотып торуы түгел микән?! Югыйсә Фәнзиясе бик лаек бит ул сүзгә. Әтиләре көчләп диярлек таныштырсалар да, үзләре килешеп, ЗАГСка гариза илттеләр. Җәүһәрия, кырт өзеп, диплом алуга ук авылына кайтып китмәсә, Камил артыннан баргач, качып калмаса, соңыннан күрше республикага китеп эшкә урнашмаса, кем белә, бәлки, тормыш арбасы бөтенләй икенче юлдан тәгәрәр иде. Егыласымны алдан белсәм, салам җәеп куяр идем, дигән әйтем бар барын, әмма шул ук вакытта татарда «һәркемнең үз язмышы» дигәне дә бар...

Җәүһәрия Камилнең этиләре сүзеннән чыга алмасына, Камилнең үзеннән дә ныграк ышанган булган, күрәсең. Фәнзия турында иң беренче сүз чыкканнан соң, Җәүһәрия алыштырып куйгандай булды. Бигрәк тә май бәйрәмнәреннән соң, юк-бар сәбәп табып, Камилне тизрәк озату ягын гына карый башлады. «Нигә әйтергә кирәк булган инде миңа этиләр белән Фәнзияләргә кунакка барганны», – дип, үзен битәрләп тә йөрде Камил соңыннан. Иң гаҗәбе: ул Фәнзияне ошатты. Юк, чибәрлегенә ушы китмәде. Ул вакытта Җәүһәрия аның күзен томалаган, башкаларны күрү дәрәҗәсендә түгел иде Камил. Кечелеге, гадилеге, нәзакәтлелеге сокландырды. Яшь башлагач, башка гүзәл якларын да ачты хатынының. Тик ни өчендер «яратам» дип әйтергә теле әйләнмәде.

Җәүһәрия... Җәүһәрия... Тәннәребез дә җаннарыбыз кавышканга кушылды бит. Мин сине мәңге ташламаска ант иттем. «Җәүһәрия авырлы, без өйләнешәбез», – дип әйтергә икәүләп план кордык, син каршы килмәдең. Ә аннан соң икебез дә диплом яклау мәшәкатьләренә чумдык... һәм аерылдык.

Секретаре: «Камил Касыймович, Җәүһәрия Ризванова сезгә керергә тели», – дигәч, Камил, торып, ишеккә каршы атлаганын сизми дә калды. Оксана, аптырабрак, читкә тайпылды.

Ишекнең теге ягында таза гына гәүдәле, кара бөдрә чәчле хатыннан башка беркемне дә күрмәгәч:

– Җәүһәрия Ризванова үтсен, кая ул? – дип сорарга мәҗбүр булды.

Кабул итү бүлмәсендә басып торган хатын:

– Исәнмесез, Камил Касыймович, мин булам Җәүһәрия Ризванова, керергә рөхсәтме? – дип, Камилгә кулын сузды.

PRESSA.RU

Камил каршында басып торган хатынга, таныш чалымнар табарга тырышып, кулын суздa. Егерме өч ел үтсә дә, кеше бу кадәр үзгәрмәс, Җәүһәрия түгел бу хатын.

Алар кабинетка үттеләр.

– Аптырадыгыз, күреп торам, – дип сүз башлады Җәүһәрия.

– Әзрәк бар.

– Сез бит икенче Җәүһәрияне көттегез, беләм.

– ...

– Кызганычка каршы, аның мәрхүмә булганына унбиш ел.

– Ничек мәрхүмә?!

Ир-егетнең йөрәгендә җигүле атлар ятар ди. Район дәваханәсендә хәтсез еллар баш табиб булып эшләүче Җәүһәрия Ризванова моны бик яхшы аңлый иде. Шуңа күрә ул дилбегәне үз кулына алды.

– Камил Касыймович, сез белгән Җәүһәрия яман шеш авыруыннан китеп барды. Аякка баса алмавын аңлагач, миңа сезнең турыда сөйләде. «Берүк минем бу дөньяда юклыгымны белдермәгез. Бик кирәк чагында гына әйтерсез», – дип үтенде. Ходай шул сәгатьне Камилә эшкә урнашкан вакытка туры китергәндер инде.

Оксана чәй әзерләп кертте. Камилнең ут кебек кайнар йөрәген чәй генә басарлык түгел иде.

– Димәк, сез Камиләгә икенче әни булгансыз?

– Әйе. Исемнәребез туры килгәнгә генә түгел. Без аның белән районга эшкә бер елны кайттык. Ул – мәктәпкә, мин – дәваханәгә. Җәүһәрия, килеп ике атна эшләү белән, мәктәп директоры Наилгә кияүгә чыкты. «28 яшенә кадәр өйләнми, Җәүһәрияне көткән икән Наил», – диделәр алар турында. Бик матур итеп яшәп киттеләр, Камилә туды. Җәүһәрия кызын мин кизү торганда тапты. Ул вакытта мин әле балалар тудыру бүлегендә эшли идем. Хәзер мин шунда баш табиб. Наил РОНО җитәкче. Җәүһәриянең бәхиллеге белән өйләнештек. Тагын ике ул алып кайттык.

Җәүһәрия тынып калды. Аннан, монысын да әйтим инде дигәндәй, сүзен дәвам итте.

– Мактана дип уйлый күрмәгез. Камиләнең тылы ныклыгын гына күрсәтәсем килә. Берүк әллә ни уйлый күрмәгез. Сездән берни дә таләп итмибез. Монда таныш-белешләребез юк дәрәҗәсендә, шуңа эшкә урнаштыру мәсьәләсе килеп чыккач мөрәҗәгать итәргә уйладык. Рәхмәт яусын, булдыргансыз. Укып бетергәч, үзебезнең республикага кайтырга теләмәде шул Камилә, эш сөйләшенгән иде югыйсә. Әнисенең кендек каны тамган җир тартадыр инде балакайны. Әбиләренә дә моннан кайтып йөрү якынрак.

– Камилә әнисен хәтерлиме?

– Беренче класста укый иде, хәтерли.

– Ә әтисенең мин икәнен беләме?

Җәүһәрия бу сорауны Камилдән көтмәгән иде. Киресенчә, сорауны Камилгә үзе бирергә әзерләнеп килгән иде ул. Кем кызы соң ул Камилә?

...Җәүһәрия Ризванова килеп киткәч, Камил өч көнлек командировкага китте. Әйләнеп кайткан кичне, эш сәгате тәмамлануга бер сәгатьләп вакыт узуга карамастан, вокзалдан туры оешмага китте. Камиләгә дип алып кайткан бүләген анда калдырып чыгу иде исәбе.

Камиләнең кызы икәненә өмете сүнмәгән иде әле аның. Беренчедән, Җәүһәрия, врач буларак, хатын-кыз баланы йөкләлек срогы беткәнче табарга да, срогыннан артык йөрергә дә мөмкин дип аңлатты. Икенчедән, Камилә белән нindидер хәл ителә алмаган мәсьәлә килеп чыкса, Җәүһәриянең Камилне эзләп табарга кушып калдыруы тикмәгә генә түгел.

Камил икенче каттагы бүлмәсенә күтәрелде. Хокук бүлегенең ачык ишегеннән кемнеңдер моңлы итеп җырлаган тавышын ишеткәч, туктап калды.

Сандугачлар су эчәләр
Агыйделгә тезелеп.
Нигә болай сагынам икән,
Үзәкләрем өзелеп?!

Кабинетка үтәргәме, әллә «сандугач»ны өркетмәскәме? Эштән соң калып моңланып утырырлык булгач, юкка гына түгелдер. Иртәгә бүлек башлыгы Ирек Газиз улы белән сөйләшеп алырга кирәк булыр, дип уйлаган арада, җыр да тукталды. Камил, саклык белән – тавыш чыгармаска тырышып, кабинетының ачкычларын тартып чыгарды.

– Хәерле кич, Камил Касыймович!

Камиләнең зәңгәр күзләре Камилгә тутырып карап тора иде.

– Хәерле кич, Камилә! Бик матур җырлыйсыз икән, махсус белем алганнардан да уздырасыз.

Төбәп әйтелгән бу сүздән Камилә кызарып куйса да, аңа күңелле икәне йөзенә чыккан иде.

– Рәхмәт, Камил Касыймович! Исән-сау йөреп кайтуыгыз белән!

Кабинетка чакырсам, сөйләшеп утырырга иң кулай вакыт, бүләкне дә тапшырырмын дип уйлады Камил.

– Камилә, кайтырга ашыкмасагыз, минем кабинетка керегез әле.

Камилә бит очларын чокырайтып елмаеп куйды. Шушы чакыруны көтеп кенә торган диярсең!

Оксана булмагач, секретарь вазыйфасын үзенә үтәргә калды Камилгә. Ял итү бүлмәсендәге кәнәфидән Камиләгә урын күрсәткәч, чәйнекне кабызып җибәрде. Өстәлгә затлы конфетлар, печенье, җимешләр куелды.

– Йә, Камилә, хәлләр ничек, эшкә күнегәсезме?

– Әкренләп инде. Өйрәтүчеләрем яхшы, тырышам...

Камил Камиләгә туры карамаска тырышты. Гел Җәүһәрия бит. Хәтта тавышлары да охшаган. Үз-үзеннән куркып та куйды, ялгышып кочаклап алмасын тагын. Тик менә бер ягы гына әнисенеке түгел: Җәүһәрия дә, Камил дә җырлый белмиләр иде. Нишләтәсең, Ходай бар кешене дә җырчы итеп яратмый. Ә менә Камиләгә каян килгән шулкадәр моң? Камил үзләренең туган-тумачалары арасында да

оста итеп җырлаган кешене белми. Бәлки, Җәүһәрия яклаптыр?

– Бүген моңланып утырасыз, берәр сәбәбе бармы?

Камилә тагын елмайды.

– Камил Касыймович, сәбәбе – бары минем җырларга яратуымда гына. Үземне белә башлаганнан бирле җырлыйм мин. Әтиемнән күчкәндер ул моң миңа. Белсәгез иде сез аның үзәкләрне өзәрлек моңлы тавыш белән ничек итеп җырлаганын!

Камилнең йөрәген нәрсәдер көйдереп алды. «Юк, бу гына әле Наил кызы булганын расламый, әллә ниләр уйлама», – дип, үзен тынычландырырга тырышты. Камиләне үзенең кызы итәсе килә иде аның. Ничә еллар көттеләр бит алар кыз бала. Тик уллары Газинурдан соң Фәнәзия бер тапкыр да авырга узмады. Кыз бала наздан туа диләр бит, әллә шул наз дигәннәре җитеп бетмәдеме икән?

Камил, уйларына бирелеп, Камиләнең янында утырганын да онытып җибәрә язды.

– Камил Касыймович!

– Тыңлыйм, Камилә!

– Сез миңа бик нык ошыйсыз, мин сезгә үлеп гашыйк!

Камил корт чаккан кебек сикереп торды.

– Камилә, сез… син…

Камил, беренче тапкыр кыз белән күрешкән егет сыман каушап, ни әйтергә белми аптырап калды. Ә мин аны юаш кына бала дип торам, карале, моның бөтен көче йөрәгендә икән!

– Камил Касыймович, мин тилене ачуланмагыз инде. 22 яшькә җитеп беркемне дә ошатканым булмады, егетем дә булмады минем. Ә сезне беренче күрүдә үк яраттым. Бүген сезнең эшкә киләчәгегезне сизеп килдем бит. Махсус сезне күрер өчен.

– Камилә, тынычлан. Мине яратырга рөхсәт бирәм. Тик башкача, әтиеңне яраткан кебек.

– Камил Касыймович, мин бакчага йөри торган бала түгел бит. Үз әтием дә бар яратырга. Ике әтинең миңа кирәге юк.

Хокук бүлеген юкка бетермәгән, оста сөйли. Ачарга кирәк дөреслекне, юкса бу бала кабинетка чакырып кертүемне дөрес аңламас.

– Камилә, эшләр болайга киткәч, әйтмичә булмый. Чөнки ялгыш адымны вакытында туктата белү мөһим, – дип башлады ул сүзен.

Камилә, ни сөйләсәгез дә мин сезне ятатудан туктамыйм дигән кыяфәт чыгарып, Камилнең күзләренә текәлде.

– Камилә, син – минем кызым.

– Камил Касыймович, миннән котылу өчен уйлап таптыгызмы моны?

– Мин – синең үз әниең Җәүһәриянең яшь чагында ярату, кавыша алмаган кешесе. Алай гына да түгел, ул, син «әти» дип йөргән Наилгә, миннән авырлы калып, кияүгә чыккан. Мин аның йөкле икәнен белмәдем… Син боларны белгәч, мине күрәлмас дәрәҗәгә җитәрсең, бәлки. Ләкин мин яшермим, дөресен сөйлим.

Камилә шул арада кәнәфидән кул арасы гына яткан сумкасын үрелеп алды да, эченнән бер конверт тартып чыгарып, Камилгә сузды. Конверт таушала төшкән. Бу заман конверты түгел иде инде бу конверт.

– Ачыгыз, эчендәге хатны укыгыз. Кычкырып укыгыз.

Камил, карышып торуның файдасыз икәнен аңлап, Камиләгә буйсынды.

«Кызым, бердәнберем Камиләм! Сиңа бу хатны әтиең кулыңа өлгергәнлек аттестаты алгач кына бирер. Шулай сөйләштек аның белән. Бөтен теләгем – синең бәхетле, озын гомерле булуың. Җиде айлык булып кына тусаң да (ике кило йөз грамм иде авырлыгың), олылар әйтмешли, Ходайга шөкер, бик тере бала булып үстең. Инде быел беренче класста укыйсың. Физкультура – иң яраткан дәресең. Беркөнне: «Әни, үскәч, мин физкультура укытучысы булам», – дип сереңне дә ачтың. Шуны әйтәсем килә: мин каршы түгел, һөнәр сайлау үз иркеңдә булыр. Тик шулай да минем сине хокук белгече итеп күрәсем килә…»

– Ярый, шунда туктагыз, башкасы кирәкми, авыр миңа тыңларга. Үзем генә аулакта укырга яратам мин әниемнең хатын.

Камил тагын буйсынды. Хәтта бу юлы аңа Җәүһәрия эндәшкән кебек тоелды.

– Мин җиде айдан тугач, әтигә дә сүзләр җиткергәләгәннәр. Тик ул әнигә ышанган, аны җәберләмәгән. Хәтта генетик экспертиза ясарга да уйламаган. Беренче курсны бетергәч, үзем көчләп диярлек күндердем. Ризванов Наил кызы икәнлегемне раслаган документларым бар. Тик бу турыда икебез генә беләбез әти белән. Ул: «Әниеңә ышанмаган кебек булып чыга бит, беркемгә дә әйтмә бу турыда», – дип кисәтеп куйды мине. Әтинең икенче хатыны Җәүһәрия Ризванова да белми хәтта экспертиза ясатып йөрүебез турында. Хәер, ул экспертизасыз да минем кем кызы икәнемне беләдер. Алар әни белән ахирәтләр булган. Әниемнең әллә күпме сере аңарда саклана, миңа да сөйләп бетергәне юк әле.

И кешем! Бу дөньяга аваз салган беренче минутларыннан ук Язмыш Сине үзенең кочагына бөтереп алып кереп китә дә, теләгәнчә елатып, теләгәнчә җырлатып, теләгәнчә кыйнатып яши дә яши. Әгәр дә Син аның теләгәненә каршы киләсең икән, ул тагын да сынауларын өстәп бирә. Ул язган юлдан гына барам дисәң дә, сукмакларың чуалмас димә: адашыр өчен әллә ни күп кирәкми. Кайберәүләр, Язмышка бирешергә теләмичә, гомер буе көрәшәләр, үз дигәннәрен үз итеп, алга баралар. Ә бит ихтыяр көче дигәне дә бөтен кешедә дә бертөрле түгел. Давыллар бөгеп салганда, яңадан күтәрелеп китүчеләр белән бер рәттән, әкрен генә искән җилгә дә түзә алмый егылып калучылар аз түгел.

Фәнәзия кулындагы язу кисәген кая куярга белми иза чикте. Ертып ыргытырга да онытыргамы? Тормышларыннан көнләшеп, юри араларын бозар өчен генә дә язган булулары бик мөмкин бит. «Ирегездән колак кагасыгыз килмәсә, япь-яшь сөяркәсеннән тизрәк

PRESSA.RU

аерып алу чарасын күрегез. Изгелек теләүче.» дигән сүзләр, болай да соңгы вакытта Камиленең эшендә күбрәк тоткарлануына ризасызлыгы арткан шикле күңелгә өстәмә азык булып кереп утырырга күп сорамый иде. Әллә Камилнең үзенә укытыргамы? Гомер буе иренә ышанып яшәгән Фәнәзиянең җанын моңа кадәр аңа билгеле булмаган ямьсез хисләр капшый башлады. Ичмасам, бер туганы да юк сер ачарлык. «Дусыңның да дусты булыр, ул да сөйләр дустына» дигән киңәшне гомер буе юлдаш итеп яшәгән Фәнәзия, күз яшьләрен сөртә-сөртә, телефоннан Камилнең номерын җыярга кереште. «Абонент недоступен...» дигән җавап кына ишетелде.

Камил кайтып кергәндә, Фәнәзия нервларны тынычландыра торган дару кабып, диванда ятып тора иде.

Көндәгечә каршына килеп: «Әтисе, кайттыңмы?» – дип хәл сорашучы булмагач, Камил беренче булып үзе эндәште.

– Әнисе, нихәл?

– Башыма чыдый алмыйм, кан басымы күтәрелгән бугай, хәлем юк.

Камил тиз генә залга үтте. Төсе качкан Фәнәзияне күргәч: «Әнисе, хәзер «ашыгыч ярдәм» машинасы чакыртам», – дип сүз башлаган иде дә, хатыны аның кулына уртага бөкләнгән кәгазь кисәге тоттырды. Арада тынлык урнашты. Тек-тек-тек. Тек-тек-тек. Сәгать телләре нигә шулкадәр тавышланып йөри икән? Ичмасам, тышта буран да уйнамый, ул вакытта сәгать телләренең текелдәве дә ул кадәр ишетелмәс иде. Тек-тек-тек... Тек-тек-тек...

Камил акланып та маташмады, кире дә какмады. Әлеге минутта аңа Фәнәзиянең сәламәтлегеннән дә кыйммәт нәрсә юк иде: ул телефоннан «ашыгыч ярдәм»не җыярга кереште.

...Камилә эш сәгате беткәч, универмагка илтеп куярга такси чакыртты. Камил Касыймович белән шунда очрашырга сөйләштеләр. Исәпләре: чәшке тун сайлау. Камилә башта карышып та карады. Беренчедән, Камил Касыймовичтан шундый кыйммәтле бүләк алырга кыенсынса; икенчедән, ул бит, гомумән, тун сайлый белми. Аңа нindирәк фасондагы тун килешер? Бәлки, бөтенләй дә килешмидер әле?! Тик Камил Касыймович өзми дә куймый: «Алабыз дигәч, алабыз!» Бер ай инде Камилә үзен төш эчендә йөргән кебек хис итә.

Киноларда яки китапларда гына була торган хәлләрнең нәкъ аңа да килеп кагыласын башына да китерми иде. Аңа ярты ел элек: «Камил Касыймович дигән кеше синең әтиең дип әйтсәләр, сумкасыннан язуын алыр да борын төпләрендә селкеп: «Минем әтием Наил Ризванов!» – дип әйтер иде. Ә бүген алай дия алмый, чөнки Камил Касыймович, экспертиза үткәреп, Камилә аның кызы икәнен исбатлады. Алай гына да түгел, Камиләнең әти-әнисе белән дә аңлашып килделәр. Олы йөрәкле кеше булганын тагын бер тапкыр исбатлады әтисе Наил. Әнисе исеменнән хат язучы да, белешмәне дә ничек кирәк шундый итеп эшләткән кеше дә ул булып чыкты. Чөнки район җирендә кешеләр бер-берсен бик яхшы белә. Камиләгә бер генә «яхшылык теләүче» килеп чыкса да, эшнең ни белән тәмамланасын чамалаган әтисе Наил.

Камил Касыймовичка «әти» дип әндәшкәне юк әле Камиләнең. Аның әтисе берәү генә, шулай булып калыр да. Камил Касыймович үзе дә кыстамый. Әмма шулай да күп вакытын бүлә ул Камиләгә. Эштән соң еш кына җәяүләп Камиләне фатирына озатып куя. Нәрсә турында гына сөйләшмиләр алар! Камилә әнисе турында әллә күпме яңалык белде, шәһәрнең алар яратып йөргән урыннарын ничә тапкыр урадылар. Камиләнең ризалыгы белән икенче оешмага эшкә дә урнаштырды Камил Касыймович аны. Гаиләсе белән таныштырырга да сүз биргән иде, җае гына чыкмый бугай әле.

Камилә универмагка килеп җиткәндә Камил Касыймович урта яшьләрдәге бер хатын-кыз белән ишек төбендә басып тора иде. Камилә хатын-кызның Камил Касыймовичның хатыны Фәнәзия икәнен чамалады. Һәм ялгышмады. Фәнәзиянең үзенә төбәлгән ягымлы елмаюлы карашын күргәч, каушавы басылгандай булды. Бер-берсен сәламләгәч, Камил Касыймович аларны якыннан таныштырды.

– Тун сайлаганда Фәнәзия апаңнан да остарак кеше табып булмас, дип уйладым. Һәм, гомумән, Камилә, ул синең иң якын кешеләреңнең берсе булып китәр, шулаймы, әнисе?

– Шулай, әтисе! Син ышыклап барганда, арага җил дә кермәс!

Камил, яратып, Фәнәзиянең күзләренә бакты...

ТАТАР ТЕЛЕНДӘ ЭЛЕКТРОН КИТАПЛАР – БУШЛАЙ!

Татарстан китап нәшрияты Татарстан хөкүмәте белән Матбугат һәм массакүләм коммуникацияләр буенча республика агентлыгы ярдәмендә «Татар әдәбияты үзәге» www.tatkniga.ru проектын эшләтеп җибәрде.

Татар әдәбиятының бай мирасы белән хәзер дөньяның теләсә кайсы почмагында танышырга мөмкин. Электрон китапханәдә китапларны бушлай укырга, китапларның басма вариантына заказ бирергә була. Портал көн саен тулыландырыла.

Бүгенгә «Татар әдәбияты үзәге»ндә ике меңләп китап тупланган. Биредә тарихи, фәнни әдәбият, балалар китаплары, матур әдәбият, белешмәлекләр, дәреслекләр бар.

Китап уку гына түгел, сайтның һәрбер кулланучысы аның эшчәнлегенә үз өлешен кертә ала. Моның өчен Татар әдәбияты үзәге яки нәшрият эшчәнлегенә кагылышлы тәкъдим-сорауларыгызны tki@tatkniga.ru адресына юлларга кирәк. Хатлар нәшриятның генераль директоры Илдар Сәгъдәтшин кулына килеп керәчәк.

РЕКЛАМА ХОКУКЫНДА

БЕРЕНЧЕ УКЫТУЧЫБЫЗНЫҢ ИСЕМЕ, ОБРАЗЫ ГЕЛ КҮҢЕЛДӘ. ХӘТТА КИЛӘЧӘК ЯЗМЫШЫБЫЗНЫҢ, САЙЛЫЙСЫ ҺӨНӘРЕБЕЗНЕҢ НИНДИ БУЛУЫНДА ДА УКЫТУЧЫНЫҢ ЙОГЫНТЫСЫ БАР. БЕР СҮЗЕ, БЕР ГАМӘЛЕ БЕЛӘН ИҢНӘРГӘ КАНАТЛАР ДА КУЯ, ХЫЯЛЛАРНЫ ДА ЧӘЛПӘРӘМӘ КИТЕРӘ АЛА УЛ.

Әнисә ВӘЛИЕВА

БЕТЛЕ КҮРКӘ

Сентябрь ахырында телевидениедән 8 яшьлек малайның маңгаена «дурак» дип язган укытучы турында сюжет күрсәттеләр. Дистә елдан артык мәктәптә рус теленнән белем биргән укытучы бу гамәле өчен бик үкенгән, үзен гаепле санавын сөйли. Баладан да, аның әти-әнисеннән дә гафу үтенә. Статья белән эшеннән дә куганнар икән үзен. Әти-әниләр, аны яклап, мәктәп ишегалдына җыелганнар. Берзаман бу гауга онытылыр анысы. Әмма... дуслары алдында хурлыкка калган малай гына онытырмы аны? Классташлары алдында бер төшкән абруен ничек кире кайтарыр? Киләчәк язмышында, үз-үзенә куйган бәясендә чагылыш тапмасмы шушы вакыйга?

Хәтерләмим, әллә беренче, әллә икенче класста укыган чагым иде. Яңа ел бәйрәменә әзерләнгәндә укытучы апа бөтенебезнең чәчен бер тарак белән тарап үрде. Икеме, өчме атнадан, мәктәпкә табиблар килеп, балаларның башларын тикшерде. Мин ул көнне мәктәпкә бармый калган идем. Икенче көнне башымны укытучы апабыз үзе карады. Ник шул вакытта үз-үзен тыеп кала алмады ул? Аның бөтен класс алдында: «Бетле күркә! Башың тулы бет бит!» – дигән ике җөмләсе абруема һич юып алып булмаслык бер тап булып ятты. Соңыннан ничә еллар буе, берәрсе белән сүзгә килсәкме, фикеремне үткәрмәкче булсаммы, «бетле башың белән тик кенә тор әле!» дип, тиз «авызлыклыйлар» иде. Югыйсә ул вакытта башка классташларымда да табылган булган ул. Табиблар бу хакта баланың әнисенә генә әйткәннәр, беркемне дә бөтен класс алдында фаш итмәгәннәр, абруен төшермәгәннәр.



Әни ул кичне, ачулана-ачулана, пәке белән чәчемне кырды. Билгә кадәр төшеп торган озын куе чәчләрем тотам-тотам булып идәнгә сибелгәндә, әнигә күрсәтми генә елаганымны хәтерлим. «Чәч үсә ул!» – әнинең сүзен күңелемнән кабатлап, үз-үземне шулай юаткан булдым. Әмма: «Иртәгә мәктәпкә ничек итеп барырмын, классташларга ничек күренермен?» – дип, төне буе борчылып чыкканымны хәтерлим. Борчылуым юкка түгел – бу яшьтә балалар миһербансыз була. Үзләреннән бераз аерылып торганнарны өерләре белән чукырга әзерләр.

Класс ишеген курка-курка гына ачып керүгә, дәррәү көлү, хихылдау, үртәү яңгырады. Мин моны көткән, аңа әзер идем. Тәнәфестә классташ малайларның яңа уены барлыкка килде: башыма бәйләгән яулыкны йолкып алалар да, бер-берсенә ата-ата, коридор буйлап чабышалар. Мин, тилмереп, елый-елый артларыннан куам. «Чебурашка!» «Әрекмән колак!» «Кояш чыкты!» «Бетле күркә!» – нинди генә сүзләр ишетмим... Бөтенебезне парлап утыртканда, минем янга утырмас өчен җан тартыш: «Бетле бит ул. Йә бете күчәр тагын!» – диешәләр.

Соңрак, инде югары сыйныфларда укыганда да шушы хәлне искә алып, алар үртәгән, мин үртәлгән чаклар аз булмады. Балаларны гаепләмим мин моның өчен. Төп гаеп олыларда – баланың сәламәтлеге белән бәйле проблеманы фаш иткән укытучыда һәм кызын көлкегә калдырасын уйламыйча, башка чарасы юкмы дип эзләмичә, ашыгып гамәл кылган әнидә. Моның бала психикасына никадәр зыян китерүен чамалар өчен психолог булырга кирәкми.

Хәзер инде мин бу хәлләрне бер мәзәк итеп кенә искә алгалыйм. Классташларымны да, укытучы апабызны да күптән кичердем. Хәер, минем ныгып бетмәгән психикама ниндидер зыян китерүен үзе абайламады да бугай ул. Әмма бүгенге тормыш тәҗрибәмнән чыгып, аның дөрес эшләмәвен, класс алдында мине хурлавы, сәламәтлегем белән бәйле серне башкаларга фаш итүе җинаять булуын аңлыйм. Укытучы этикасы җитеп бетмәгән инде аңа...

PRESSA.RU





Эльмира ЗАКИРОВА

ЧИШМӘ ҖЫРЫ

Күзгә матур көн иде. Бишенче класста укып йөргән чаклар. Безне мәктәп ишегалдында линейкага тезделәр. Мәктәп директоры Басыйров абый килгән кунак белән таныштыра: «Укучылар, менә бүген бездә кунакта Казан дәүләт университеты укытучысы, шагыйрь Мостафа Ногман», – ди. Зур гәүдәле, беретыннан бөдрә чәчләре ташып тора, иңенә сумка аскан, күзләре очкынланып яна… Безнең каршыга әнә шундый абый чыгып басты. Университетның татар теле һәм әдәбияты бүлеге, үзенең шунда борынгы татар язуыннан, фарсы теленнән дәресләр алып баруы турында сөйләгәннәре истә калган… Аларның студентларын Актанышка бәрәңге алырга җибәргәннәр, Мостафа абый җитәкчеләре булып килгән икән.

– Сезнең Актаныш бик матур! Актаныш басмаларыннан гына Агыйделгә төшәсең… Казанга, Уфага китүче пароходларны яшьләр гармуннар белән җырлап озата… Илһамланып, шушы көннәрдә генә Сара Садыйкова белән «Актаныш таңнары» дигән җыр яздык, – дип, ул безгә җырлап та күрсәтте. (Уныннчыдан соң шул университетка укырга керермен, Мостафа Ногман фарсы теле укытучым булыр дип кем уйлаган ул чакларда?!)

Ә июнь аенда Мостафа Ногман белән Сара Садыйкова безнең Байсарга, авылдашыбыз – данлы комиссар Шәйгәрдән Шәймәрданов турында җыр язарга дип махсус килделәр. Укытучы әтием шул очрашуны оештыру, аларны озатып йөрү өчен җаваплы иде. Әти кушуы буенча болыннардан, Сөн буйларыннан ак, зәңгәр чәчәкләр җыеп кайттык, сәламләү сүзләре әзерләдек.

Икенче көнне иртүк әти Аккүзгә бару хәстәрен күреп йөри башлады. Мостафа абый белән Сара апаның шунда бик барасылары килгән икән.

Оныталмасам, нишләрмен?

Сөн буйлары бөдрә урман,
Агыйделләргә җиткән.
Сөн буенда Чишмә авылын
Ник барып күрдем икән?!

Кушымта:
Бер гүзәлен сагынам Чишмәнең,
Оныталмасам аны, нишләрмен?

Нигә туып үсмәгәнмен
Шул Чишмә якларында?!
Елмаюын күрер идем
Очрашкан чакларымда.

Кушымта:

Сагынуларны баса алмас
Ялкынлы хатлар гына.
Бәлки юллар илтер әле
Мәхәббәт хакларына?

Кушымта:

«Чишмә» колхозы рәисе Ясәви Хөсәенов чакырган диме соң шунда… Әти Казан кунаклары турында аерым бер ярату белән, көлә-көлә сөйли әнигә: «Авылча бик простойлар, мәзәк сүзләре белән көлдерәләр, бала-чага кебек беркатлы үзләре… Әрем исләренә исләре китеп, колын күрсәләр дә сөенеп йөриләр. Бигрәк тә тарантаска утырып бару ошады инде аларга!» – ди.

Дистә еллар узгач, Мөхәммәт абый Мәһдиев студентларны пароходта Актанышка фольклор экспедициясенә алып китә. Шул ук авыллар, Сөн-Агыйделләр… Соңрак ул юлъязмалар «Актаныш басмалары» исеме белән язучының «Ачы тәҗрибә» китабында да басылып чыга. Анда кызыклы истәлекләр байтак. Ә менә монысы, әлеге җыр турындагысы, балачакта өзелеп калган хатирәләремне ялгап җибәрде. Әйтерсең, мин әллә кайчан күргән фильмның дәвамын карыйм.

«…Менә бер хәбәр таралды: имеш, Актаныш районы Байсар авылына, аның турында махсус җыр язарга, Сара апа белән Мостафа Ногман киткәннәр. Байсар – Татарстанның иң матур табигатьле куенына – Сөн буена иңеп утыра. Сөн буе, Ык буе авылларында кызлар бик гүзәл. Минзәлә белән Актаныш тирәсендә инде ул татар кызларының иң гүзәл генофонды. Әйе, монда бик шәп җыр тексты туарга мөмкин, хатын-кызга гүзәллек ягыннан бер карау белән бәя бирүдә алыштыргысыз Мостафа монда үз гомерендәге иң яхшы җырны язып ташлавы мөмкин.

Сара апа мәшһүр «Җидегән чишмә» көен Аккүз авылында тудырды. Менә әле Байсарга тагын композитор белән шагыйрь килгән…

Ну бу Сара ападагы җиңеллек инде! Нинди авыр гәүдәле Мостафаны каз мамыгы урынына очыртып кына йөртә. Үзе гел аны сүгә: «Җүнле сүзләреңне башка композиторларга биреп бетергәнсең син! Миңа җүнсезе генә калган!»

Шулай, килгәннәр, ди, болар Байсарга, җыр язарга дип йөриләр, ди. Бу хәбәр Байсардан ерак түгел генә урнашкан Аккүз авылына да килеп җиткән. «Чишмә»нең рәисе Ясәви Хөсәенов – әдәбият-сәнгать кешесе, моңа зур игътибар биргән. Туктале, дигән бу, нигә әле Байсарда җыр туып ятканда, бездә тумаска тиеш? Без кемнән ким? Һәм ул «хитрый ход» ясый. Әгәр дә ул, үзе барып, «әйдәгез, безгә дә җыр языгыз» дисә, Байсардагы колхозның яшь рәисе алдында дәрәҗәсе төшәр иде. Фронтовик Ясәви исә башта «разведка с боем» ясый. Канатлы тарантаска шлеялы, шөлдерле ат җиктерә, тарантас башына түбәтәй кидереп, бер малай утыртта да Байсарга җибәрә… Мин күз алдына китерәм инде, хисләр колы Сара апа белән хисләр вулканы Мостафа агайның бу хикмәтне күргәч нинди халәткә килгәннәрен.

– Мостафа, Мостафа! – дип өтәләнгәндер Сара апа. – Җыен тизрәк, киттек Аккүзгә! (Мостафа агайны ул, кызып китеп, әллә нинди сүзләр белән сүгеп ташлый иде) тиз бул, нәрсә карт алаша кебек торасың…

Тегесе – зур басым астында баллонга кысып тутырылгач сыек хәлгә килгән газ кебек: башта тыныч, әмма инде клапанын бер ачсаң… чыда гына. Тарантас башына Мостафа үзе утыра. Мондагы балык күлләрен, Сөн буендагы сандугачлы куакларны күреп, Сөн аръягындагы кымыз йортында булып, ялларын болыт итеп уйнатып урманнан чабып кайткан савым бияләр табунын күреп, тегеләр композитор һәм шагыйрьләрдә генә була торган икенче дөньяга күчәләр.

Әле тагын шунысы бар: сөйләүләренә караганда, узган көздә генә университет студентлары «Чишмә» колхозында ындыр табагында эшләгәннәр икән дә, шунда кафедрадан җитәкче булып Мостафа Ногман килгән, һәм күп тә үтми Аккүз авылындагы бер кызгамыханымгамы гашыйк булып ялкынлы утлар эчендә калган, ди.

Инде, сандугачлы җәйдә шөлдерле атлар белән Аккүз авылына килеп төшкәч, Ясәви белән балыклы күлләр, кымызлы тау итәкләрендә йөргәч… Күлләрнең берсендә пар аккошлар күргәч… Ничек итеп тумый калсын ул җыр?.. Инде Сара апа да иләсләнеп беткән, Мостафадан текст көтә. Көтә, дулый, малайлар урынына сүгә тегене, әллә ниләр әйтеп бетерә. Һәм… июнь иртәләренең берсендә, Сөн аръягындагы кымыз бияләрен урманга чыгарганда, күл өстендә балыклар чупылдаганда, күршедәге Меңнәр авылы зәңгәр рәшә белән капланганда җырның сүзләре туа…

Сара апага текст ошаган, күрәсең; сөйләүләренә караганда, көй шунда ук Аккүздә туган. Бу җырны сәнгатебезнең энҗе-җәүһәрләреннән бер кисәк дип ничек сокланмыйсың?..»

Фото: 436 нчы группа студентлары Мостафа Ногман белән. Шагыйрьнең сул ягында – автор Эльмира (Мәҗитова) Закирова. Мостафа Ногманның Рөстәм Яхин белән язган «Киек казлар китә» җырын беренче тапкыр тыңлаганнан соң, шул вакыйганы тарихка кертеп калдыру мизгелләре. 1974 ел, 29 май.



Тулысынча сайтыбызда укыгыз.

PRESSA.RU



СИН ЯШӘСӘҢ, БЕЗ ЯШӘРБЕЗ



Лилия ГӘРӘЕВА

«ФӘРИДӘ-ӘҮ! ДӨГЕ ГЕНӘ БИРЕП ТОРЧЫ?»«ФӘРИДӘКӘЕМ, КАЗАНГА БАРАСЫ ИДЕК, СЫЕРНЫ ГЫНА САУМАССЫҢМЫ?» КҮРШЕ-ТИРӘ АНЫ «АШЫГЫЧ ЯРДӘМ», «911» ДИП АТЫЙ. СОҢГЫ ӘЙБЕРСЕН БИРЕР, КЕШЕНЕ БУШ КУЛ БЕЛӘН ЧЫГАРМАС.

Дүрт малай да бер кыз үсте алар. Фәридәләренң өлкәне – әти-әнисенең таянычы булды. Әтиләрен инсульт аяктан екканда төпчек энеләре нибары өч кенә айлык иде әле. Әтисенең, чарасызлыгыннан оялып, урын өстендә ятканын хәтерли ул. Җиде ел бакты аны әниләре Зәмзәмия, кашыктан ашатты, йомышын йомышлатты, аркасына асып, мунчага алып барды... Шул ятудан торалмады инде ул, энеләре укырга кергән елны мәңгегә дип хушлаштылар әтиләре белән. Әнисе кичергәнне язмыш үзенә дә әзерләп куяр дип, ул вакытта Фәридә каян белсен?!

Булдырасың, кызым!

...Елтыр бизәкле шул өрфия яулык әле дә төшләренә керә аның. Җил әллә каян очыртып алып килә дә, үртәгәндәй, каршысында бөтереп, күзләрен камаштыра. Инде тотам дигәндә генә тагын очыртып алып китә. Күз алдында алсу-кызыл нурлар булып җемелдәгән чәчәкләре генә балкып кала. Аһ ул өрфия яулык! Әнисенә ничек килешер иде. Шуны бәйләп, авыл урамнарыннан бер узсамы! Сатмады бит шуны кибетче Фәридәгә. «Анаңа түгел, аннан болайракларга да җитми әле! Йөрмә эч пошырып!» Эт баласын куган шикелле, кибеттән куып чыгарганына әй гарьләнгәне Фәридәнең!

Юл буе елый-елый теләк теләп кайтты: «Йа Раббым! Үскәч, мин бөтен эшне эшли алсам иде дә бөтен кеше миннән ярдәм сорап килсә иде. Мин бер кешене дә кире бормас идем, соңгы әйберемне дә бирер идем!»

Әйбәт укыды Фәридә, тырыш иде. Шәфкать туташы буласы килде, хыялында үзен гел ак халаттан күрә иде. Юк инде, гомер буена юлдашы булачак кыюлыгы бу юлы хыянәт итте аңа. Аннан... ул китсә, әнисе нишләр?

Унынчыны тәмамлауга, колхозга ашчы итеп чакырдылар. Курыкмады, риза булды бит. Үзе кадәр тәпәннәрне күтәрәсе булу да, 300 кешегә өч тапкыр ашарга әзерләү дә өркетмәде. Бер әрчегәндә генә дә өч капчык бәрәңге әрчеп, йөз тавык йолкыйлар иде. Эшен яратты Фәридә. Гомумән, пешерергә бик ярата ул.

Хәтерле әле, алты яшьләр булгандыр үзенә. Әнисенең эшкә киткәнен көтеп кенә торды да кыстыбый пешерергә булды. Табакка бер чүмеч чишмә суы, бер аш кашыгы тоз салды. Әнисенең иләп куйган бер чиләк оны бар иде, ул да кереп бетте. Җәймәләрен бармак калынлыгы итеп җәйде, бер чиләк бәрәңге пешереп төйде. Туң майны эретеп, мул итеп майлады да, әнисе эштән кайтышка биш җиргә түбәләмә итеп өеп куйды. Мактаган да иде соң әнисе. Туң май ябышып каткан телен чак-чак кына әйләндерсә дә: «Булдыргансың, кызым, гаҗәп тәмле булган бит бу!» – дип үсендергән иде. Әнә шул көнне үк чыныгып калгандыр аның рухы. Булдыра икән лә бит ул! Нәрсәгә тотынса, шуны эшли ала икән!

Сәгадәтле көннәр

Сәгадәт!.. Чубар Абдулның иң чибәр егете иде ул. Бөрлегәндәй күзләргә гашыйк булмый кара син! Хәзер көлә Фәридә апа (миңа апа ул, кемгәдер яшьтәш, кемгәдер сеңелдер), Сәгадәттән элек миңа кайнанам гашыйк булды ди. Белгән әни кеше улының кемгә өйләнсә отасын. Сигез ел колхозчыларга ашарга пешергәндә дә, кибеттә эшләгән вакытларында да ни сынады бит ул бу сөйкемле кызны. Аның чыңлатып көлүләрен, чәч бөдрәләрен иңнәрендә тибрәлдереп, җил-җил генә атлап килүләренә кадәр яратты.

Әй, ул бәхетле көннәр! Ник аның гомере шулай кыска икән?! Бәхет нурында коенып, нибары алты ай гына яшәп кала алар. Аннары... Ни булганын да белмиләр, ничек дәвалыйсын да – яшь-яшь ир урынга егыла. Шул вакытта ук инсульт кичерүен ачыклап, тиешле дәвасын бирсәләр соң. Алай да кабат аягына баса әле Сәгадәте. Уллары Илназ туа. Чир чигенгән кебек була. Озакка түгел, алты елга гына.

«Ирем белән Сарман районының Җәлил бистәсендә яши идек, – дип искә ала тормышының ул кара көннәрен Фәридә апа Шәйдуллина. – Сәгадәт картлар йортында шофер булып эшләде. Иртән мин эшкә чыгып китәм, ул ятып кала. Ялкаулана, эшлисе килми, дип уйлыйм. «Алайса, аерылышабыз. Ялкауларны җенем сөйми», – дигәч кенә әйтте хәленең начар булуын. Шулкадәр ачуландым. «Ник аны әйтмисең, эшкә бармаган өчен прогул язалар бит». ВТЭК комиссиясенең кайсы көнне җыелганын белдем дә чыгып киттем. Сәгадәт ятып калды. Аллаһыма мең-мең рәхмәтле (Фәридә ападан бу сүз бер генә ишетелмәс әле – *Л. Г.*), табиблар янына кергәч, телемә иң кирәкле сүзләрне әйттерде. «Ирең кайда соң, ник килмәде?» – дигәч, монда килерлек тә хәле юк, дия алмыйм бит, автобуста килгәндә югалттым, дидем. «Кеше күп булгач, абайлап бетермәгәнмен, автобустан төшеп калган». Шулай итеп, иремә икенче группа бирделәр».

Тәкъдир белән алыш

Ул көнне гомерендә дә онытмастыр алар. «Кичтән Сәгадәт белән телевизор карап, йокларга яттык. Иртәнгә язмыш тормышны төбе-тамырыннан үзгәртеп куйган. Ирем кымшана да, сөйләшә дә алмый...» – Фәридә апа хәзер боларны тыныч кына сөйли ала инде. Ә ул вакытта... Хастаханәдән елый-елый кайтканда юл уңае «файдалы киңәш» бирүчеләре дә очрый: «Берәр җиргә илтеп ыргыт, интекмә».

Аның язмышы – тәкъдир белән көрәш. Йә тәкъдир – аны, йә ул – тәкъдирне.

...Хыялында ак халатлы шәфкать туташы итеп күрә иде бит ул үзен. Хәзер аңа хыялында түгел, тормышында шәфкать туташы булырга туры килә менә. Иренең шакыраеп каткан аяк-кулларын яздыру өчен көненә өчәр тапкыр массаж ясый. Үҗәтләнә-үҗәтләнә, «йә, тормыш, кем кемне?» дия-дия, тәкъдир белән узыштан тырыша. Кычыткан суы килешә икән дигәч, тирәюньдә бер кычыткан әсәрен калдырмый. Киштәсендә төргәк-төргәк дару үләннәре кибә...

Хатын-кызны көчсез зат диләр, дөрес түгел – көчле ул. Рухы белән көчле! Ике генә дә түгел, берьюлы дүрт эштә эшләсә эшли, «Ирем авырый», – дип, беркемнән дә ярдәм сорап бармый. Кешеләр йокыдан уянганганда, ул инде бер эшен бетереп кайткан була. Ишеп-ишеп кар яуганда Илназының: «Ур-ра! Безгә акча ява!» – дип шатланганын хәзер кызык итеп кенә сөйләсә дә, урыннан да кузгала алмаган авыру ирен ашатып, сабый баласын җитәкләп, иртәнге дүрттә өйдән чыгып китүләре җиңел булмагандыр. Бер эшен бетергәч, икенче эшенә – кондитер цехына юнәлә. Ул арада базарга чыгып, Мәскәүдән үзе алып кайткан вак-төяген сата. Кич бөтен кеше өенә кайтып киткәндә дә туры өенә кайтасы түгел әле аңа – «Юный техник» йортына гардеробка керәсе.

Авылда җир дә терелтә

2002 елда Азнакай районының Буралы авылына – Фәридә апаның туган авылына күченеп кайта Шәйдуллиннар. Җәлил белән Буралы арасы 15 чакрымдыр. Көн дә бара-кайта йөрисе булса да, авылда тормыш барыбер дә уңайлырак тоела. Авылда җир дә

PRESSA.RU



Авырлыкларга карамый, алар утыз елдан артык бергә. Төп таянычлары – уллары Илназ.

дәвалый бит анда, тынычлыгы, саф һавасы да шифа. Сәгадәт абый да акрынлап тернәкләнә. Аның кашык тотып үзе ашый алуын, кирәген аңлатырлык аваз чыгаруын да зур бәхеткә саный алар.

Иртән күзегезне ачып, аягыгызга баскансыз икән, «уф» та димәгез.

«Төнлә уяндым да, кайгырып ятам – өй иске, кечкенә, яңасын салырга акча юк. Теплица төзесәк, ничек булыр, дигән уй килде башыма. – Фәридә апа күңеленнән Буралыга кайткан гына көннәрен барлый. – Улым белән иске-москы такталардан теплица корып куйдык. Өстеннән целлофан белән ябып, помидор чәчтем. Шулкадәр яхшы булып үсте кәлшәләрем. Беразын саттым, калганын алучы юк. Беркөн базарга сугылсам – халык җыелышкан. Кулларында – буш әрҗәләр. Җәлилдә кырау төшкән дә бөтен кешенең помидорларын кырган. «Очтым» авылга. 15 минутта алып бетерделәр помидорларымны. Өч көндә 150 меңлек помидор кәлшәсе саттым. Шул акча белән өйгә тотындык. Көз көне 100 үрдәк алдым. Кеше көлде инде, бу Фәридә нишләмәкче була аның кадәр үрдәк белән, дип. Аларны да сатып бетердем. Әнә шулай итә-итә, 12 ел салдык өйне».

«Чәкчәк пешерегез – баерсыз!»

Бу кәсепкә үзе дә уйламаган җирдән генә керешеп китә ул. «Беркөнне дус хатыныма барсам, әнисе белән чәкчәк пешереп яталар. Бер тотам гына камырлары бар. Йомшакмы, катымы, дип, барып тотып кына карадым да, өйгә йөгереп кайтып, 30 йомыркадан камыр басып аттым. Майга салуга, кабартма кадәр булып күперде болар. Тагын киттем дус хатынга. Алар ничек итеп кисә икән? Пешереп бетергәч, матурракларын тезеп, целлофанга төрдем дә, киттем базарга. Алып бетерделәр бит! Кайтып, тагын пешердем. Улым белән «бизнес» ачып җибәрдек: мин тәгәрәтеп торам, улым майда пешереп тора. Төне буе пешерәбез дә иртән базарга алып чыгып китәм. Илназ идәнгә түгелгән майга таеп егылмаса, гел шулай пешергән булыр идек әле. «Булды, әни, башка өйдә пешермисең!» – дигәч, авылдагы буш кибетне арендага алдым да чәкчәк пешерә торган кечкенә генә цех ачып җибәрдем». Фәридә апаның кул астында тагын ике кыз эшли. Язмышлары уртак аларның – тормыш арбасын ялгыз тартучылар.

Чәкчәк кенә пешерми әле ул: күп итеп мал-туар да асрый, токмач та кисеп сата, гөлләр дә үстерә, матур өй башмаклары бәйли, заказга күлмәкләр тегә – нәрсәгә көче җитә – барын да эшли! «Теге вакытта елый-елый теләгәнем кабул булды бит, кем нәрсә сорап керсә, шуны биреп чыгара алам!» – Фәридә апа кешеләргә булыша алуына куанып яши.

Буралы бәйрәмнәре

2012 елда – Азнакайда «Ак калфак» оешмасы оешкач, районның мәдәни тормышында яңа дулкын күтәрелә. Фәридә апа үзе дә «Ак калфак»ныкы. Буралыда «буран-нар уйнатып» ята ул. «Башка авыллар гөр килә, бездә генә бернәрсә юк, дидем дә, клуб мөдире янына киттем: «Әйдә, – мин әйтәм, – балалар өчен Сабан туе уздырабыз». Фәридә апа кичтән уйлый икән, иртән аны тормышка ашыру артыннан йөри башлый торган кеше. Шуннан китә инде. 1 сентябрь – балаларны мәктәпкә озату бәйрәме, аннан – Өлкәннәр көне, аннары Яңа ел...

Фәридә апа үткәргән Каз өмәсен авылдашлары һаман да сагынып искә аладыр әле. «Кечкенә вакытымда әни каз өмәсе үткәргән иде. Кызларның чишмәгә каз юарга төшүләре, җигүле атлар, гармун, җыр-бию – күңелемә шулкадәр матур бер истәлек булып кереп калган. Буралы яшьләренең дә сагынып сөйләрлек хатирәсе булсын, дидем дә, казлар сатып алдым, өмәгә кызлар чакырдым. Дугаларына кыңгыраулар тагып, атлар җиктердек. Бик матур бәйрәм булды. Гармуннар белән, җырлый-җырлый чишмәгә каз юарга төшкәннәрне әле дә искә алабыз. Аннары бер ел буе караватт асларыннан каз мамыгы җыйсам җыйдым, аның каруы, гомерлек истәлек булып калды ул».

Тагын бер бик зур, күз төбәп көтеп торган бәйрәме бар аның – тиздән Сәгадәт абыйның 60 яшьлек юбилее. Теге вакытта – иренең гомере кыл өстендә торган чакларда, тагын бераз гына яшәтә алсам иде, улыбызның үскәннәрен күрсә иде дип теләгәндә, ул бу турыда хыялланмаган да булгандыр.

«Язмышка үпкәм юк. Ни күрсәм дә, үкенмим. Иртән күземне ачам да: «Аллага шөкер, таңны күрдем», – дим. Ирем белән улымның сулыш алганнарын ишетәм – шөкер, исән-саулар, дим. Төнлә телефон шалтырамады, димәк, туганнарым исән-саулар.

Өч тапкыр машина белән капландым, өчесендә дә исән калдым. Язмыш мине ирем хакына исән калдыргандыр, дим. «Син яшәсәң, без яшәрбез», – ди бит ул үзе дә».



АКБЕРДИНА Гүзәл. Уфа

Заһир Исмәгыйлев исемендәге Уфа сәнгать академиясе

Кияүдә, бер улы, бер кызы һәм бер оныгы бар.

Карьера: режиссер-куючы, Дамир Сираҗиев исемендәге театраль премия һәм күпсанлы фестивальләр лауреаты. Константин Хабенский-ның «Канат чыгару» иҗади үсеш студиясенең Уфадагы җитәкчесе.

Тормыш шигаре: «Максат түгел, ә аңа ирешү юлы мөһим. Мәхәббәт – бар, менә шул мөһим».

https://www.facebook.com/suyumbike.zhurnaly

Көн саен шатлык

Һәр көн – сөенечле. Иртән торып кояш күрдең – шатлык. Яраткан кешеләреңне күрдең – шатлык. Алардагы үзгәрешләрне күрдең – шатлык. Кичә, мәсәлән, бер олы яшьтәге ханым, үзенең кем икәнен онытып, безне балалар урынына күреп: «Менә, карагыз, минем кулда нәрсә бар? Кайсыгыз белә – шуңа!» – дип уен оештырды. Өлкәннәрнең шушы рәвешле балалыгын саклый алуы – үзе шатлык. Уфада яшәп, Казанга килүем дә, монда яшәүче кызым белән очрашуым да – шатлык.

Кырым – безнеке!

Кырым ярымутравын Керчь бугазы аша безнең ил белән тоташтырачак күпер төзелә. Минем өчен аның символик мәгънәсе бар. Гомумән, «Кырым – безнеке!» булуына сөенәм. Бәлки, кайберәүләргә бу фикерем ошамас та, әмма мин анда еш булам һәм кырымлыларның Россиягә кушылуына сөенүен күрәм. Кырым халкы фашистларга каршы көрәштә катнашкан, партизаннар хәрәкәте көчле булган. Анда Россия өчен күп кан түгелгән. Мин анда Кырым татарлары белән дә очраштым. Алар да безнекеләр бит! Без кушылдык. Бу кушылу авыр булачак, ул озакка сузылачак әле. Әмма безгә кирәк бу.

Без асфальтны ярып чыккан чәчәк кебек

Швейцария белән бер проект эшендә катнашабыз. Эш белән бәйле рәвештә еш кына Европага чыгып йөрибез. Шунысы сөендерә: планетаның теләсә кайсы почмагында да кешеләр бертөрле: алар яратырга, яратылырга тели, алар иҗатка тартыла. Мәгълүмат чаралары негатив белән күпме генә коендырмасын, чәчәк барыбер асфальтны ярып яктылыкка омтыла. Бу җәһәттән безнең (мин бөтен илне күздә тотам) сәнгать, безнең иҗади мохит ирекле. Без хискичерешләребезгә ирек бирә алабыз.

сөендерде

көендерде














Кунакчыллык сатылмый

Кешеләрнең бөтен нәрсәне дә сатып алып була, дип уйлавы өчен борчылам. Үзләре дә сизмәстән, шушы фикергә ияләшәләр дә үзара хөрмәт турында бөтенләй онытталар. Бер-берсен үпкәләтәләр, авыр сүзләр әйтәләр. Бу юлы Казанга килүемдә шуңа бәйле бер күңелсез хәл булды. Мәдәниятка кагылышлы югары даирәләрдә андый мөгамәлә булыр дип көтмәгән идем. Татар халкы бик кунакчыл халык бит. Ул беркайчан да кунагына караңгы йөз күрсәтмәс.

Иҗат кешесе яклanmаган

Быел август аенда Россия режиссеры Кирилл Серебренниковны, акча үзләштерүдә гаепләп, кулга алдылар. Ул «Платформа» проектына бюджеттан бирелгән акчаларны урлауда гаепләнә. Мине бу вазгыять тулаем борчый. Ул гаепле булганга гына түгел. Фейсбукта һәм башка социаль челтәрләрдә аңа карата чын-чынлап хөкем оештырдылар, чукырга ябырылдылар. Мондый реакция, менталитеттагы менә шушы сыйфат борчый. Иҗат кешесе якланмаган! Кеше башкаларга охшамавы, башкача уйлавы белән ирекле. Гаепләме, түгелме – прокуратура тикшерер. Нигә инде моннан шоу ясарга?

Тук тормыш та буа икән

Шул ук вакытта чит илләрдә эмоциональ интеллектка кытлык тоясың. Бигрәк тә нык алга киткән, үсешкә ирешкән илләрдә сизелә бу. Мәсәлән, Швейцария психик авырулар саны буенча беренче урыннарда бара. Андагы кешеләр белән, әйтерсең лә, пыяла аша сөйләшәсең. Алар ябык. Аларның бугазындагы чалу сөяге дә туктаусыз йөреп тора: гүя аларны нәрсәдер буа. Югыйсә җитеш тормышта яшиләр, иртәгесе көннәре турында борчыласы юк. Ни җитми?

PRESSA.RU


Батырның туган көнендә (Германия һәм АКШтагы дуслары белән), Кашкайш яр буе, Португалия


Гауда шәһәре Нидерланд


Гауда шәһәре Нидерланд


Не́ймеген шәһәре, Нидерланд


Делфт шәһәре, Нидерланд


Заансе-Схanс музее, Нидерланд


Лиссабон шәһәре, Португалия


Пена сарае, Синтра шәһәре, Португалия


Делфт шәһәре, Нидерланд


Зонненкопф тауда чаңгы шуу курорты, Австрия


Маття́ чәе. Камакура шәһәре, Япония


О́бидуш шәһәре, Португалия

УЕНЧЫКЛАР... СӘЯХӘТ ИТӘ?



Галия ГЫЙМАДИЕВА

Без яшәгән дөнья бик киң һәм бик кызыклы ул. Менә нәкъ шушы минутта аның башка бер кыйтгасында, син беркайчан аяк басмаган почмагында кемдер үзенең милли ризыгын пешерә, кемдер Җир шарының иң бөек нокталарыннан саналган таулар итәгендә басып тора, икенче берәүләр тарих эзләрен саклаган истәлекле урыннар яныннан узып бара... Ә сезнең өйдән чыкмыйча гына боларның барысын күрәсегез, шушы кешеләр янәшәсендә буласыгыз – дөнья гизәсегез киләме?

Гаҗәпләнмәгез, чыннан да мөмкин эш бу! Һәм сезгә бу мөмкинлекне сәяхәт итүче уенчыклар бирә ала.

«Ничек сәяхәт итә соң бу уенчыклар?» – диярсез. Бүген инде бар дөнья буйлап таралган бу күренешнең, бу мавыгуның тарихы болайрак. 2001 елда экранга «Амели» фильмы чыга. Әлеге фильмда Амели исемле кыз үзенең әтисен шатландырыр өчен аның бакча гномын таныш стюардессасына «ияртеп» сәяхәткә җибәрә. Әтисе башта гномны кемдер урлаган дип уйлый, ләкин, ни гаҗәп, бераздан аңа гном исеменнән дөньяның төрле почмакларыннан фотосурәтләр килә башлый. Нәкъ менә шушы гном www.toyvoyagers.com сайтын башлап җибәрүче өчен бер илһам чыганагы була да инде. Бу сайт башта бер эксперимент буларак кына барлыкка килә. «Ирекккә чыгарылган», ягъни очраклы кешеләр тапсын да алсын өчен җәмәгать урыннарында калдырылган (чүплеккә чыгару белән бутамагыз!) уенчыкларны күзәтү мөмкинлеген биргән ул. Сайтта һәрбер уенчыкның үз номеры һәм сәхифәсе бар: анда аның хуҗасы (йә кабул итүчесе) фотографияләр өстәп, төрле узган вакыйгалар, кызыклы урыннар, рецептлар һәм башка нәрсәләр турында яза ала. Шунысы мөһим: бу сурәтләр һәм язмалар уенчыкның үз исеменнән булырга тиеш!

Тора-бара ToyVoyagers дөньякүләм бер ширкәткә әверелеп китә. Хәзер инде рәсми сайттан тыш, уенчыкларның мәҗараларын Facebook, Flickr кебек социаль челтәрләр аша күзәтеп була. Кайбер уенчыкларның хәтта аерым блоглары да бар! Алай гынамы, Чехиядә һәм Япониядә йомшак уенчыклар өчен инде махсус сәяхәт бюролары да ачылган!

Бу мавыгу үзенә нәрсә белән җәлеп итә соң? Әйткәнемчә, ToyVoyagers – уникаль бер күренеш: уенчыкка ияреп, аның күзләре белән дөнья күрү, чит илләрдәге тормышны эчке яктан күзәтү мөмкинлегенә тудыра ул. Моның өчен почтага барып, кечкенә илгизәрне посылка белән «мин аны кабул итәргә әзер» дигән кеше адресына җибәрергә генә кирәк. Аннан инде уенчыгыңның сайттагы сәхифәсеннән яңартуларны, яңалыкларны түземсезләнеп көтәсе, күзәтәсе генә кала.

«Кунак» уенчыкларны күбрәк хатын-кызлар кабул итә, әмма арада ир-атлар да очрый.

Улым белән без кечкенә тычкан малае Батырның һәм шаян маэмаебыз Караколакның маҗараларын әнә шулай көтеп утырдык та инде. Ел ярым вакыт эчендә алар икәү бергәләп ун илдә булдылар! Алар белән бергә без Гауда шәһәрендә (Голландия) сыр ашадык, Фольксваген заводында (Германия) машиналар карадык, Австрия тауларыннан сноубордта шудык, Португалиядә океан буенда пикник оештырдык, японнарның бамбук бакчаларында йөрдек... Һәм тагын бик күп-күп нәрсәләр эшләдек! Еш кына безнең уенчыкларга башка илләрдән килгән йомшак сәяхәтчеләр дә кушылды, һәм алар бер хуҗада берничә җыелдылар – дөньяны бергәләп карадылар. Кайчагында сәфәрчеләребез төрле җирләрдән безгә открыткалар «җибәрделәр». Өйгә кире әйләнеп «кайтканда» алар беркайчан буш кул белән кайтмадылар: үзләре белән гел бүләкләре, күчтәнәчләре дә була иде. Гадәттә, без посылкаларны улым белән бергә ачабыз. Әмма безнең бу мавыгуны белгән барлык якыннарым, туганнарым һәм дусларым: «Караколак хәзер кайсы

PRESSA.RU



■ Нидерландтан килгән Дилле исемле кунак курчакка *(сул якта)* хәтта татар милли күлмәген дә тектердем (ул кемгә генә кунакка барса да, үзенә шулай яңа кием тектерә иде).

илдә?», «Батыр әйләнеп кайттымы әле? Үзе белән ниләр алган?» – дип гел сорашып, кызыксынып торалар – аларга да кызык!

Гомумән, посылка алу һәм ачу – дулкынландыргыч бер вакыйга.

Мавыгуның икенче ягы да бар. Күңелле ягы! Үз уенчыгыңны сәфәргә озатып кына калмыйсың, башкалар җибәргән йомшак сәяхәтчеләрне син дә үзегездә кунак итәсең. Без сигез илдән инде сигез уенчык кабул иттек: Британиядән фил малае Glennны, Финляндиядән Aura исемле камканы, Кытайдан курчак кызы Hanselны, Америкадан күкшә кошы – Buzzны, Нидерландтан Dille исемле курчакны, Германиядән Gustav исемле смайликны, Япониядән бака кызы Matchaны, Канададан бөркет малае Landrovalны... Ә алар, әйткәнемчә, барысы да күчтәнәч «тотып килә». Мәсәлән, Голландиядән килгән «кунагыбыз» милли бизәкле кухня бияләе алып килгән иде. Ә Португалиядән килгәне безне балык консервасына охшатып ясалган шоколад белән «сыйлады». Эш бүләкләрдә генә түгел бит: өйгә яңа уенчык килү һәрвакыт көндәлек тормышны, яшәешне балкытып җибәрә, аңа бер яңалык өсти. Хәтта токмач басып аш пешерү дә кечкенә сәфәрче белән бер маҗарага, вакыйгага әйләнә. Токмач камырын ничек басканыңны, аны ничек җәйгәнеңне, аннан вак кына итеп кискәнеңне – барысын-барысын «кунак»ның сайттагы сәхифәсендә сөйләргә, фотолар урнаштырырга кирәк. Бу юлларны укучылар токмачны үзләре җәеп, кисеп карарга теләрлек итеп!

Ә инде «кунак»ка үзегез яшәгән шәһәрне «күрсәтик» дип, урамга чыксаң, үзең дә сизмичә, барысына да яңа караш белән карый башлыйсың – читтән килгән кеше карашы белән. Никадәр яңалык ачасың! Татарның гореф-гадәтләре, мәдәнияте турында сөйләгәндә дә шулай бу. Сәяхәтчеләр белән бергә татар театрын да карадык, милли ризыклар да пешердек, аларны мин татар теленә дә өйрәттем...

Сәфәрче нәни дуслар ялкауланырга ирек бирмиләр: аларга күрсәтер өчен шәһәрнең кызыклы урыннарын искә төшертәләр, яңа идеяләр эзләтәләр, иҗади хыялларны үстерәләр... Гомумән, ToyVoyagers балалар, гаилә белән бергә вакыт уздыру өчен менә дигән бер шөгыль. Дөньяның киңлеген, төрлелеген шундый уен формасында өйрәнү, ачуның отышлы, файдалы яклары бик күп. Минем үзем өчен иң беренче чиратта, ToyVoyagers – дөньяга татар халкы, аның мәдәнияте, гореф-гадәтләре, йолалары турында ишеттерүнең, танытуның бер юлы ул.

...Кунак киткәч, өй бушап, күңелсезләнеп кала бит – монда да шулай. Чираттагы уенчыкны алдагы сәфәренә озаткач, аның турында бик озак искә төшереп сөйләшәбез. Бигрәк тә аларга улым ияләшә, ул сагына.

Ә бераздан инде яңа уенчыкны көтә башлыйбыз...

БЕРНИЧӘ КИҢӘШ



ToyVoyagers белән шөгыльләнергә теләүчеләр сәфәргә җибәрү өчен нинди уенчык сайлый ала?

■ Җиңел. Почтада артык авырлык өчен акча түлисе булганга, уенчыкның авырлыгы 150-200 граммнан да артмасын дип киңәш итәләр. Шул ук вакытта бик кечкенә «сәяхәтчеләр» дә хупланмый, чөнки аларны югалту ихтималы зур. Бәләкәй уенчыкларны фотога төшерергә дә уңайсыз.

■ Рәхмәтле. Уенчыклар буш кул белән сәяхәт итәргә «яратмыйлар», алар кабул итүчеләргә кечкенә генә бер күчтәнәч алып барырга ияләшкән. Без җибәргән чәкчәкне, Казан сурәтләре төшкән магнитларны, күн читек формасындагы брелокларны, сувенирларны барысы да яратып кабул итте.

■ Иң яраткан уенчыгың булмасын. Бу киңәш сәеррәк тә тоелырга мөмкин, ләкин эш шунда ки – уенчыклар почта аша сәяхәт итә, ә алар, кызганычка каршы, анда югалырга да мөмкин. Шуңа күрә иң кадерле уенчыгыгызны андый хәтәр юлга җибәрмәсәгез яхшырак. (Безнең бер Чебешебез әйләнеп кайтмады шулай.)

Бу гади киңәшләргә колак салсагыз, кечкенә сәфәриләрнең сәяхәтләре тагын да күңеллерәк узачак.

TATAR RADIOSI ХИТЛАРЫ

ҖАНЛЫ КОНЦЕРТ

РЕКЛАМА

Халыкара «Татар җыры» эстрада фестивален һәм «TMTV» телевизион премияләрен тапшыру тантанасын оештыручылар тәкъдим итә:

«Татар Радиосы» концерты – ел саен зурлап үткәрелә торган масштаблы чараларның берсе. Татар җырларын яратучылар өчен онытылмаслык бәйрәм, популяр артистларның чыгышларын карап, радионың «алтын хитларын» тыңлап кайту мөмкинлеге. Еллар белән сыналган җырлар инструменталь яңгырашта кабатланмас мохит тудыра.

Гала-концертны оештыручылар сәхнә бизәлеше, режиссура, күз явын алырлык киемнәр, җанлы музыка уен кораллары, инструменталь ансамбльгә игътибарны юнәлтеп, югары дәрәҗәдәге тамаша булачак дип вәгъдә итә.

«Татар Радиосы» тыңлаучыларының яраткан артистлары үзләренең иң яхшы хитларын, сезгә таныш җырларны башкарачак: Илназ Бах, Раяз Фасыйхов, Эльмира Сөләйманова, Ландыш, Илсия Бәдретдинова, Алсу-Азат Фазлыевлар, Ринат Рәхмәтуллин, Айгөл Рәхимова, Азалия Зиннәт, Мөнир Рахмаев, Хәмдүнә Тимергалиева, Идрис Газиев, Ләйсән Гыймаева, Илмира Нәгыймова, Ришат Фазлыйәхмәтов, Зөһрә Шәрифуллина, Закир Шаһбан, Илсаф, Артур-Марат, Айдар Галимов, Фирдүс Тямаев, Салават һәм башкалар – «Пирамида» сәхнәсендә чыгыш ясаячак.

Гала-концертның алып баручылары ролендә сез Татарстанның атказанган артисты Гөлназ Сәфәрова белән Татарстанның халык артисты, Г. Камал театры актёры Искәндәр Хәйруллинны һәм «Татар Радиосы» алып баручысы — Айваз Садыйров белән Татарстанның атказанган артисты, «Голос» телепроекты финалисты Эльмира Кәлимуллинаны күрә алачаксыз. Гала-концертның режиссеры – республика һәм хөкүмәт концертларының баш режиссеры, «Шарм» сәнгать театры җитәкчесе – Максим Скалозубов.

1 октябрьдән 21 октябрьгә кадәр «Татар Радиосы»н игътибар белән тыңлаучылар бу концертка билет та отып куярга мөмкин!

21 октябрь көнне 17.00 сәгатьтә «Пирамида» мәдәни-күңел ачу үзәгендә очрашырбыз.

6+

PRESSA.RU



ИТАЛИЯ КАНИКУЛЫ




Фирүзә
ДӘҮЛӘТШИНА

ӨЧЕБЕЗНЕҢ ДӘ ЕГЕРМЕНЧЕ ҖӘЕ ИДЕ УЛ. БЕЗ АНЫ МОҢА КАДӘР БУЛМАГАН ЭЧКЕ БЕР АШКЫНУ БЕЛӘН КӨТЕП АЛДЫК. ЯҢА ДӨНЬЯЛАР АЧАРГА ВАКЫТ! ОНЫТЫЛМАСЛЫК СӘЯХӘТКӘ КУЗГАЛЫРГА!



■ Милан. Аны «шопинг башкаласы» дип тә атыйлар.

■ Верона. Джульетта йорты. Менә ул атаклы балкон!



Без – өч дус кыз – булачак архитекторлар. Шуңа күрә «кая барырга?» дигән сорау тугач, озак уйлап та тормадык. Италиягә! Архитектура бишеге булган Италиягә барырга кирәк. Тур белән барабызмы, әллә үзебез генәме дигән сорауга җавап эзләп тә мәшәкатьләнмәдек – әлбәттә, үзебез. Ирекле сәяхәт булсын, туристлар аягы басмаган җирләр гизелсен... Маршрут төзү, билетлар алу, кунакханәләр табу кебек эшләрне хәл иткәч, чемоданнарыбызга матур күлмәкләребезне салдык та, фотоаппаратларыбызны алдык та, күптән хыялланган сәяхәткә кузгалдык.

Милан

Сәяхәт маршрутын төзегәндә, төньяктан көньякка таба хәрәкәт итәргә булдык. Дөресрәге, башта ике генә шәһәргә барырбыз дип уйлаган идек. Тик интернетка кереп китеп эзләнә торгач, әйдә монысына да барыйк дия-дия, алты шәһәрне сайлап куйганыбызны сизми дә калдык.

Маршрутыбызның беренче ноктасы – Милан. Шопинг башкаласы дип аталган шәһәргә килеп төштек тә, иң беренче эш итеп кибеткә түгел... урамда йөрергә киттек. Күкрәк тутырып Италия һавасын сулыйсы, урамнарында йөреп, кешеләре белән аралашып, шушы илнең атмосферасына башаяк белән чумасы килде. Кибетләр качмас ул!

Адаша-адаша, үзебез өчен яңа урамнар ача-ача, шул ачышларыбызга сөенә-сөенә йөрибез дә йөрибез. Берәр бинаның матурлыгы күңелебезгә генә сыймаса, брусчаткага утырабыз да, блокнотны алып, матурлыкны кәгазьгә төшерә башлыйбыз. Монда бу гадәти күренеш: берәүләр әнә юл кырыена утырган да тамак ялгый, икенчеләр хәл җыя. Ә без рәсем ясыйбыз. Кешеләр килеп танышалар, мактыйлар, хәтта «бу рәсемеңне сат әле» диючеләре дә бар. Ә безгә рәхәт: без әле бүген генә Италиягә килеп төштек һәм инде кояш нурлары биешкән йорт фасадларын дәфтәребезгә һәм күңелебезгә дә төшерә башладык.

Верона

Миланда кунып тормыйча, икенче шәһәргә юл тоттык. Веронага барып җиткәндә төн иде инде. Әллә Италия һавасын күбрәк сулап ташлап башлар әйләнгән шунда: телефоннарыбызга зарядка җыйдырырга да оныткангбыз. Карта да юк, интернет та. Кулыбызда бары тик без барасы кунак йортының (кунакханәнең бер төре) адресы язылган кәгазь генә. Нишләргә? Яныбызда барысын да хәл итәргә әзер торган әти-әни дә, салкын акыл белән эш итә торган ир-ат та юк. Чит ил, чит шәһәр, чит тел куркыта да бит әле. Тик баш миенең бер өлеше: «Төнлә урамда кала алмыйсыз бит! Йә, куркуыңны онытып тор әле», – дип сулкылдый башлауга, үзебезне кулга алырга һәм кинәт кенә бик-бик көчле кызларга әйләнергә туры килде. Кешеләрдән сораша-сораша, ничек кирәк шулай аңлашып, үзебезгә кирәкле кунак йортына исән-имин барып җиттек.

Кулыбызда карта да юк, кая барасын да белмибез. Шулай кызыграк.

Верона Ромео белән Джульетта шәһәре буларак билгеле. Монда Джульеттаның атаклы балконы бар. Балкон янына бөтен дөньядан кызлар, апалар, тол хатыннар килә. Хат язып алып киләләр. Аларны ачып укымасак та, эчтәлеген беләбез: үзләренә насыйп яр сорый ул кызлар. Балкон янындагы дивар да шундый ук теләкләр белән язып тутырылган. Ә без хат язмадык. Язасы килмәүдән яки ышанмаудан да түгел. Икенче тапкыр килгәндә язарбыз дидек. Кабат килү теләге бөреләнә башлаган иде шул инде.

Иң тәмле пиццаны да Веронада ашадык без. Рекламаларда күрсәтелгән кыйммәтле рестораннарда сатылмый ул, юк. Аулак бер урамнан барганда, кечкенә генә кафега юлыгасың. Хуҗа кеше өйнең икенче катында

PRESSA.RU



■ Венеция. Канал-урамнарына карауга ук, аны шундук танып аласың һәм башка бер шәһәр белән дә бутый алмыйсың.

■ Римини. Диңгез буенда ятып ял итәргә теләүчеләр, гадәттә, шушы шәһәрне сайлый.





яши, ә беренчесендә кечкенә генә кафе ачып җибәргән. Өч-дүрт өстәл генә бар анда. Һәм иң тәмле пицца – шунда!

Кайбер йортларга, кибетләргә бары тик су аша гына барып була.

Венеция

Европада транспортка билетлар төнлә арзанрак. Шуңа күрә без дә бер шәһәрдән икенчесенә төнлә барырга тырыштык. Венециягә дә төнлә килеп җиттек.

Венеция – үзенең канал-урамнары белән данлыклы шәһәр. Гондолалар, катерлар йөреп кенә тора. Шуңа күрә монда гондолачы хезмәте бик яхшы эш санала. Ярты сәгать йөреп килү 80-100 евро тора бит анда. Их, ярты сәгать булмаса, хет унбиш минут кына булса да йөреп килергә иде шул каналлардан! Тик гондолага түгел, вапоретто дип аталган су трамваена да акчабызны жәллибез. Анысы – безнең акча белән мең сум тирәсе. Ә безнең әле тагын күпме шәһәргә барасы бар!

Җәяү генә барырга кала инде. Без сайлаган хостелга барып җитү өчен җиде күперне үтәсе бар. Һәм без, матур күлмәк-туфлилар кигән кечкенә генә буйлы өч кыз, 20 шәр килолы чемоданнарыбызны брусчатка ташларыннан сикертә-сикертә, юлны үтә башлыйбыз. Бәхеткә, гел яхшы кешеләр очрап тора, алар безгә исән-имин барып җитәргә ярдәм итә.

Иртән кояшның беренче нурлары күзләрне кытыклый башлауга, йөгереп барып тәрәзәне ачабыз. Тәрәз төбеннән үк канал башлана, Венециянең кайнап торган тормышы бүлмәгә бәреп керә. Иң матур күлмәкләребезне киеп, шәһәр белән хозурланырга чыгып китәбез. Һәм шул вакыт яныбызга катер килеп туктый. Йөртеп килергә тәкъдим итәләр. Бернинди начар ниятсез, чын күңелдән. Канал буйлап йөреп килергә иде дигән хыялыбыз әнә шулай тормышка аша.

Кояш нурлары тулган тар урамнар, төрле төстәге йортлар, малахит һәм фирүзә төсендәге каналлар, бер-берсенә тиеп диярлек узып китүче гондолалар, елмаеп кына торган кешеләре – Италия көннән-көн ныграк ошый бара.

Римини

Моңа кадәр кунакханәләрдә, хостелларда кунып йөргән булсак, Риминида каучсерфинг хезмәте аша тапкан кешеләрдә калырга тиеш идек. Каучсерфинг – туристка бушлай кунып чыгу өчен урын табарга ярдәм итә торган хезмәт. Безне әти-әнисе белән яшәүче бер егет үз фатирларында сыендырырга ризалашты.

Әлеге егет көндез эшли икән. Шуңа аның әти-әнисе белән калырга туры килде. Без – итальянча, алар инглизчә белмәсә дә, уртак телне тиз таптык. Аралашканда «гугл-тәрҗемәче» ярдәм итте. Безне үз кызлары кебек кабул итте ул апа белән абый. Йокыдан торуыбызга безнең өчен иртәнге аш әзерләп куюларын әйт әле син! Югыйсә моны эшләргә тиеш тә түгелләр бит. Фатирлары да кечкенә генә. Ни өчен шушылай – кешеләргә бушка яшәү урыны бирәсез, дип тә сорадык. «Мөмкинлегебез бар икән, нишләп әле яхшылык эшләп калмаска!» дигән җавап тагын да гаҗәпләндерде. Хәер, без мондагы якты, ачык күңелле кешеләргә күнегә башлаган идек инде.

Римини – пляж шәһәре, ял шәһәре. Менә – алсу ятаклы комлык, менә монысы – зәңгәрсу ятаклы, монысында волейбол уйныйлар, ә тегесендә күбекле шоу бара. Без дә рәхәтләнеп ял иттек...


Флоренция

Архитектура белән кызыксынган кешегә бу шәһәр исемен әйтсәң, күзләрендә очкын кабынмый калмас. Заманында иң танылган архитекторлар шушында яшәп киткән бит. Шуңа күрә кайчандыр алар йөргән эзләрдән



■ Флоренция. Безгә – булачак архитекторларга бу кала иң кызыгы тоелды.

■ Рим. Монда кадәр кил дә, Коллизейны күрми кит инде!



йөрү, алар кулы тигән биналарны үз күзебез белән күрү безне аеруча тәэсирләндерде.

Флоренция – бик эссе шәһәр. Дымлы һава, кояшта кызган брусчаткадан күтәрелгән пар белән кушыла да, тагын да кайнарлык өсти кебек. Тик без бу эссе һаваны да һәр күзәнәгебезгә сеңдереп калырга тырыштык. Анысына башыбыз эшләде, ә менә үзебезгә азык-төлек алырга онытылган. Ял көне Италиядә кибетләр эшләмәвен белә дә идек югыйсә. Кибетләр дә, кафелар да ябык. Ә безнең эчәргә суыбыз да юк. Әллә ничә урам үтеп, бер кунакханәне эзләп табып, шуның ресторанында өч тапкырга кыйммәтрәк бәягә су алып эчәргә туры килде. Әйбәт сабак булды бу.

Гомумән, итальяннар үзләрен дә, тормышны да бик ярата. Шуңа күрә алны-ялны белми эшләмиләр. Мәсәлән, төштән соң сиеста дип аталган ике сәгатьлек яллары бар. Сиеста вакытында урамда туристлар гына йөри. Ә итальяннар үзләре өйләренә кайтып, черем итеп ала. Сиестадан соң – теләсәләр эшкә киләләр, теләмәсәләр – килеп тә тормыйлар. Ә без нәрсә? Без гел каядыр ашыгабыз, чабабыз. Кайвакыт туктап, күкрәк тутырып сулыш алырга, һәр туган таңнан тәм табарга да онытабыз.

Рим

Беренче эш итеп, әлбәттә инде, Колизейга киттек. Һәм... күңелебез төште. Вакыт җиленә түзмичә, җимерелә башлаган Колизейда реставрация үткәргәннәр, тик төзекләндергән өлешен бөтенләй башка төрле материалдан эшләгәннәр. Мин – яңа материал, ә күршедәгесе – иске, дип кычкырып тора сыман. Ул вакытта безгә университетта реставрация дәресе керми иде шул әле. Һәм без, төзекләндергәндә, материалның аерылып күренеп торырга тиешлеген белми идек. Беренче эшләгән авторны кабатламас өчен шулай эшләнә икән ул.

Италиягә килгән бөтен кеше күреп китә торган Изге Петр соборына да бардык. Соборның тар гына 551 баскычын үтеп, түбәсенә кадәр мендек. Ә аннан кояш баешы күренә. Бу минем гомеремдәге иң матур кояш баешы иде. Йөрәк туктап торган кебек булды, тәнгә дулкын булып тынычлык йөгерде, иреннәргә үзеннән-үзе елмаю кунды. Италия каникулының соңгы сәгатьләре нәкъ менә шушында, нәкъ менә шушы биеклектә узарга тиеш иде. Баеп барган кояшка карап, теләк теләдек. Яңадан кайчан да булса бирегә әйләнеп кайтырга язсын!

Италия безне тормышны ныграк яратырга өйрәтте.

Аш-су



■ Кояшлы Италиядә яшәүчеләрнең иң популяр ризыгы дип паста белән пицца санала. Әмма тортеллини дигән ризыклары да популярлыкта алардан калышмый. Тортеллини – төче камырга ит, сыр яки яшелчәләр төреп әзерләнә. Кыяфәте белән безнең пилмәнгә охшаш. Итальяннар үзләре аны роза чәчәгенә охшаталар.
Пилмәннәренең камыры да төрле төстә булырга мөмкин. Шпинат кушылганы – яшел, томат кушсалар кызыл төстә. Тортеллинины табынга соус белән дә, шулпа белән дә бирергә мөмкиннәр. Итальяннар үзләре пилмәнне каплун (үзгә ысул белән үстерелгән әтәч) шулпасында гына әзерлиләр.

PRESSA.RU

16+

ХАТЫН-КЫЗ ИКЕЙӨЗЛЕ БУЛМАСЫН



Мирсәет СӨНГАТУЛЛИН,
Россиянең атказанган,
Татарстанның халык артисты;
гаилә стажы – 32 ел;
бер бала атасы.

Ир-ат һәм хатын-кыз. Бер үк галәмгә без бит очраклы гына эләкмәгән... Шулай булгач, нигә соң бер-беребезне күп вакыт аңламыйбыз? Гамәлләребезне, теге яки бу адымыбызны, әйткән сүзләребезне... Үзара тартылуны «җиңеп», арага каршылыклар керә дә куя...
Ә ир-атлар үзләре бу хакта ни уйлый икән?
Сүзне аларга бирик.

1 Иң элек хатын-кызның нәрсәсенә игътибар итәсез: киеменә, буй-сынына, күзләренә, чәченә...

– Мин башта хатын-кызның буй-сынына, кием-салымына игътибар итәм бугай, ә аннан, якыннан сөйләшә, аралаша башлагач, акылына, күңеленең байлыгына, матурлыгына...

2 Хатын-кызның кайсы сыйфатларын гафу итәргә була?

– Начарлыкны сиңа махсус, алдан уйлап эшләмәсә, ниндидер сиңа ошамаган адымы булса да, ул аны ялгыш, белмичә генә эшләсә – боларны гафу итеп була.

3 Ә нәрсә өчен сез бик якын хатын-кызны да гафу итмәс идегез?

– Минем җавабым башка ир-атларныкыннан аерылмас: иң мөһиме – хатын-кыз сиңа хыянәт итмәсен. Хатыны хыянәт итеп тә, аны гафу иткән ир-ат турында минем ишеткәнем юк. Яратмаса, аңа барыбер булган очракта, бәлки, гафу да итә аладыр, анысын белмим. Тормыш бит – төрле хәлләр булырга мөмкин.

Хатын-кызның тагын икейөзле булуын, алдашуын яратмыйм.

4 Ир кеше өчен аның хатыны дус та була аламы?

– Өч дистә ел янәшә яшәгәч, ул инде синең дустың да, туганың да, киңәшчең дә, булышчың да – барысы да була ала. Без бөтен нәрсәне дә уртага салып сөйләшә алабыз: тормыш хәлләрен, авыл яңалыкларын, җандагы борчуларны, берәүгә дә әйтмәгән шатлыкларны... Алмаз өйдә чак булса, бу сөйләшүләргә ул да кушылып китә – өч дуска әйләнәбез.

5 Хатыныгызга ничек тәкъдим ясаганыгызны хәтерлисезме?

– Хатыным Кадерия белән без Мәскәүдә таныштык. Муллануp Вахитовның 100 еллык юбилее уңаеннан концертлар куярга барган идек. 1985 елның октябрь ае бу. Концертлар Мәскәүдә ун көнгә якын барды. Мин Анатолий Шутиков җитәкчелегендәге халык уен кораллары оркестрына кушылып, «Мулланур Вахитов» дигән җыр белән концертны башлап җибәреп, татар халык көе «Кичке авыл» белән үземнең чыгышымны тәмамлап керә идем. Чыгышларыбызның икенче көнендә Кадерия миңа сәхнәгә чәчәкләр менгерде. Концерт тәмамлангач карыйм, шул кыз сәхнә артында йөри! Әлфия апа Афзалова бүлмәсенә кергән. Вафирә дә шунда, Илһам абый да. (Мәскәүдәге концертлар вакытында Вафирә Гыйззәтуллинаның гел Кадериядә тукталуын соңрак белдем.)

Фабрикада инженер булып эшләсә дә, сәнгатькә, җыр-моңга, театрга гашыйк бер җан булып чыкты ул! Бөтен артистларны белә – безнекеләрне дә, башкортларны да. Фидан Гаффаров, Әнгам Атнабаев белән якыннан аралашып яши, Уфада да үз кеше... Бүгенгедәй күз алдымда: ул көнне өстендә куе зәңгәр төстәге велюр костюм иде аның. Гәүдәсенә ятып тора – шундый матур!

Мәскәүдәге концертлар беткәнче без Кадерия белән телефон аша хәбәрләшеп тордык. Аннары ул Казанга – Вафирәгә кунакка килде. Без аның белән бик озак Казан урамнарында йөрдек... Бераздан мин Мәскәүгә бардым. Кадерияләргә кыз сорарга – Горький өлкәсе Сергач районы Шөбиле авылына без Вафирә һәм аның баянчысы белән өчәү кайттык. Әти-әнисе яңа өй салып кергәннәр иде, хәтеремдә: табын артында кич буе җырлашып утырдык. Никахны да аларда укыттык. Ә туебыз Казанда, «Татар ашлары йорты»нда узды: өстәлләрдә атаклы аш-су остасы Юныс абый Әхмәтҗанов пешергән ризыклар иде.

Кадерия Мәскәүдән күченеп кайтты, тик безнең Казанда яшәргә урыныбыз булмады. Филармония бүлмә вәгъдә итте, әмма бирмәде. Гыйнвар буе йөрдек туганнарда кунып, февраль, март буе... Аннан, кеше почмакларында йөреп арыдык, туйдык һәм Мәскәүгә китеп бардык: Кадериянең анда бүлмәсе бар иде. Филармониядән эштән китмәдем, кайтып 16 концертымны куям да, тагын Мәскәүгә билет алам... 1987 елда Рифкать Сәйфетдинов белән «Бәйрәм» ансамблен оештырдык. Мин аннан 1989 елда киттем – урыныма Хәния Фәрхи урнашып калды... Бер концерт вакытында Минтимер Шәймиев белән очраштык та: «Төп проблемаң фатирмы? Кайт,

син татар халкына хезмәт итәргә тиеш», – диде ул миңа. Яшәү урыны хәл ителгәч, әлбәттә, кайттым.

6 Ир кеше хатын итеп әнисенә охшаган кызны сайлый диләр, шулаймы?

– Күңеленә ошаса, әнигә охшаганмы, юкмы дип тормый, ир кеше күзе төшкән кызга өйләнә инде ул. Кадерия белән әнинең, мәсәлән, тышкы кыяфәтләре капма-каршы: хатыным – чын блондинка, ә әни кара кашлы, кара күзле, кара чәчле татар хатыны. Дөрес, алар икесе дә Сукояр йолдызлыгыннан, шулай булгач, уртак сыйфатлары барыбер бар инде. Минем әти дә, әни дә мәрхүмнәр инде, Кадериянең дә әтисе исән түгел. Алар ягында мәетләр рухына ел саен Коръән укыталар һәм аны һәрвакыт «ел ашы» дип атыйлар. Күптән түгел авылга кайтып, әтинең елын укытып килдек. Әнинекен монда гына үткәрдек. Боларның барысын да Кадерия оештыра, ул башлап йөри.

7 Хатыннары ирләреннән күбрәк мал тапкан гаиләләр бар. Ир кеше бу очракта үзен ничек тотарга тиеш?

– Белмим, безнең үзебезнең гаиләдә мондый хәл булмады. Улыбыз Алмаз тугач, Кадерия инде өйдә генә торды. Аның төп эше – улыбызны тәрбияләү булды. Беренче сыйныфка укырга кергәч, без Алмазны музыка мәктәбенә дә бирдек. Ул скрипка классында укый башлады. Кадерия аны мәктәптә укулары беткәч кереп ала, икенчесенә илтә, анда дәресләр тәмамлангач, өйгә алып кайта... Мин аңа бу эшләрдә бер дә ярдәмче була алмадым. Элек норма буенча без, әйткәнемчә, айга 16 концерт бирергә тиеш идек, димәк, ярты ай өйдә булмыйсың дигән сүз. «Бәйрәм» ансамбле белән берсендә тоташ ике ай гастрольдә йөрдек! Улыбыз ул чакта кечкенә иде әле, Кадериягә булышырга авылдан әби килде. Алмазның бүгенге уңышларында әнисенең өлеше бик зур. Ул Мәскәүдә консерватория тәмамлады. Кызыл дипломга! Хәзер аспирантурада укый, фәнни эш белән шөгыльләнә.

8 Гашыйк булуын хатын-кыз башлап үзе белдерүгә ничек карыйсыз?

– Мин үзем, гашыйклыгын хатын-кыз беренче булып сиздерсә, ир кешегә яратуын әйтү җиңелрәк була дип саныйм. Әмма башка төрле уйлаучылар барын да беләм. Бер дустым мондый чакта: «И-и, моның бөтен сере бетте бит инде», – дия иде... Шул ук вакытта, мондый очракларда икейөзле кешегә очрау куркынычы да зурдыр дип уйлыйм. Бигрәк тә бүгенге яшьләргә. Фатирың, машинаң, кесәңдә акчаң булса, яратмасалар да, «яратам» диючеләр табыла торган заман. Андыйларның чын йөзе ачылганда артык соң булырга да мөмкин.

9 Хатын-кызларны ир-атларда иң беренче чиратта нәрсә җәлеп итә дип саныйсыз?

– Бер күрүдә җәлеп итәргә мөмкин нәрсәләр күптер инде ул: ир-атның таланты, булдыклылыгы, үз-үзен тотышы, буй-сыны, тышкы кыяфәте, киеме... Бүгенгеләр бу исемлеккә «акчасы, машинасы бармы, әти-әниләре кем?» дигән сорауларны да кертәләр дип беләм.

10 Хатын-кызларның үзегезнең кайсы якларыгызга игътибар итүне көтәсез?

– Мәктәптә укыганда спорт белән җитди итеп шөгыльләнә идем: чаңгыда шуам, йөгерәм... Җиңел атлетикада беренчелекне бирмим. Мактау кәгазьләрем дә байтак җыелды. Кыскасы, үземне бер дә төшеп калганнардан санамыйм. Үземә каратырга, игътибар иттерергә теләп, шул вакыт бер кызга хат яздым. «Бергә йөрик, очрашыйк әле», – дип. Икенче көнне ул хатымны кисәкләргә ертып, битемә бәрде... И-и, шул вакыт гарьләнгәннәремне белсәгез?! Шуннан соң мәктәптә укыганда да, аннан соң да мин бик озак беркем белән йөрмәдем. Хат та язмадым, үземә игътибар итүләрен дә теләмәдем. Инде өйләнгәч, хатынымнан кала башка беркемнән дә игътибар көтмәдем, эзләмәдем.

11 Ир-ат белән хатын-кыз икесе ике галәмнән икәне билгеле инде. Кайчакларда аларның бер-берсен аңламаулары шуннан килеп чыга да.

– Кадерия кайчакта: «Гел халык көйләре генә башкарырга димәгән, азрак эстрада җырларын да керт репертуарыңа», – ди миңа. «Халык җырлары минем башкаруда яхшырак килеп чыга, шуңа күрә аларны күбрәк җырлыйм», – дип, шушы хакта бәхәс купкан саен аңа аңлатам. Килешкән дә кебек була, ә аннан, вакытлар узгач, тагын сүз башлый: «Нигә эстрада җырлары юк синдә?»

12 Хаклы икәнегезне яхшы беләсез, әмма хатыныгызның үз туксаны – туксан, хаклык аның ягында дип саный.

– Андый очракта үземнең хаклы булуымны аңлатырга тырышам, аңламый икән, дәшмичә көтеп торам. Бераз вакыт үткәч, үзе килеп: «Син хаклы икән», – дип әйтә ул. Мин Елан елында туган – чага алам. Әмма үзең кагылмасаң, Елан сиңа тими ул. Тик Кадерия дә бит мишәр кызы! Гел юл гына куеп тормый – төрле чак була.

13 Шундый очракны күзаллыйк әле: Сез, ачыгып, арыпталып эштән кайтып керәсез, ә өйдә ашарга пешмәгән. Хатыныгыз, арыдым дип, диванда кырын ятып тора.

– Кадерия белән 30 ел бергә торып, андый хәлнең өйдә булганы юк әле. Безнең өстәл һәрвакыт ризык белән тулы. Минем хатын ашарга пешерергә бик оста, аның пешермәгән ризыгы юктыр. Нәрсә теләгәнеңне әйт кенә – хәзер әзерләп бирә. Күз тимәсен! Мин бигрәк тә аның пәрәмәчләрен яратам. Мишәр пәрәмәчләрен! Кадериянең шундый гадәте бар: безне ашатмыйча үзе өстәл янына утырмый да ул. «Ир-атның тамагы тук булырга тиеш», – ди.

Кадерия хәзер еш кына улыбыз янына Мәскәүгә барып йөри. Андый чакларда аш-су мәсьәләсен үзем кайгыртам инде. Берәү: «Мин бик мощный бер ризык пешерә беләм. Йомырка кыздырам!» – дип әйткән ди. Шуның кебек, мин дә йомырка кыздыра беләм. Ботка пешерәм. Кадерия шулпа кайнатып, токмач басып калдыра – аннан аш ясап ашый алам. Ач түгел!

14 Хатын-кызлар еш кына... бүләк сайлауда ялгыша: ир-атка ошамастай бүләк бирә...

– Кадериянең бүләк алганда ялгышканы юк! Киемнәрне дә Алмазга да, миңа да ул ала. Аның сайлаган әйберләре икебезгә дә ошамый калганы юк әле. Ә мин менә бүләк ала белмим... Кадерия әллә кайчан: «Берни дә алма, кирәк әйберемне үзем карармын, син акчасын гына алып кайт», – дип әйтеп куйды инде.

PRESSA.RU

ЭНҖЕЛЕ ХӘСИТӘ

Бүгенге мастер-классыбызның хуҗабикәсе – танылган кул эшләре остасы Рәмилә ГАЙНЕТДИНОВА. Сез аны телевидение аша да күреп беләсездер. Иртәнге тапшырулар вакытында кул эшләре буенча мастер-класслар үткәрә ул. Журнал укучыларыбыз да таныш аның белән. Бу юлы Рәмилә безне милли зиннәт әйберсе – хәситә тегәргә өйрәтер. Борынгы чорларда аны фәкать кыйммәтле асылташлар белән генә бизи торган булганнар. Без дә, энҗе, бәллүр, перламутр һәм көмеш йөгертелгән сәйләннәр кулланып, затлы итеп тездек хәситәне. Бертөстәге кичке күлмәк өстеннән театр-концертларга киеп бару өчен бик матур була ул.



Кирәк:

- 70x75 см зурлыгындагы бәрхет тукыма. Корея тукымасы әйбәтрәк. Чынлыкта, тукыма кисәгенең зурлыгы гәүдәгә бәйле, әмма хәситәнең киңлеге 15 сантиметрдан ким булмаска тиеш;
- шундый ук зурлыктагы дублерин кисәге;
- 7-8 клеванте (зурысы). Аны тегү кирәк-яраклары кибетендә була;
- эре энҗе бөртекләре;
- түгәрәк бәллүр;
- көмеш каймалы перламутр;
- көмеш һәм маренго (асфальт төсе) сәйлән (үлчәме – 11/0, 20 г. Һәрберсе икешәр кап кирәк булыр);
- 10 метр чамасы 0,3 мм юанлыктагы тимерчыбык. Сәйлән төсендәгесен алсагыз, бигрәк тә яхшы. 5 метры – көмеш төсле сәйләнгә, 5 метры маренго төслесе өчен кирәк;
- тукыма төсендәге тегү җебе;
- 1 метр чамасы матур тасма яки көмеш сыман чылбыр (озынлыгы гәүдәнең калынлыгына бәйле).



Эш барышы:

■ иң элек бәрхет тукыманың җеп юнәлешен ачыкларга кирәк. Өстән караганда төсе куерак булып күренсә, шул ягы өске як була. Бутамас өчен, буй юнәлешне сул якка акбур белән ук ясап, билгеләп куярга була.
■ Тукыманы бер генә катлап салып, өлгене куябыз һәм 0,5 см тегү өлеше калдырып, кисәбез. Хәситәнең икенче ягы да шушылай ук киселә. Игътибар: өлге тукымага 45 градуслы почмак белән куела!
■ Шушы өлге белән ике кисәк итеп, дублеринны кисәбез һәм дымлы тукыма аша бәрхет өлешләрнең сул ягына үтүкләпябыштырып куябыз.
■ Ике кисәкне дә бер-берләренә уң яклары белән куеп, кырыйдан машина белән тегеп чыгабыз. Җөй киңлеге 0,5 см. Аскы якта кыл уртадан 10 см араны текми калдырабыз.
■ Җөй кырыеннан чыгып калган дублеринны 0,2 мм гына калдырып, кисеп тарайтабыз. Бәрхетнең дә почмакларын кыеп алабыз.
■ Хәситәне уң ягына әйләндереп, тигезлибез. Үтүкләргә уңай булсын өчен, ачык төстәге җеп белән ике катны бергә типчеп чыгабыз. Аннары дымлы тукыма аша үтүклибез. Бәрхет өстендә үтүкне озак тотмаска кирәк.
■ Типчегән җепләрне сүтеп алып, ачык калган аралыкны белендерми генә тегәбез.

Бизәкләрне әзерләү.

■ Көмеш һәм маренго төсле сәйләннәрне аерым тимерчыбыкка тезәбез. Сатуда көмеш сыман сәйләннәрдән тезелгән чылбыр бар, аны кулланса-гыз да була. Аннары тимерчыбыкларны бер-берсенә урап, бөтерәбез.
■ Клевантедан үзебезгә ошаган өлешләрне (бөтеркәләрне) кисеп алабыз. Кискән очы сыпылмасын өчен, утта көйдерәбез. Бөтеркәнең озынлыгын исәпләп, сәйләнле тимерчыбыктан шул озынлыктагы кисәк кисеп алабыз.
■ Тимерчыбыкларның очын бөтереп, сәйләннең берсенә урап куябыз. Бушабрак китсә, ныграк бөтерәбез.
■ Сәйләнле чыбыкны бөтеркә рәвешендә бөгеп, бизәкнең эчке ягына тукыма төсендәге җеп белән тегеп куябыз. Теккән җеп күренмәсен өчен, энәне уң яктан караңгы төсле сәйлән янынннан атлатырга кирәк.
■ Бизәкнең уртасына берәр таш беркетәбез. Кайберләренең очына ваграк энҗе дә таксаң – матур була.
■ Әзер бизәкләрне матурлап хәситәгә тезәбез. Бизәкләрне тезү ирекле. Алай да бөтеркәләрне бер-берсенә терәбрәк тезәргә тырышыгыз. Килешле итеп тезеп чыкканнан соң, җебе күренмәслек итеп кенә аларны хәситәгә тегеп куябыз. Энәне хәситәнең сул ягыннан чәнчеп алмаска тырышыгыз.
■ Хәситәнең ике читенә тасма яки чылбыр беркетәбез. Озынлыгын хәситәне гәүдәгә куеп карап билгелиләр. Ул салынып та торырлык булмасын, шул ук вакытта артык кысан да булырга тиеш түгел.

PRESSA.RU



Иллә дә уңган инде бу Лилия. Татарстанның атказанган артисты, җырчы Лилия МУЛЛАГАЛИЕВАны әйтүебез. Инстаграмдагы битенә матур-матур бәлешләрне, өчпочмакларны тезә генә. Әнә беркөнне мич тутырып бәрәңге тәкәләре пешергән. Шулкадәр тәмле күренә. Мондый уңган хуҗабикә «Сөембикә»нең «йолдызлы мастер-класс» проектында катнашырга тиеш, дидек тә, җыенып, кунакка киттек үзләренә. Ялындырып тормады ул, берьюлы ике төрле таба ашы әзерләп күрсәтте. Гап-гади ризыклардан бик тиз әзерләнә һәм гаҗәеп тәмле алар...



БӘРӘҢГЕ ТӘКӘСЕ



Кирәк:

- камыр өчен (2 зур табалык)
- 1 йомырка (камырга йомырканы күп салмасаң яхшырак, ди Лилия үзе);
- 2 зур аш кашыгы 15 процентлы кибет каймагы;
- 3 аш кашыгы үсемлек мае;

150-200 г кайнаган салкын су;

- 1 аш кашыгы шикәр комы (азрак яки күбрәк тә салырга була, кем ничек ярата бит);
- 0,5 чәй кашыгы тоз;
- камырны үзле булганчы басарлык күләмдә он.

Эчлек өчен:

1,5-2 кг бәрәңге;

- 3 зур баш суган (күбрәк булса да зыяны юк);
- 1 тырнак сарымсак;
- 2-3 дәфнә (лавр) яфрагы;
- 1 чәй кашыгы әнис орлыгы (мәҗбүри түгел);

тәменчә тоз һәм төелгән кара борыч.



Эш барышы:

■ Зуррак савытка йөрмырканы сытып, каймак, су, үсемлек мае, тоз һәм шикәр комын салып, камыр басабыз. Камыр үзләнгәч, артык онламый гына озак итеп бассаң, яхшырак була дип өйрәтә җырчы.

■ Әзер камыр бераз ял итәргә тиеш. Шулай тотсаң, ул ертылмый, үзле була. Үзебез исә шул арада эчлеген ясыйк.

■ Бәрәңге белән суганны әрчеп, вак шакмаклап турыйбыз. Тоз-борыч салабыз, әнис һәм вакланган дәфнә яфрагын кушабыз. Сарымсакны исә вак угычтан уабыз. Барысын бергә болгатабыз, бернинди дә май салмыйбыз.

Төс өчен вак угычтан уылган кишер яки ваклап туралган кабак кушып җибәрергә була.

■ Камырны куна тактасына бушатып, 80-100 граммлы кисәкләргә бүләбез. Һәр кисәкне уклау белән тәгәрәтеп җәябез. Бик кечкенә булмасын, диаметры 15 см чамасы булырга тиеш. «Безнең якта тагын да зуррак – аш тәлинкәсе чаклы итеп җәяләр», – ди Лилия Муллагалиева үзе.

■ Эчлекне җәлләми салабыз. Камырның ике читен күтәреп, ябыштырабыз, матур итеп бөрәбез. Тәкәләрне (кайсы якта бөккән диләр, кайда – бөкре) төбе майлаган табага тезеп, мичкә тыгабыз. Мичне алдан ук 200 градуска кадәр кыздырабыз. Тәкәләр 20 минут чамасы пешә.

■ Алар пешкәндә күп итеп ак май эретеп куйыйк. Тәкәләрне мичтән алгач, майлыйбыз. Аннан үткен пычак белән буйга ярып, өстеннән мул итеп эретелгән ак май салабыз. Кайнар тәкә янына баллы чәй бик килешә.

Ашларыгыз тәмле булсын!



АЛСУ АЛМА БӘЛЕШЕ

■ Бәлешне төчегә генә әзерлибез. Камырны нәкъ бәрәңге тәкәсенә баскан кебек басабыз. Әзер камырны ике өлешкә бүләбез: төбенә дигәне зуррак, капкачына дигәне кечерәк булсын. Зуррак кисәкне уклау белән тәгәрәтеп җәеп, майлаган табага салабыз. Камыр таба читенә чыгып калсын.

■ Алмаларны юып, юка гына телемләп турыйбыз.

■ Сливаны төшләреннән арындырып, блендер белән издерәбез (слива өлгергән вакытта күп итеп ясап, туңдыргычта сакларга була). Слива урынына теләсә нинди башка җиләк-җимеш кулланчаң да ярый.

■ Туралган алма белән сливаны бергә кушып, шикәр комы салабыз, барысын бергә болгатабыз да камыр өстенә тигезләп салабыз. Шикәр комы алманың тәменә бәйле, алма ачырак булса, күбрәк кирәк.

■ Камырның кечерәген шулай ук юкартып җәеп, алма өстенә каплыйбыз. Кырыйларын ябыштырып чыгабыз, аннары матурлап бөрәбез.

■ Алма бәлеше 200 градус кызулыктагы мичтә 35-40 минут пешә.

PRESSA.RU



Быел җәй яңгырлы килде. Фитофтора гөмбәләре үрчер өчен бик кулай булды инде бу. Дөрестән дә, күпләрнең помидорлары каралып, яраксызга чыкты. Бәрәңге дә зарарланды, диючеләр бар. Киләсе елга да шушы хәл кабатланмас дип әйтеп булмый. Халык арасында, помидорлар томан төшкәч чери, дигән сүз йөрсә дә, томан читтән алып килми ул фитофтора гөмбәләрен. Туфракта яши алар, томан исә аларга котырып үрчесен өчен уңай шартлар гына тудыра. Алга таба да үстергән яшелчәләребез үзебезгә насыйп булсын, дисәк, инде быелдан ук чарасын күрергә кирәк.

КАРА «ДОШМАН»

Гөмбәнең споралары туфракта бик рәхәт кенә кыш чыга. Салкыннар да артык куркыныч түгел аларга. Шуңа күрә беренче көрәш чарасы – туфракны зарарсызландыру. Әмма ничек итеп? Химик препаратлар беләнме, биологик препаратлар беләнме, әллә инде халык чаралары гына да ярдәм итә аламы?

Фитофтораны җиңү өчен көрәш өч юнәлештә алып барылырга тиеш.

Беренчесе – агротехник чаралар. Никадәр генә баналь ишетелсә дә, көздән бакчаны авыру үсемлек калдыкларыннан чистарту мөһим. Аларны компост өеменә салырга ярамый, яндырсаң гына! Икенчедән, бакчаны көздән тирән итеп казып чыгарга яки сукалатырга кирәк. Әлбәттә, бу гына гөмбәләрне үтереп бетерми, әмма киметә. Язын туфракка кайнар су бөркү файдалы. Суга аз гына марганцовка салырга була. Чәчү әйләнешен саклау, үсемлекләрне тыгыз итеп утыртмау да зур роль уйный.

Икенче юнәлеш – биологик чаралар куллану. Фитофтора элек-электән булган. Әле химия уйлап тапканчы ук, аның белән көрәшкәннәр бит. Мәсәлән, суга әчегән сөт яки эремчек суы кушып, туфракка һәм үсемлекләргә сипкәннәр. Суга йод та кушсаң, аның көче тагын да арта. Яки менә бер чиләк суга салам яки печән салып, бераз мочевина өстәргә һәм 5 көн тотканнан соң, туфракка сибәргә була. Кара «дошман»ны җиңәргә көл дә булыша. Элек утын көлен колхоз басуларына сибәр өчен, хуҗалыктан җыеп йөри торган булганнар. Көлне коры килеш бөркергә дә, селтесен ясап сибәргә дә була.

Уңышны җыеп алганнан соң, түтәлләргә горчица, фацелия, тукранбаш (клевер), арыш ише сидерат үләннәр чәчеп калдырып, бераз үскәннән соң, аларны шул килеш кенә туфракка күмдереп калдыру яхшы нәтиҗә бирә. Биологик чараларның шунысы уңай – аларны көн саен чиратлаштырып кулланса да, үсемлекләргә дә, туфракка да бернинди зарары юк. Өстәвенә, ашлама да бит әле алар. Инде халык чаралары гына булышмас, дип санийсыз икән, сатуда әзер биологик препаратлар да бар. Алар да кеше сәламәтлеге өчен дә, туфрак өчен дә зарарсыз. Препаратлар, билгеле, күптөрле. Мәсәлән, «Байкал», «Бактофит», «Триходермин», «Фитоспорин»... Аларны, инструкцияләрендә күрсәтелгән күләмдә сыеклап, көздән дә, язын кар эрегәч тә сибәләр. Сыеклык туфракка ким дигәндә 10 см үтәрлек булсын, өстен чылатып кына файдасы булмас.

Инде болар да булышмаса, ярдәмгә химияне чакырабыз. Дөрес, аны бик сак кулланырга кирәк. Мәсәлән, көзен-язын туфракны бордо сыекчасы белән эшкәртергә була. Үсемлекләргә аны ел саен бөркергә яраса да, туфракта биш елга бер генә кулланырга ярый. Шулай ук 4 процентлы бакыр хлор окисе яки 2 процентлы оксихом эремәсе дә нәтиҗәле чара булып тора.

Фитофтора ачык туфракта гына түгел, теплицаларда да яши. Көздән үк аларны да йогышсызландырырга кирәк. Яшелчәләрне җыеп алганнан соң, 10 литр суга 400 г известь салып, туфракка һәм стеналарга сиптереп чыгалар. Теплицаның тәрәзә-ишекләрен ябып, күкерт төтәтү дә бик нәтиҗәле чара (сатуда күкерт шашкалары сатыла). Соңыннан ишекләрне бер-ике тәүлек ачмый торалар, аннары гына җилләтәләр.


Кучкар. Киләчәккә планнар кору, тормышны үзгәртү өчен менә дигән вакыт. Егәрегез дә җитәрлек, фикерегез дә ачык. Ниятләрегезне әлегә беркемгә дә белдерми торыгыз: көнләшеп, аяк чалмагайлары.


Үгезбозау. Максатыгызга ирешү өчен бераз гына кыюрак һәм тәвәккәлрәк булырга кирәк. Эшегезнең нәтиҗәсен шунда ук күрергә хыялланмагыз, уңыш көттереп киләчәк.


Игезәкләр. Башыгызга гениаль идеяләр килер, көчле һәм егәрле булырсыз. Талантыгыз ачыла торган вакыт. Эш һәм гаилә белән бәйле мәсьәләләр булса, уңышлы хәл ителәчәк.


Кысла. Тормышыгызны үзгәртер өчен, беренче чиратта, фикерегезне үзгәртергә кирәк. Нәтиҗәләр ясар һәм элек җибәргән хаталарны төзәтер өчен яхшы вакыт. Көчегезне алучылар белән вакытлыча гына булса да араларны суытыгыз.


Арыслан. Бөтен игътибарны гаиләгезгә багышлагыз. Тормышның һәр өлкәсендә уңыш елмаячак. Сездән бераз түземлек, тырышлык кына сорала. Кемдер ярдәм тәкъдим итә икән, баш тартмагыз, аның язмыш бүләге булуы бар.


Сөмбелә. Мәшәкатьләрне авыр кабул итә торган гадәтегез бар. Чынлыкта, бар да алай начар түгел. Бәхәсләргә кермәскә тырышыгыз. Килешми торган нәрсәләр булса да, иң яхшысы – елмаеп кына кую. Әлегә рухи тынычлыгыгыз барысыннан да мөһимрәк.


Бизмән. Намусыгыз һәм омтылышларыгыз белән тулы килешүдә булырсыз. Барысына да җитешим дип, үзегезгә көчкә килмәгә. Үтә мөһим мәсьәләләрне хәл итүне яхшырак вакытка калдырып торыгыз.


Чаян. Айга бер генә көн булса да үз рәхәтегезгә яшәп карагыз әле. Сезнең өчен бик тә мөһим бу. Театрга яки концертка барып кайтыгыз. Кышка әзерләнү өчен сезгә якты хисләр, күңелле кичерешләр кирәк.


Укчы. Барысына да җитешүе кыен булыр – якыннарыгызның ярдәменнән файдаланырга кыенсынмагыз. Көтелмәгән сәфәргә чыгуыгыз ихтимал. Моның бәхетегезгә илтүче юл булуы мөмкин.


Кәҗәмөгез. Уңышлы ай. Әмма язмыш бүләге белән ятлар алдында мактанмагыз, күз тидерүләре ихтимал. Ирешкән уңышларыгыз, рухыгызны ныгытып, яңа эшләр башларга көч бирер. Хыялларны чынга ашырыр өчен җай килеп чыгар.


Сукояр. Иялəнгән тормышыгызга үзгәрешләр килеп керер. Айның беренче яртысы күңелле вакыйгалар, истәлекле очрашулар белән хәтердә калыр. Ниятләрне чын итәр чак бу. Мөмкинлекләрне вакытында күреп алып, кулдан ычкындырмасагыз иде.


Балык. Алдыгызга олы максатлар, зур бурычлар куюдан курыкмагыз. Язмыш сезгә бүләк әзерли – нинди генә эшкә тотынсагыз да, җиңел генә башкарылачак. Шуңа күрә форсаттан файдаланып калырга кирәк.

Октябрь дә кабынган йолдызлар

Татарстан



Лидия Әхмәтова (17.10.1962) – **Татарстанның халык артисты, профессор.**

Кайбыч районының Соравыл авылында туып-үсә. Әти-әнисе җырга-моңга гашыйк кешеләр була. Гаиләдәге алты баланың алтысы да баянда, скрипкада уйный. Лидия үзе кечкенәдән үк бию белән дә мавыга. Мәктәпне тәмамлагач, Алабуга культура-агарту училищесының хор бүлегенә укырга керә. Мөмкинлекләрен күреп, укытучысы музыка училищесына барырга киңәш бирә. Аннары инде консерватория, аспирантура... Консерваторияне тәмамлаган елны ук аны Казан педагогика институтының музыка факультетына вокал укытырга чакыралар (1992). 2011 елдан – Г. Тукай исемендәге татар дәүләт филармониясендә. 2014 елдан филармониянең джаз оркестрын җитәкли. Үзе дә кырыкка якын җырга көй язган композитор.

Россия



Роза Макагонова (28.10.1927–18.04.1995) – **Россиянең атказанган артисты.**

Самарада туа. 40 нчы еллар ахырында Мәскәүгә килеп, ВГИКка укырга керә. Студент чагында ук «Далеко от Москвы» фильмында уйный. 1951 елда институтны тәмамлаганнан соң, «Киноактер» театр-студиясенә эшкә урнаша. 1953 елда Анатолий Граникның балалар өчен төшергән «Алеша Птицын вырабатывает характер» картинасында төшә. Ире – режиссер Владимир Басовның «Школа мужества», «Крушение эмирата», «Необыкновенное лето» фильмнарында уйный. 50 нче еллар ахырында бик популяр булып киткән актриса экраннардан ун елга югалып тора. Үпкә чиренең көчәеп китүе, стресслар, иреннән аерылуы белән дә бәйле була бу. Экранга кабат 1973 елда чыга – «Дача» комедиясендә уйный. Соңгы эше – Николай Чирукның «Ваши пальцы пахнут ладаном!» комедиясендәге роле.

Чит илләр




Кейт Уолш (13.10.1967) – **актриса.**

Американың Сан-Хосе шәһәрендә күп балалы гаиләдә туа. Мәктәптә укыганда ук җирле театрларда уйный. 80 нче елларда Япониядә модель булып эшли, шул ук вакытта япон студентларына инглиз телен укыта. Аннан кайткач, Чикагода «Пивенның актерлык остаханәсе»ндә белем ала. Актерлык карьерасын 1996 елда «Убойный отдел» фильмындагы роле белән башлый. 2005 елда аны «Анатомия страсти» сериалына доктор Эдиссон роленә чакыралар. Соңрак сериалның исеме «Частная практика» дип үзгәртелә һәм ул алты сезон буена бара. «Трудности быть изгоем» фильмындагы роле дә уңыш китерә.

PRESSA.RU





ЮРҮЗӘНГӘ КӨЗ КИЛГӘН...

Рәссам Ралиф Әхмәтшинның танылу юлы шактый бормалы. Әлбәттә, туган Уфасында да, Оренбургның Орскиенда да, хәтта Германия, АКШ күргәзмәләрендә дә куела аның картиналары. Ә шулай да ул меңнәрнең мәхәббәтен социаль челтәрләр аша яулады дисәк тә, ялгыш булмас. Ралифның интернетта урын алган пейзажлары күпләрне Уфаның иске урамнары, татар һәм башкорт авыллары дөньясы, Көньяк Уралның мәгърур табигате белән таныштырып, бу үзенчәлекле якны тулырак ачарга ярдәм итте. Рәссамның уңыш сере нәрсәдә соң? Мөгаен, туган җир матурлыгын үзенчә – артык сентиментальлеккә бирелмичә, дөрес итеп, тыныч төсләр белән лирик сурәтләүдәдер. Урал тау битендәге урманлы калкулыкларны һәм шушы кырыс матурлыкта гомер итүчеләрне бербөтен итеп тасвирлар өчен талант та, осталык та җитәрлек үзендә. Юк, бу сурәтләр гади фотокүчермәләр кебек кенә түгел, җирдән күтәрә торган канатлы романтика бар аларда.

Һәм тамырлар. Совет чоры сәнгать белемендә «иҗатның халыкчанлыгы»на, ягъни рәссамнарның халык тормышы белән бәйләнешенә күп игътибар бирәләр иде. Совет осталарының эшләрендә ул тормыш төрлечә чагыла – күбесе талантлы, ләкин соцреализмның артык күтәренке купшылыгы да үзен сиздерә. Әхмәтшин үзенең иҗат юлын 1980 нче еллар ахырында башлап җибәрә, элеккеге сәнгать алымнары инде искергән, ә яңалары әле үзләштерелә генә башлаган чор була ул. Һәм рәссам бердәнбер дөрес юлны сайлый – тамырларга мөрәҗәгать итә. Авыл кешесенең көнкүрешен яхшы белүе, туган авылын яратуы күптән югалган тамырларны һәм чишмәләрне искә төшертә.

Ралиф Әхмәтшинның туган җире – Башкортстанның төньягындагы Караидел районы, анда элек-электән башкортлар, татарлар (типтәрләр дә, мишәрләр дә), марилар, руслар яши. Таулы урманнар арасыннан Юрүзән елгасы ага. Булачак рәссам Юрүзән яр буендагы Шамрат авылында 1963 елда туа. Район үзәге Караиделгә – 50, күршедәге Пермь краендагы тимер юл станциясенә 120 чакрым. Әмма эт олаккан як түгел ул – гүзәл табигать, якты тынлык, уңган авылдашлары аны үзенчә бизи. Рәссам тормышында Уфа сәнгать училищесы урын алса да (аңа кадәр әле авиация институты да бар), дөньяны рәссам буларак кабул итү нәкъ менә биредә башлана.

Әхмәтшин картиналарында башка авыллар да күренеп-күренеп китә: далалы Әбҗәлил районы авыллары Равил һәм Ишкул – Башкортстанның зур рәссамы Әхмәт Лотфуллин туган яклар. Биредә йөз еллап элек кенә әле башкортлар үз тирмәләрендә яшәп, күчмә тормыш алып барган.



Парклары, борынгы урамнары белән Уфа да бар ул картиналарда.

...Ел фасыллары, җәй-көзләре үтә күренмәле пәрдә артыннан сихри бер нурга төренеп күренә.

Минем үземә Ралиф Әхмәтшинның язгы-көзге пейзажлары аеруча якын. Табигатьнең кышкы йокыдан уянуы һәм, киресенчә, сулган урман, коелган яфракларның моңсу җырында үзенә бер ямь, төсләр балкышы бар.

Табигатьтә – көз тантанасы. Рәссам картиналары белән аваздаш, сердәш, моңдаш ул.

Марат СӘФӘРОВ



РАЛИФ ӘХМӘТШИН

PRESSA.RU

21 ОКТЯБРЬ

TATAR RADIOSI ХИТЛАРЫ

ҖАНЛЫ КОНЦЕРТ



297 43 77

АЛЫП БАРУЧЫЛАР:
ГӨЛНАЗ СӘФӘРОВА & ИСКӘНДӘР ХӘЙРУЛЛИН,
АЙВАЗ САДЫЙРОВ & ЭЛЬМИРА КӘЛИМУЛЛИНА

КРК ПИРАМИДА **17:00**

РЕКЛАМА

Генераль партнер:



БАНК ДЕВОН-КРЕДИТ
БАНКОВСКАЯ ГРУППА ЗЕНИТ

VIP-партнер:



Партнерлар:

Kukmara Сделано в России since 1950



ПОРА В БАКИРОВО!





TATAR RADIOSI сеть радиостанций



Ticketland.ru

ВСЕ БИЛЕТЫ KASSIR.RU

6+